ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# КЫЗ ХИКӘЯТЕ

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# КЫЗ ХИКӘЯТЕ

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2012

УДК 902/904 + 821.512.145
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)
К 89

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

К 89 **Кыз хикәяте /** төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2012. – 184 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 10 нчы китап).

ISBN 978-5-88473-065-6

Китапта борынгы мавыктыргыч сюжетка татар телендә иҗат ителгән шигъри кыйссаның Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязма күчермәсе нәшер ителде.

Авторы хәзергә тәгаен ачыкланып бетмәгән бу хикәятнең иҗат ителү вакыты якынча XV–XVI гасырлар дип билгеләнә. Тексты 348 бәйтне (ягъни, 696 шигъри юлны) тәшкил итә торган «Кыз хикәяте» матбугатта беренче тапкыр басыла.

Бу басмада дөнья мәдәниятендә Турандот исеме белән мәшһүр булган, Шәрыкнең мең елдан артык тарихка ия сюжетына бәйле төрле телләрдәге һәм төрле дәверләрдәге әсәрләр турындагы махсус мәкалә дә урын алды.

ISBN 978-5-88473-065-6

УДК 902/904 + 821.512.145
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)

© Мәрданов Р.Ф., 2012
© «Милли китап» нәшрияты, 2012

## «ГАКЫЛЫ КИТӘР – ҺӘРКЕМ КҮРСӘ ЙӨЗЕНЕ!»

«Татар археографиясе» сериясенең бу чыгарылышында борынгы дәверләрдә Шәрыктә туган, башта Көнчыгышта, соңрак Европа әдәбиятларында гасырлар дәвамында төрле вариантлары иҗат ителгән һәм камилләшкән мавыктыргыч сюжетның бер үрнәге нәшер ителде.

Ул – урта гасырларда безнең халык җирлегендә, татар телендә иҗат ителгән «Кыз хикәяте» поэмасы. Аңа охшаш сюжетка язылган әсәрләрнең бер өлеше «Хан кызы Турандык» исеме белән бөтен дөньяда билгеле. Эчтәлекләрендә уртаклыклар булса да, «Кыз хикәяте» – оригиналь әсәр булуы белән әһәмиятле. Аның тексты моңа хәтле өйрәнелмәгән, басылып чыкмаган һәм озак вакытлар онытылып, татар укучыларына билгесез калган.

«Кыз хикәяте» Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган, XVIII гасырга караган кульязма җыентыкларның «1764 т» шифры белән билгеләнгәнендә тулы хәлендә килеп ирешкән. Башындагы һәм ахыргы битләре төшкән, барлыгы 85 кәгазьдән гыйбарәт татар кульязма җыентыгында берничә борынгы әдәби текст язылган. Аларның нәрсә икәнлекләрен тасвирлап, күзәтү ясап китәбез.

Җыентыкның 1а–18б кәгазьләрендә Мөхәммәт пәйгамбәрнең мигъраҗы (күккә – Аллаһ катына ашу) вакыйгасын тасвирлаган күләмле шигъри әсәр язылган. Тик текстының башындагы битләре җуелган. Ахырында әсәрнең исеме һәм аның авторы күрсәтелгән:

Хаҗи Мәхмүд дөзде ошбу «Миғраҗ»ы
Кем, киясез йәрен андан салават таҗы.

Димәк, авторы – Хаҗи Мәхмүт, ә әсәрнең исеме – «Мигъраҗ» булуы аңлашыла. Бәлки аның тулы исеме «Мигъраҗнамә» булгандыр, әсәр ахырында бары тик шигъри төзелешкә һәм ритмикага күрә ул «Мигъраҗ» рәвешендә кыскартып язылгандыр.

Кульязмада «Мигъраҗ» исемле шигъри әсәрнең барлыгы 459 бәйте (918 шигъри юлы) сакланган. Һәр биттә 13 бәйт язылган. Әмма кульязманың 1а битендәге текст бөтенләй укылмый диярлек, аерым сүзләрне генә танырга мөмкин. 1б–8б кәгазьләрдәге текстлар да дефектлы, алар яртылаш кына укыла.

Бу әсәрнең теле бик борынгы. Ләкин шигъри куәсе, «Кыз хикәяте» белән чагыштырганда, йомшаграк. Палеографиясе үзенчәлекле һәм кызыклы. «Мигъраҗ» текстының кайбер юллары «Кыйссаи Мансур» поэмасына аваздаш. Мәсәлән, «Мигъраҗ»дагы

Йа, Мөхәммәд! Сән – бәнүм, бән – сәнүң,
Ғәрше көрси, йиде күк – җөмлә сәнүң,

шулай ук

Нә пәрдә қалды арамызда, нә хиҗаб,
Аллаһың дидарын күрдем – ғәҗәб!

Ғайан улды қаршума Хақ дидары –
Күрмәз улды күзләремүң нәзары.

Дөнйа күзе Хақ йөзен күрмәз улур,
Қадир Җәббар җани күзенә нур орур.

Җан күзилә күрдем ул Сөбхаными,
Ул бәне әүварә әйләйән солтаными,

– кебек һәм боларга охшаш юллар «Кыйссаи Мансур»да берничә урында очрый[1]. Бу факт – ике әсәр арасында үзара йогынты-тәэсир булгандыр дигән фикергә этәрә. Шулай ук Мөхәммәтәмин һәм Мөхәммәдьяр әсәрләре белән Хаҗи Мәхмүд «Мигъраҗ»ы арасында тел-стиль уртаклыклары, охшаш рифмаларның күп булуы бу әсәрне XV–XVI гасырларда иҗат ителгән дип билгеләргә бер дәлил булып тора.

Татар әдәбияты тарихын өйрәнгән галимнәр Гали Рәхим (1892–1943) белән Газиз Гобәйдуллин (1887–1937) пәйгамбәрләрнең һәм изгеләрнең тормышларына багышланган чыгытай әдәбияты истәлекләре турында язганда «Мигъраҗнамә» дигән бер әсәрне телгә алып үткәннәр[2]. Алар күздә тоткан «Мигъраҗнамә» нәкъ шушы – без тасвирлый торган кулъязмадагы әсәр булганмы яисә бүтәнме – әлеге

[1] [Мөхәммәтәмин]. Кыйссаи Мансур / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – 128 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 6 нчы китап).
[2] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Беренче җилд: борынгы дәвер. Беренче бүлек. Мәдхәл: борынгы төркләрдә әдәбият. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты, 1924. – Б. 136.

мәсьәлә билгесез. Чөнки Г.Рәхим һәм Г.Газиз китабында ул әсәр турында бүтән сүз юк.

Француз тюркологы Паве де Куртей (Павэ де Куртейль, 1821–1889) тарафыннан «Мигъраҗнамә» исемендәге бер әсәрнең французчага тәрҗемәсе 1882 елда Парижда бастырылган булуы фәндә билгеле. Куртей тәрҗемә иткән төрки телдәге әсәрнең 1436 елда уйгур язуы белән теркәлгән 69 кәгазьдәге нөсхәсе Париж Милли китапханәсендә саклана икән[3]. Фарсы галиме Т.Гәнҗәи тикшеренүләреннән күренгәнчә, 1432–1442 елларда кайбер дини һәм әдәби әсәрләр, шул исәптән «Мигъраҗнамә» гарәп язуыннан уйгур язуына күчерелгән булган[4]. Паве де Куртей телгә алган «Мигъраҗнамә» текстының уйгур язуында булу сәбәбе шуның белән аңлатыла дип исәплибез.

Француз галиме бастырган текст белән танышу мөмкинлегебез чикләнгәнлектән, без ул әсәр турында кайбер фикерләрне фаразлар рәвешендә генә искәртеп китә алабыз. Э.Умаров мәкаләсендә Паве де Куртей бастырган әсәрнең шигъри рәвештәге яисә чәчмә булганлыгы турында әйтелмәгән. Гәрчә француз галименең башка тәрҗемәләре арасында ике төр әсәрләр дә булган.

Танылган татар галиме Әмир Нәҗип (1899–1991) хезмәтләрендә «Мигъраҗнамә» турында бераз мәгълүмат бар. Ул XIII йөздә гарәп теленнән төрки телгә тәрҗемә ителгән «Мигъраҗнамә» исемле әсәр булганлыгын, аны исә Паве де Куртей, шулай ук аңа ияреп С.Е.Малов «Нәһҗел-фәрадис» китабы белән бутаганлыклары турында язган. Ә.Нәҗип бу карашның ялгыш икәнлеген аңлаткан. Аерым алганда, ул Маловның «Мигъраҗнамә» авторы Шиһабетдин Мәрҗанидә искә алынган Гали угылы Мәхмүд Болгари түгел микән дигән фикерен кире каккан[5]. Кызганыч ки, Әмир Нәҗиптә дә «Мигъраҗнамә» әсәренең нинди төрдә (шигъри яисә чәчмә) булуы әйтелмәгән.

---

[3] Умаров Э. Паве де Куртей – лексикограф: к 160-летию со дня рождения // Советская тюркология. – 1981. – №6. – С. 72.

[4] Щербак А.М. К изучению старотюркской и персидско-таджикской литературы // Советская тюркология. – 1987. – №5. – С. 119.

[5] Нәҗип Ә. Татар әдәбиятының һәм әдәби теленең кайбер онытылган язма истәлекләре турында: Татар әдәби теленең һәм әдәбиятының формалашу тарихына карата // Совет әдәбияты. – 1957. – №12. – Б. 83; Наджип Э. О памятнике XIV века «Нахдж ал-фарадис» и его языке // Советская тюркология. – 1971. – №6. – С. 65–66; Наджип Э.Н. Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV века. На материале «Хосрау и Ширин» Кутба. В четырёх книгах. Книга I. – М.: Главн. ред. Вост. лит., 1979. – С. 64–65.

Танылган тюрколог Сергей Ефимович Малов (1880–1957) «Мигъраҗнамә» әсәренең 1442 елгы кульязмасына нигезләнеп, аны иске чыгытай теле истәлеге дип билгеләгән булган[6]. Ләкин Э.Фазылов Маловның бу фикеренә саграк карарга киңәш иткән[7].

Тюрколог галимнәрнең әйтеп үтелгән хезмәтләрендә язылган һәм телгә алынган «Мигъраҗнамә» без сүз алып бара торган, Татарстан Милли китапханәсендәге «1764 т» шифрлы кульязмадагы «Мигъраҗ» әсәре белән бер үк әдәби истәлек дип әйтү өчен хәзергә җитәрлек дәлилләр юк. Тюркологлар телгә алган «Мигъраҗнамә»нең исеме без тикшергән кульязмадагы әсәрнекенә охшаш булуы уңаеннан монда язып китүне кирәк дип таптык. Максатыбыз – киләчәктә бу әсәр белән кызыксынып, аны өйрәнергә иҗтиһад итәчәк фән әһелләренә азмыкүпме мәгълүмат теркәп калдыру иде.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең мигъраҗ вакыйгасы Ислам галимнәрен, әдипләрне һәм гади мөселманнарны бик кызыксындырган темалардан булган. Шуңа күрә төрле чорларда һәм төрле илләрдә яшәп иҗат иткән әдипләр бу теманы тасвирларга алынганнар. Бер үк темага һәм бер үк исемдәге, нәзыйрә рәвешендәге, шулай ук мөстәкыйль әсәрләрне төрле телләрдә күп язган Шәрык халыкларында төрле әдипләр тарафыннан «Мигъраҗнамә» исемле әсәрләр дә иҗат ителгән. Мәсәлән, мәшһүр төрки шагыйрьләрдән Әхмәт Ясәвинең «Хикәяте мигъраҗ» исемле поэмасы, Сөләйман Бакырганыйның (1166/67–1186) «Мигъраҗнамә» исеме белән йөргән шигъри әсәре булган[8]. Пәйгамбәрнең мигъраҗ вакыйгасы Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» әсәрендә дә киң яктыртылган. Шуңа күрә, безнең татар авторларының да бу темага әсәр иҗат иткән булуы бик ихтимал.

Авторы Хаҗи Мәхмүд булган «Мигъраҗ» әсәре текстында, урта гасырлардагы әдәби ядкәрләр телендәгечә хасиятләрдән тыш, борынгы чыгытай теленә хас аерым үзенчәлекләр күп дип, аерып әйтерлек түгел.

---

[6] Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности: тексты и исследования. – М.; Л.: изд-во АН СССР, 1951. – С. 96.

[7] Фазылов Э.И. С.Е.Малов – исследователь истории тюркских языков СССР // Советская тюркология. – 1975. – №5. – С. 66.

[8] Яхин Ф. Урта гасырлар татар әдәбияты: татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: «Раннур» нәшр., 2003. – Б. 89–91; Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской академии наук. – М: Вост. лит., 2002. – С. 258.

Бу әсәр авторының Хаҗи Мәхмүд дигән исеме татар әдәбиятының мәшһүр шагыйре Мөхәммәдьярның әтисе исеменә аваздаш булуы аеруча кызыклы. Билгеле булганча, Мөхәммәдьяр «Төхфәи мәрдан» поэмасының ахырында

Атымны кем тиб сорсаң, и шәһрийар,
Мәхмүд Хаҗи угылы фәкыйрь Мөхәммәдйар,

– дип язган юллардан шагыйрьнең әтисенең исеме мәгълүм иде. Менә бу мисалдан башка, төрки-татар әдәбияты тарихында Мәхмүд Хаҗи (яисә Хаҗи Мәхмүд) исемле шәхес турында мәгълүмат тапмадык. Мөхәммәдьярның әтисе Мәхмүд Хаҗи белән «Мигъраҗ»ның авторы икесе бер үк зат булуы ихтимал дип фаразларга мөмкин. Болар киләчәктәге тикшеренүләр нәтиҗәсендә, бигрәк тә Паве де Куртей бастырган хезмәт белән Татарстан Милли китапханәсендәге «Мигъраҗ» текстын чагыштырып өйрәнгәч, ачыкланыр дип өметләнәбез.

Кулъязма җыентыкның 18б–20а кәгазьләрендә «Һәркем гаурәтенә инана...» дип башланган, күләме белән кечкенә (бары тик 40 бәйтлек) шигъри әсәр тексты язылган. Авторы күрсәтелмәгән. Бу әсәрнең күләме зур булмаса да, сюжеты бөтен һәм гыйбрәтле. Аның төп мәгънәсе – ирләрне хатыннарына ышанып алданмаска өндәүдән гыйбарәт.

Җыентыкның 20б–26б кәгазьләрен «Әбелфәварис хикәяте»нең тулы тексты, 26б–30а кәгазьләрен төрки-татарча дини риваятьләр биләп тора.

31б–44б кәгазьләрдә күләмле шигъри әсәр – XV гасыр төрек шагыйре Раушаниның «Шубан кыйссасы» язылган. Әсәрнең үзендә аның исеме «Дәр мәдхе Җәлаледдин Руми» дип күрсәтелгән.

Җыентыкның 49а–58б кәгазьләрендә язылган шигъри әсәрнең башында «Кыз хикәяте» дип, исеме күрсәтелгән. Бу текст тулы: башы һәм ахыры бөтен. Әмма авторы кем булганлыгы әйтелмәгән. Хикәят тексты кулъязманың һәр битендә икешәр баганалы 17 (18) юл булып, 12,5х15,5 (16,5) см күләмендәге мәйданны били.

59а–64а кәгазьләрдә «Мәсаилес-салават» исемендәге, төрки-татар телендәге шигъри әсәр теркәлгән. 64а–85б кәгазьләрдә «Мәфатихелколүб» исемле дини эчтәлекле чәчмә әсәр тексты язылган.

Бу кулъязма җыентык Татарстан Милли китапханәсе фондына 2000 елда Казан шәһәрендә алынды.

Әлеге җыентыкка кергән, югарыда санап үтелгән әсәрләрдән «Кыз хикәяте»нең текстын тикшереп һәм өйрәнеп аерым бастырып чыгарырга булдык. Поэманың бу кулъязма нөсхәсе фән әһелләренә һәм, гомумән, киң даирәгә билгесез иде.

***

«Кыз хикәяте» турында тәфсилләп язуга керешкәнче, бер мәсьәләгә тукталып үтәргә тиешбез. Әдәбият галиме Нәҗип Исмәгыйлев бу әсәрнең бер вариантын (тулы булмаган күчермәсен) элекке Ленинград (Петербург) шәһәрендәге Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү (хәзерге Көнчыгыш кульъязмалары) институтында тапканлыгын белдереп һәм шул кульъязмага кыскача күзәтүен биреп мәкалә бастырган иде[9]. Н.Исмәгыйлев болай дип язды: «1982 елның җәендә Ленинград Көнчыгыш институты китапханәсенең кульъязмалар бүлегендә эзләнүләр белән шөгыльләнгәндә «Кыйсса-и Ибраһим егет вә падишаһ кызы» дип исемләнгән кульъязма табылды. Шигъри икеюллыклар белән язылган бу кыйсса «Мәликә китабы»ндагы сюжетка корылган әсәр булып чыкты. Сюжет бик кызыклы, анда башка вариантларда булмаган мотивлар да бар. Кыз белән егет арасында сорау-җавап ярышы беткәч, ахырда егет үзе бер сорау бирә. Кыз аңа җавап бирә алмый. Бик гарьләнеп, җавапны хәйлә белән белү өчен төсен-кыяфәтен үзгәртеп, төнлә егет янына килә. Егет белән мәҗлес корып, аңа шәрап эчертеп, җавапны сорап белә. Соңыннан егеткә йоклата торган дару биреп, чыгып китә. Әмма егет янында кызның йөзеге онытылып кала. Шушы йөзек аркасында егет зур хәвефтән котыла һәм патша кызы белән кавыша. Менә бу йөзек мотивы башка вариантларда очрамый.

Безнең өчен шунысы әһәмиятле – әсәр ахырында автор кыйссаның язылган вакытын күрсәтә: ул һиҗри белән 784 ел, милади белән бу 1382 елга туры килә. Димәк, әсәр Алтын Урда чорында, Идел буенда төрки әдәбиятның чәчәк аткан чорында язылган. Шушы ук кульъязмада атаклы «Кисекбаш» кыйссасы бар. Аны махсус тикшергән Я.Әхмәтгалиева әсәрнең язылу вакытын XIV йөзгә, Алтын Урда дәверенә нисбәт итә (Ахметгалеева Я.С. Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». – М, 1979. – Б. 57, 119). «Кисекбаш» кыйссасы да, моннан тыш бу кульъязмадагы тагын ике шигъри әсәр дә тел һәм стиль ягыннан «Мәликә кыйссасы»на бик якыннар.

Шигырь белән язылган бу әсәрнең башка нөсхәләре, вариантлары бармы, таралуы ничек, – бу аерым тикшеренүне таләп итә. Һәрхәлдә, әле бу тулы булмаган нөсхәнең табылуы да безнең XIV йөз әдәбияты-

[9] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет // Казан утлары. – 1985. – №9. – Б. 181.

на яңа бер әсәр өсти, Көнчыгыш әдәбиятлары белән, аерым алганда, фарсы әдәбияты белән бәйләнеш традицияләренең бик тирәннән килгәнен һәм беркайчан да өзелеп тормавын күрсәтә.

«Мәликә» сюжетының татар әдәбиятында XIV гасырдан XX гасыр башларына кадәр төрле вариантларда, төрле формаларда бик киң таралуы – борынгы дәвердән үк язма культурасы булган башка халыкларның әдәбиятлары белән чагыштырып карарга, уртак типологик якларны һәм үзенчәлекләрне билгеләргә, беренчел чыганакларны ачыкларга мөмкинлек бирә»[10].

Мәкалә авторы Н.Исмәгыйлев бу сюжетка корылган әсәрләр турында соңрак тагын бер мәкалә бастырган иде[11]. Ул бу мәкаләдә «Сораулар, мәсьәләләр биреп егетләрне сынаучы Кытай падишаһы кызы турындагы бу сюжет – татар әдәбиятында искиткеч киң таралган. Аның хәзергә мәгълүм булган, XIV гасырдан XX гасыр башына кадәр татар әдәбиятында төрле жанр формаларында йөргән 4–5 варианты, күп сандагы кулъязма һәм басма нөсхәләре бар» дип язды[12]. Нәҗип Исмәгыйль монда «XIV гасырдан» дип язганда Ленинград Көнчыгышны өйрәнү институтында тапкан шигъри әсәрне күздә тоткан. Бу кулъязма истәлек турында бүтән галимнәрнең нәрсә дә булса язганлыгы безгә билгеле түгел.

Исмәгыйлев мәкаләсендә әйтелгән, 1382 елда иҗат ителгән әсәр теркәлгән кулъязманы Л.В.Дмитриева каталогы ярдәмендә эзләп табып, фотокүчермәсен алдырып, без дә таныштык. Нәҗип Исмәгыйлев мәкаләсендә ул әсәрнең «Кыйссаи Ибраһим егет вә падишаһ кызы» дип әйтелгән исеме кулъязма җыентыктагы башка битләрнең берәрсендә теркәлгән булгандырмы – бу мәсьәләне ачыклый алмадык. Һәрхәлдә, әсәрнең текстында аның исеме күрсәтелмәгән. Дмитриева хезмәтендә ул Ибраһим турындагы поэма буларак (Об Ибрахиме) тасвирланган. Шунда ук текстның үзендә әлеге әсәр 420 бәйтне тәшкил иткәнлеге, ләкин бу кулъязмада 154 бәйте генә саклануы турында искәртелгән. Басма каталогта күрсәтелүенчә, XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башына нисбәтле бу кулъязма җыентык Фәннәр академиясе

[10] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет… – Б. 181.
[11] Исмәгыйль Нәҗип Нәккаш. Борынгы хикәятләрдә хатын-кызлар // Татарстан. – 1994. – №5–6. – Б. 137–140.
[12] Шунда ук. – Б. 140.




*«B4060» шифрлы кулъязма (Петербург). 1а кәгазь.*

институтына 1936 елда археограф Сабир Алимовтан алынган. Ул зәңгәрсу-яшькелт рус кәгазенә кара төстәге кара белән язылган[13].

Бу поэма «В 4060» шифрлы кульязманың 1а–4б кәгазьләрендә бит саен ике баганалы итеп язылган. Текстта хәрәкәләр шактый кулланылган. Каталогта күрсәтелгәнгә караганда, җыентыкка шулай ук «Вафа һәм Мәһр» (Вафа и Махр, 4б–24б кәгазьләрдә), «Кисекбаш» (24б–28б кәгазьләрдә) поэмалары да язылган.

Әлеге әсәрнең ахырында мондый юллар бар:

Бер зәгыйфь кол иде, ады – Ибраһим.
Йарлыкасын аны, безне ки Рәхим.

Ошбу бәйтләр хасс-у-гамә улур сәбәб,
Дога кылучылар кем бездән шәйх-ү-шәб.

Канкый йылдан бу хәбәр улды тәмам,
Әйдәйем бән тарихыны вәс-сәлям.

Йиде йөз сиксән дүртендә һөмам,
Йарлыкасун Хәллякыль-әнам.

Түрт йөз йегерме бәйт бән дидүм,
Мөхәррәм айында вә итмам әйләдүм.

Шөкре Аллаһ кем, кыйлдук бу дәфтәри,
Вир салават – шад кыйл фигамбәри[14].

Менә шушылардан әлеге әсәрне иҗат иткән авторның исеме Ибраһим булганлыгы аңлашыла. Шулай ук поэма 420 бәйтне (икеюллыкны) тәшкил иткәнлеге һәм аның һиҗри 784 елның мөхәррәм аенда язып төгәлләнгәнлеге күрсәтелгән. Бу дата милади ел исәбе буенча 1382 елның февраль-март айларына туры килә.

Әлеге кульязма җыентыктагы 784 һиҗри ел фәнни басмаларда элегрәк чагылыш алган булган. Ягъни, кульязманың шушы поэма

---

[13] Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской академии наук. – М: Вост. лит., 2002. – С. 400.

[14] *ады* – аты, исеме; *хасс-у-гамә* – бөтен халыкка; *шәйх-ү-шәб* – карт һәм яшь; *канкый* – кайсы; *һөмам* – тырыш кеше; *Хәллякыль-әнам* – барлык кешелекне яратучы (Аллаһ Тәгалә); *итмам әйләдүм* – тәмам иттем; *вир* – бир; *фигамбәри* – пәйгамбәрне.

язылган 1а кәгазенең өстендә башка кеше тарафыннан кызыл карандаш белән гарәп язуында «Дастане Кисекбаш» диелгән һәм соңрак кара белән сызып куелган сүзләр бар. «Кисекбаш» әсәрен фәнни яктан өйрәнгән галимә Я.Әхмәтгалиева бу кульязмада ялгыш күрсәтелгән исеменә карап, әлеге ядкәр 784 һиҗри елга карый дип билгеләгән[15]. Ләкин ул бу хатасын үзе үк төзәткән[16].

Кульязма җыентыкта поэманың 154 бәйте сакланган булуын исәпкә алганда, әсәрнең 266 бәйте, кызганыч ки, билгесез кала. Мәгълүм булган өлеше поэманың өчтән береннән аз гына артык. Тик әлеге әсәрнең шушы кульязма нөсхәдә сакланган кадәрле тексты да фәнни кыйммәткә ия һәм кайбер фикер-нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Беренчедән, Н.Исмәгыйлев билгеләвенчә, ул «безнең XIV йөз әдәбиятына яңа бер әсәр өсти». Икенчедән, без бу җыентыкта бастыра торган «Кыз хикәяте»нә әлеге текстның мөнәсәбәте һәм әлеге ике поэманың үзара бәйлелек дәрәҗәсе күзаллана. Кыскача әйткәндә, «Кыз хикәяте» поэмасы – Ибраһим исемле шагыйрь 1382 елда иҗат иткән әсәрнең бүтән бер әдип тарафыннан соңрак эшкәртелгән варианты. (Бу мәсьәләгә алдарак тәфсилләп тагын тукталырбыз).

«Кыз хикәяте» әсәренең Татарстан Милли китапханәсендәгедән тыш, бүтән күчермәләре табылмасмы дип эзләнүләребез дә уңай нәтиҗә бирде. Поэма текстының тулы булмаган ике күчермәсен ачыклауга ирештек. Аларның берсе Петербургта, икенчесе Казанда саклана. Шулар турында җентеклерәк мәгълүмат биреп үтәбез.

Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана торган кульязма истәлекләр арасында «Кыз хикәяте» әсәренең тулы булмаган һәм дефектлы бер күчермәсен табып ачыкладык. «Табып ачыкладык» дибез, чөнки бу поэма тексты язылган «5228т» шифрлы, 18 кәгазьдән торган һәм XVIII гасырның ахырына нисбәтле кульязма китапханәнең каталогында «Шигъри әсәр» дигән гомуми исем белән генә теркәлгән. Кульязма төрелгән кәгазьгә зур итеп куелган сорау билгесе дә аның нәрсә икәнлеген төгәл ачыклаучы булмаганлыгына ишарәли.

---

[15] Ахметгалеева Я.С. «Кисекбаш китабы» и его рукописи // Конференция по татарскому языкознанию, посвященная 50-летию Союза ССР: тезисы докладов. – Казань: АН СССР. ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова, КГПИ, 1972. – С. 99.

[16] Ахметгалеева Я.С. Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». – М.: Наука, 1979. – С. 22.

Хакыйкатьтә, әлеге кулъязмада бер шигъри әсәр генә булмыйча, ике мөстәкыйль поэманың текстлары өлешчә сакланган. Аларның беренчесе (1а–12б кәгазьләрдә) XVI гасырда яшәп иҗат иткән мәшһүр татар шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы, икенчесе (12а–18б кәгазьләрдә[17]) – «Кыз хикәяте». Бу кулъязма Казан университеты һәм Татарстан Милли китапханәсенең берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Киров өлкәсенең Вятка Аланы районындагы Урта Шөн авылында 2002 елда табылган.

Әлеге кулъязмада «Нуры содур» текстының яртысыннан күбрәк өлеше (төгәл итеп әйткәндә, 416–787, 789–792 нче бәйтләре), шул исәптән ахыры бар. Җитмәгән өлеше: 1–415 һәм 788 бәйтләр[18].

Казан федераль университеты китапханәсендәге кулъязмада «Кыз хикәяте» текстының башы бар, ләкин ахыры юк, исеме бүтәнчә язылган. Атамасының беренче сүзләре, хәрефләре уңган булуы сәбәпле, аңлашылып бетми. Тик анда «Хикайәте гяһ дигәр фәкыйрьнамә» дип язылганга охшый. Бу кулъязмада әсәрнең барлыгы 218 бәйте (1–40, 42–97, 99–146, 148–162, 228–265, 267–274, 276–290 бәйтләр) язылган. Кулъязманың 17–18 нче кәгазьләре вертикаль буенча яртылаш диярлек ертылган булуы сәбәпле, 228–265, 267–274, 276–290 нчы бәйтләрне тулаем уку мөмкин түгел. Сакланган хәтле текст эчендәге 41, 98, 147, 266 нчы бәйтләр бөтенләй язылмыйча төшеп калган. Шулай ук бу кулъязмада 144–148 бәйтләрнең юллары үзара бутап язылган.

Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш кулъязмалары институтында саклана торган җыентыкларның берсендә шулай ук «Кыз хикәяте» әсәренең тулы булмаган бер күчермәсе саклануын ачыкладык һәм аның фотокүчермәсен алдырып таныштык. Бу кулъязма СССР Фәннәр академиясенең Татарстанда 1934 елда үткәргән археографик экспедициясе вакытында табылган. Ул рус кәгазенә татар кешесе тарафыннан

---

[17] Битләр нумерациясендә буталчыклык бар.

[18] Шунысын искәртергә тиешбез, автор 788 нче бәйттә әсәрнең иҗат ителгән елын күрсәткән булган. Сүз уңаеннан әйтик, университет китапханәсендәге шушы – «5228т» шифрлы кулъязмада теркәлгән «Нуры содур» нөсхәсе – поэманың әлеге китапханәдә саклана торган икенче күчермәсе. Ә фән даирәсендә бу поэманың 2009 елга хәтле барлыгы 11 күчермәсе билгеле булуы турында язган идек. (Мөхәммәдьяр. «Нуры содур» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары / төз.-авт. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – Б. 3–4, 10. – («Татар археографиясе» сериясе; 4 нче китап). Димәк, монысы белән бергә, хәзерге вакытка «Нуры содур»ның 12 күчермә нөсхәсе фәнгә мәгълүм дип әйтә алабыз.

коңгырт төстәге кара белән, һәр битендә берәр баганалы итеп күчереп язылган. Күләме 72 кәгазьдән тора һәм зурлыгы 17х11 сантиметрны тәшкил итә. Анда «Хәмра вә Хурлуга» дастанының тулы булмаган тексты (1а–18а кәгазьләрдә), «Кыз хикәяте» (19б–25б кәгазьләрдә), Сөләйман Бакырганыйның «Ахыр заман» поэмасы (39а–46б кәгазьләрдә, текст тулы түгел), дини эчтәлекле шигъри әсәр һәм төрле догалар (47б–72а кәгазьләрдә)[19] теркәлгән.

«Кыз хикәяте»нең тексты Л.В.Дмитриева каталогында «Патша кызы Зөләйханың егеткә биргән сораулары һәм аның җаваплары турындагы поэма» (Поэма о вопросах Зулайхи (дочери правителя) юноше и его ответы) дип язылган. Ләкин бу поэмада кызның исеме кем булганлыгы бөтенләй әйтелмәгән, ә Зөләйха дигән исем 25б кәгазьдә «Кыз хикәяте» текстыннан соң ук дәвам итеп киткән «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан алынган. Зөләйха исеме каталогка да ялгышлык белән кергән. Ягъни, Дмитриева тасвирлавында 25б–26а кәгазьләрдәге «Кыйссаи Йосыф» әсәренең өзеге аерып күрсәтелмәгән.

Бу җыентыкның 23а кәгазендәге «Ошбу китаб Мөхәммәдсиддыйкның торур, әткәсе Әхмәдҗан торур. 1855 нче йылда» дигән язудан аның кем тарафыннан күчерелгәнлеге һәм вакыты ачыклана. «А 1295» шифры белән саклана торган әлеге кульъязмадагы «Кыз хикәяте» поэмасының исеме күрсәтелмәгән, аның башланган урынында бары тик «Илаһи бәет» дип кенә куелган.

Татарстан Милли китапханәсендәге кульъязма текст белән чагыштырганда, «А 1295» кульъязмасында бу әсәрнең башы һәм ахыры юк. Аның беренче юлы 57 нче бәйткә, ә соңгысы 294 нчы бәйткә туры килә. Әмма бу бәйтләр арасында күчерүче тарафыннан төшереп калдырылган шигъри юллар бик күп. Аерым икеюллыкларның язылмый калуы белән беррәттән, поэманың 134–137, 139–167, 178–225, 185–193 нче бәйтләре кебек, урыны-урыны белән тоташ һәм зур-зур өлешләре төшереп калдырылган. Әсәрнең 294 нче бәйтеннән соң ук кульъязманың 25б кәгазендә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Зөләйха турындагы фасыл-бүлегенең «Колак тотып дыңлаңыз ошбу сүзи» дигән мәгълүм юллары дәвам итеп киткән.

[19] Дмитриева Л.В. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 261, 389, 479, 529.



*«B1295» шифрлы кулъязма (Петербург). 21б кәгазь.*

Бу кулъязма иясе Мөхәммәдситдыйк Әхмәтҗан улы әсәрнең әүвәлге нөсхәсеннән (протографтан) шактый бозып һәм хаталы күчергән: хәрефләр һәм сүзләр бутап язылган, кайбер архаик сүзләр җиңеләйтелгән. Мәсәлән, 65 нче бәйттәге «күк алында» сүзтезмәсе бу кулъязмада «күрке эчендә» дип, 70 нче бәйттәге «анча» сүзе «нәчә» дип язылган. 130 нчы бәйттәге «дәкмә» сүзе монда укучыга аңлаешлырак «һәр» сүзе белән алыштырылган. 226 нчы бәйттәге «җавабын» сүзе ялгыш «җуануб» дип язылган. Боларга охшаш мисалларны тагын да бик күп китерергә мөмкин. Шунысы мөһим, нихәтле генә хаталы һәм кимчелекле булса да, Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш кулъязмалары институтында саклана торган бу ядкәр әлеге әсәрнең татарлар арасында таралып укылганлыгына өстәмә бер дәлил булып тора.

Шулай итеп, «Кыз хикәяте» поэмасының безнең тарафтан хәзергә өч күчермә нөсхәсе ачыкланды. Әйткәнебезчә, аларның тулы нөсхәсе Татарстан Милли китапханәсендә саклана.

Поэманың монда нәшер ителә торган тексты шул тулы күчермәдән алынды, ихтыяҗ булган очракларда бүтән кулъязмаларга да мөрәҗәгать ителде. Андый урыннарга тексттагы астөшермәдә искәрмәләр бирелде.

Киләчәктә максатчан эзләгәндә, Ибраһим әсәренең дә, «Кыз хикәяте»нең дә моңарчы билгесез күчермәләре табылуы бик ихтимал әле.

## «Кыз хикәяте»нең эчтәлеге

«Кыз хикәяте» унбер-унбер иҗекле гаруз үлчәмендәге, барлыгы 348 бәйттән (ягъни, 696 шигъри юлдан) гыйбарәт.

Ислам мәдәниятенә бәйле бөтен Шәрык һәм шул исәптән төрки-татар язма әдәбиятына хас булганча, әдәби әсәрләр Аллаһка, Мөхәммәт пәйгамбәргә дан һәм мактау сүзләре белән башланган. Әмма, ни сәбәпледер, «Кыз хикәяте»нең башлангыч юлларында әлеге традиция сакланмаган. Дөрес, әсәрнең эчтәлегендә Аллаһы Тәгаләнең исеме 48 мәртәбә искә алынып макталган[20]. Автор үз исеменнән 94 нче бәйттә «Бер салават әйдәлүм Мөхәммәдкә...» дип, пәйгамбәр исемен дә язган.

---

[20] Төгәл итеп әйткәндә, «Аллаһ» исеме – сигез мәртәбә, «Аллаһ»ның синонимнары һәм эпитетлары булган сүзләрдән «Хакъ» – 12 мәртәбә, «Тәңре» атамасы – 12 урында, «Чәләб» сүзе – 4 тапкыр һәм берәр мәртәбә «Газыйм», «Кадим», «Йәзид», «Фәрд», «Әхәд», «Мөстәган», «Вәдүд», «Халикъ», «Пәрвәрдигяр», «Кадыйр», «Җәббар», «Рабб» язылган.

«Кыз хикәяте» кыйссасының эчтәлеге кыскача тасвирлаганда түбәндәгечә.

Әсәрнең башында:

Бер хикайәт кәлде, әйдәм, дилимә,
Ошбу сүздә файда вардур галимә.

Һәркем гыйлем илә даим дорыша –
Һич гөман йук – соңра гыйлем ирешә,

– дип, галимлек мәртәбәсе зур булуы искәртелә. Остазын куандырган кешенең дөньяда хур булмаячагы да әйтелә.

Шуннан соң хикәятнең төп өлеше бәян ителә. Элекке заманда мул тормышлы бер хуҗа яшәгән. Аның бик белемле һәм сүзгә оста, яхшы холыклы, күркәм йөзле бер улы була. Бер заман болар мохтаҗлыкка төшеп, бөләләр. Тамак туйдырырлык хәлләре дә калмый. Улы әтисенә бүтән шәһәргә барырга тәкъдим итә.

Үзара килешеп, бер чит шәһәргә баралар. Анда ачлыкта өч көн, өч төн җан асрыйлар. Аптыраган уллары ата-анасына «Монда ачлык һәлак иткәнче безне, патшага сатыйм икегезне. Ач хуҗа булганчы, тук кол булыгыз. Сез нәрсә диярсез?» – ди. Ата-анасының ризалашмыйча чаралары юк. Уллары шәһәргә барып, «бер колым һәм бер карт хезмәтчем бар – аларны сатам» – ди. Солтан, боларны кызганып, сатып ала. Егет әтисе бәясенә ат, әнисе өчен киемнәр ала. Ата-ана тамак туйдыру һәм кием-салым хакына солтанга кол булып калалар[21].

Егет киенеп, атка менеп сәфәр чыга. Юлда ул бер җайдакны очрата. Сәламләшәләр. Җайдак үзенең калага баруын, андагы бәккә хат илтүен әйтә. Егет исә шул якка юл тотуын әйтеп, «хатыңны тапшырырмын» дип, үзенә ала. Аерылышалар. Егет шикләнеп хатны ачып караса, анда «бу хатны китерүченең башын кисәргә» дигән юлларны укый. Гаҗәпләнеп һәм, хатны укып каравы сәбәпле, башын исән саклап калуына Аллага шөкер кылып, егет юлын дәвам итә.

Бик зур һәм бик төзек, күп халык яши торган бер шәһәргә барып җитә:

Дүрт йаны сулаб акар хуш багчалар,
Пул йиренә анда йөрүр акчалар.

[21] Моңа охшаш, ата-ананы сату вакыйгасы Мөхәммәт Әмин әсәрендә дә бар (Мөхәммәт Әмин. Могҗизнамә. – Казан: Татар. китап нәшр., 2004. – Б. 133–134.

Әмма кирмән манарасына асылган адәм башлары күреп егет бик гаҗәпләнә. Ул бер карчык өенә төн кунарга туктала. Карчык бу шәһәр солтанының гаҗәеп чибәр һәм укымышлы кызы барлыгын, үзен кияүгә алырга теләүчеләргә сораулар-табышмаклар биреп, дөрес җавап бирә алмаганнарны үлем җәзасына тартуларын сөйләп бирә. Бик күп патша һәм солтаннарның уллары йөк-йөк мал китерсә дә, кызның шарты какшамас – сорауларына дөрес җавап бирүчегә генә кияүгә барачак.

Карчыктан рөхсәт алып, бу егет тә кыз катына барып карарга була. Карчык башта каршы килеп, үгетләсә дә, аннары «Аллаһ ярдәм итсен сиңа» дип, фатихасын бирә. Егет солтан сараена барып:

Гыйлем илә, хәдис илә, тәфсир илә,
Сөйләшәлүм икебез анда билә,

– ди. Солтан егеткә харап буласың дип, фикереннән ваз кичәргә өндәп тә карый:

Солтан әйдүр: «Каныңа кермә, йегет!
Белмәз ирсәң, үлдүрүрем, сүзүм ишет!»

Ниһаять, кыз сараена кертәләр. Егет үзалдына «бу чибәрнең йөзенә баксам, ул күңелемне алып, мәҗнүн итәр дә, мин дөрес җавап бирә алмам» дип фикерли. Кызга «йөзеңне капла, шәригать буенча миңа синең йөзеңне күрү хәрам», – ди. Беренче күрешүдә кыз егеткә дөньяви һәм дини эчтәлектәге җиде сорау бирә. Дини сораулар пәйгамбәрләрнең Коръәндә тасвирланган һәм риваятьләрдә сөйләнгән вакыйгаларына бәйле. Егетнең барлык сорауларга да дөрес җавап тотуыннан кыз пошаманга төшә. Егет үзенә мәрхәмәт кылган рәхимле Аллага шөкерана укып, хушлашалар.

Ул йегет торды йирендән. Сөйенә.
Кәлде йәнә ул карыйчук өйенә.

Карчык аның котыла алуына гаҗәпләнә.

Икенче көндә иртән егет тагын кыз сараена килә. Бу юлы кыз күпчелеге дини мәсьәләләргә караган, тагын да катлаулырак унике сорау бирә. Егет һәммәсенә җавап биреп котыла.

Бу хәлгә аптыраган кыз ашаудан бизә, йокысыз кала:

Кыз каты пошукды углан эшенә,
Ул кэчдә сонмады әлен ашына.

Әндишәдән уйку кэлмәз күзенә,
Хәйран улды ул йегетүң сүзенә.

Өченче көннең иртәсендә егет кыз катына килеп,

Сәлям вирүб, шадиман утурды хуш,
Әйтде: «Дәхи нә сорарсән? Кәлдем уш».

Ике көндүр җавабуң вирдүм сәңа,
Бу көн дәхи нә сорарсән? Ди бәңа!»

Кыз исә аеруча кырысланып куркыта:

Белмәз исәң, башыңы кәсәрәм,
Ошбу кальга бөрҗенә хуш асарам.

Егет ике көн үзенә Аллаһ ярдәм итүен, инде бу юлы да ярдәме булачагына ышануын әйтә. Кыз монысында гөнаһлары өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан кеше сурәтеннән хайван, кош, бөҗәк һәм башка хәшәрәтләргә әверелдерелгәннәрне санап бирергә куша. Егет һәммәсенә җавап бирә. Ул барлыгы унтугыз затны атый. Кыз аларны шул хәлгә төшергән сәбәп-гөнаһларны да әйтергә куша. Егет барысына да җавап бирә һәм үз соравын бирә.

Ул йегет әйдер кызи: «Ий, җарийә!
Өч көн улды, сүз дөште арайә.

Йиңсәйдүң һәм кэсәр идең башыми.
Хакга чук шөкер! Үгәрде эшеми.

Бүгүн өч көндүр, сән мәсьәлә сордың бәңа,
Нә сордың ирсә, җавабын вирдем сәңа.

Бән дәхи бер мәсьәлә сорам сәнгә
Ки, җаваб әйдүр улурсаң сән бәнгә,

Шөйлә улсун шартымыз – башың кәсәм,
Илтүб ошбу кальга бөрҗенә асам!»

Кыз ризалаша. Егет үз башыннан кичкән хәлләрне сорау итеп куя.

Йегет әйдүр: «Кемдүр ул, әй, хуш сурәт,
Анасын тун әйләде, атасын – ат?»

Кыз бик күп уйланса да, җавабын бирә алмый һәм төнлә фикерләп, иртән әйтергә егеттән рөхсәт сорый. Егет ризалашып, карчык өенә кайта. Кыз көчле хәсрәткә-уйга төшә. Ниһаять, яшертен генә егет янына бару карарына килә:

Хәйлә илә мәсьәләсен сорайын,
Эртә кәленчәк җавабын вирәйен.

Дәхи нә кылур, башыны кисәйен,
Аны дәхи ошбу бөрҗдә асайын.

Тора килде, бизәде кәндүзени.
Гаклы китәр – һәркем күрсә йөзени!

Төн уртасында кыз карчык өенә килә. Рөхсәт сорап эчкә үтә.

Бакды, күрде йегет каршыдан кызы,
Әйтде: «Хуш кәлдең, әй, таң йолдызы!»

Егет кызның ник килүен сораша. Кыз: «Сиңа гашыйк булдым. Син кем? Солтан кызын җиңгәнсең икән...» дип, хәйлә белән серен ала башлый. Кыз йөзен ачкач, егет аның гүзәллегенә таң кала. Ашап-эчеп көлешәләр. Кыз егеттән: «Шаһ кызына биргән соравың нәрсә иде?» – дип, җавабын белеп ала.

Хәйлә илә ул кыз аңлады аны,
Дүнде кыз. Әйде: «Ай, җаным җаны!
Кэчдән бәрү һич эчмәдүк шәраб...

Егет шәрап эчеп, һушын җуйгач кыз китеп бара.

Иртән егет төн кызы белән бәйле хикмәтләрнең серен аңлый. Хафага төшә.

Әйтде: «Ай-вай, аңламадум эшем,
Кәсерсә золым илә ул кыз башым...»

Шул вакыт,

Бакды – күрде түшәгедә бер йөзүк,
Әйтде: «Бонуңлә ула сүзүм төзүк!»

Кашы йагкут ул йөзүк алтун иде,
Кашында ул кызың ады йазулу иде.

Йөзекне алып ул кыз сараена килә. Сәламләшәләр. Кыз егетнең кичәге соравына төгәл җавапны бирә һәм башын кистерергә куша:

Мәсьәләң бу иде – белдем, әй, йегет,
Кәстерәрәм башыңы, бел ки, эшет!

Егетне солтан янына китереп, җиңелгәнлеген хәбәр итәләр. Егет солтанга үзенең сүзе барлыгын белдереп бер күгәрченнең кыз сараеннан очып чыгып, үз өйләренә керүен әйтә. «Кошны тотып аягыннан бәйләгән идем, тик сизмәгәндә ул кызның сараена очып китте. Шөкер, аның бер кауры калды» – дип, сөйләп бирә һәм солтанга йөзекне тоттыра. Йөзектә кызының исемен укыгач солтан ярсый:

Әйтде бәр гиз: «Һәй-әй, буйнун өзүң!
Бу йегет катында нәйләр йөзүгүң?

Кыз исә бу йөзекнең үзенеке түгеллеген әйтә, ул егет алдый ди.

Солтан әйтде: «Йөзегүң кәтүр, күрәйен!
Бу йегетә бән җәзасын вирәйен».

Куркусындан шаһ кызы дүнде кәрү,
Варды сарайына, керде ичәрү.

Кыз бер останы чакыртып, хакына нәрсә сорасаң да бирәм дип, үзенә тиз генә йөзек ясарга боера. Оста бер сәгать эчендә нәкъ әүвәлгесе кебек үк йөзек ясап, аның якут кашына кызның исемен яза.

Ул остада вирделәр бең алтунни,
Әйдер остад: «Гайебләмәңез бәни?»

Алды ул кыз йөзүге, кәлде кәрү,
Ата сарайына керде ичәрү.

Кыз менә минем йөзегем дип, атасына бирә. Солтанның вәзирләре, бәкләре һәм башкалар да ике йөзекне чагыштырып карыйлар.

Бәкләр әйдүр: «Иске йөзүкдүр бу йөзүк,
Йаңы йөзүкдүр бу соңрагы йөзүк.

Рәнге – бер, калыбы – бер һәм кашы – бер,
Бу аның дәгелдүр! – дәделәр, – Йа, әмир!»

Кол-каравыш, хадим-бәкләр каму,
Танык вирделәр солтана, гаму.

Хәйләләрнең серенә төшенгән ата кызына мөрәҗәгать итеп:

Солтан әйдүр: «Сәне вирдем йегетә.
Бунуң кеби галим улмаз дөнйада!»

– ди. Шулай итеп, солтан кызын егеткә кияүгә бирә. Җиде көн, җиде төн бәйрәм була. Солтан егетне үз улы кебек күреп, үзенә алмашка хөкемдар булачагын белдерә, бәкләр дә ризалаша.

Егет солтан булганнан соң илгә гадел хөкем ирешә. «Гадил ирде ул каму йуксуллара», ягъни ул барлык фәкыйрьләргә дә гадел булган.

Атасына-анасына хальне ул,
Йаздырыб белдүрде әхвальне ул.

Коллыктагы атасы үзләренең хуҗасы булган шаһка яңалыкны җиткерә һәм азат итүен сорый. Хаким аларны азат итә. Ата-ана уллары янына килеп, бергәләп озын гомер кичерәләр.

## Әсәрнең идеясе

«Кыз хикәяте» поэмасының төп идеясе гыйлем дәрәҗәсен олылаудан гыйбарәт. Автор белем куәтен акыллы һәм гадел хөкемдар мәсьәләсенә килеп тоташтыра. Хикәятнең башында ук егеткә Аллаһ хуш гыйлем биргәнлеге, аның холкы-табигате һәм төсе-бите күркәмлеге әйтелә. Гаиләләре бөлгенлеккә төшкәч тә, угылларының акыл белән эш йөртүе нәтиҗәсендә, ата белән ана ач үлемнән котылып калалар.

Егетнең ата-анасы бай сәүдәгәрлектән бөлгенлеккә төшүе мисалында автор гыйлемнең мәртәбәсе олуграк булуын күрсәтә. Мөлкәт байлыгына караганда рухи-гыйльми байлык өстенрәк икәнлеген аңлата.

Юлда очраган җайдакның хатын ачып эчтәлеген белгәч, егетнең харап булудан котылуына да төп сәбәпче – белем. Чөнки уку-язуны белмәсә, егет юлчы биргән хатның үз башына җитәрдәй дәрәҗәдә куркынычлы икәнлеген аңламас иде. Ниһаять, солтан кызы белән сорау-җавап бәйгесе дә гыйлемлек ярышын, ягъни ике укымышлы кешенең үзара көч сынашуын тасвирлый.

Тирән гыйлемгә ия кыз бу егет белән очрашканчы байтак егетләрне җиңеп, башларына җиткән. Ул да иң югары мәртәбә итеп белемне күреп, үзен акыл сынавында җиңгән кешегә генә кияүгә барачагын шарт итеп куйган. Патшалар һәм солтаннарның угыллары хисапсыз мал-мөлкәт тәкъдим итсә дә, байлыкка риза булмыйча, сорауларына дөрес җавап бирүне өстенрәк күргән.

Егет, Аллаһ биргән гыйлемен файдаланганда, әлбәттә, Хак Тәгаләнең ярдәменә ышана һәм даими шөкер кыла. Кыз белән көч сынашканда да «гыйлем илә, хәдис илә, тәфсир илә сөйләшәлүм...» дип, дини гыйлемнәр беренче урында тотылуы искәртелә. Чынлыкта да, егет Коръәнне, Ислам дине тарихын һәм шәригать өйрәтмәләрен тирәнтен белгәнлеген дәлилли. Кыз һәм егет үз сорау-җавапларында чиксез хакыйкать һәм гаделлек чыганагы булган Коръәнгә таяналар, аңа ишарә итәләр.

Әсәр ахырында солтан үз кызын егеткә кияүгә бирүен белдереп, «моның кебек галим булмас дөньяда» дип соклана. Белемнең көченә таянып гамәл кылган егет солтанлык дәрәҗәсенә ирешә һәм дөньядагы иң газиз һәм кадерлеләре – эти-әнисен дә азат итә.

Хикәят ахырындагы «каму галим торды анда аңа колга» дигән сүзләрдән мәмләкәттә әлеге егеттән дә гыйлемле кеше булмаганлыгы аңлашыла.

Әсәрнең төп фикерен ил-дәүләт белән зур галим дәрәҗәсендәге кеше идарә итәргә тиеш дип аңларга кирәк. Бу мәсьәлә дөнья тарихы мәйданында һәр чорда да актуаль булган һәм шулай булып калуын дәвам итә.

### Сорау-җавапларга аңлатмалар

Бу хикәяттә кыз егеткә өч тапкыр көрешүдә барлыгы 21 сорау биргән. Авторның 115 нче бәйттәге «Кичәйә диген йегет вирде җавап» дигән сүзләренә карап фикерләгәндә, сорауларга җавап бирү озакка сузылган. Егерме бер сорауның дүртесе дөньяви сораулар булса, 17 сорау дини тәгълимат белән бәйле.

Әсәрдәге кайбер нәрсәләр Аллаһның исеме белән бәйләп күрсәтелсә дә, чынлыкта, сорау-җавапларның бер өлеше Коръәндә язылмаган башка төр риваятьләр, легендалар, халык ышанулары һәм хорафатларга нигезләнгән.

Текстта Аллаһы Тәгалә һәм Коръәнгә нисбәт ителгән сорау[22] һәм җавапларда тасвирланган вакыйгаларның күпчелеге, чынлап та, Коръән текстына бәйле, кайберләре Коръән тәфсирләрендә һәм пәйгамбәрләр тарихына багышланган «Кыйссасел-әнбия» һәм «Тарихе әнбия» әсәрләрендә чагылыш тапкан. Мәсәлән, «Кыз хикәяте»нең 100–107 бәйтләрендә сөйләнгән Юныс, Әюп, Адәм, Исмәгыйль, Салих пәйгамбәрләргә, Хауа анага бәйле вакыйгалар шундыйлардан. Сүз уңаеннан шуны искәртик, «Кыз хикәяте»ндә барлыгы тугыз пәйгамбәрнең (Адәм, Салих, Исмәгыйль, Ягъкуб, Йосыф, Әюп, Юныс, Гайса, Мөхәммәд галәйһиссәламнәр) исемнәре телгә алынган.

100–101 нче бәйтләрдәге табышмак һәм аның җавабы рәвешендәге, Юныс пәйгамбәрне балык йоту вакыйгасы Коръәндә «Әс-Саффат» сүрәсенең 139–148 нче аятьләрендә тасвирланган. Диңгез эчендә Юныс пәйгамбәрне көймәдән суга ташлыйлар. Аны зур хут (кит) балыгы йота. Юныс балык карынында тәсбих әйткәннән соң котылуга ирешә. Балык аны коры җиргә чыгара. Дини кыйссаларда һәм Коръән

---

[22] Автор Коръәнгә нисбәт иткән сораулар 137, 139, 143, 151, 162, 163 нче бәйтләрдә.

тәфсирләрендә бу хәлләр тәфсилле хикәяләнгән. Мәсәлән, Рабгузи китабында Юныс пәйгамбәрне суга батырмас өчен Аллаһы Тәгаләнең Залуха исемле зур балыкка йотарга әмере ирешкәнлеге бәян ителә. Балыкка «Әй, Залуха! Кырык көнгә тигенчә синең карыныңны Юныска зиндан кылдым. Сиңа йимәк-эчмәкне хәрам кыйлдым, бәгъреңне аңа михраб кыйлдым. Юнысны имгәтмәгел...» диелгән. Кырык көн булгач, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән балык Юныс пәйгамбәрне җиргә чыгарган[23].

Садыйк Иманколый тәфсирендә Юныс пәйгамбәрне балык йоту вакыйгасы Рабгузидагыга охшаш сөйләнеп, аның кырык көннән азат ителүе әйтелгән[24]. Ләкин Ногмани тәфсирендә балык Юнысны ярга өч көннән соң чыгарып ташлавы турында язылган[25].

«Кыз хикәяте»нең 102–104 нче бәйтләрендә Әюп пәйгамбәргә бәйле юлларда аның сабырлыгы турында язылган. Әюп галәйһиссәламнең зур газапларга сабыр итеп, әҗер-савапка ирешкәнлеге турында Коръәндә берничә урында әйтелгән[26].

Гаять газаплы тән җәфаларына дучар булып та, Аллаһка иманын җуймаган Әюп пәйгамбәр, сабырлыкның иң югары үрнәкләреннән берсе буларак, Рабгузи кыйссасында да тасвирланган. «Кыз хикәяте»ндә Әюп галәйһиссәламнең тәнен унике мең корт ашавы турында сүз барса, Рабгузи төрле чыганакларда кортлар саны бер мең яисә кырык мең дип язылганлыгын искәрткән[27].

«Кыз хикәяте»нең 105–107 нче бәйтләрендә кыз егеттән анадан тумаган дүрт нәрсәне әйтеп бирүен сорый. Аңа җавабында

Йегет әйдүр: «Бере – Адәм атамыз,
Икенчесе, бәллү, Хауа анамыз.

Исмәгыйль кучкарыдур ул өчүнчесе,
Ул бере дәхи – Салих тәвәсе».

---

[23] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1881. – Б. 356–359.
[24] Әл-мөҗәлләдес-сани мин тәфсири «Тәсһилел-бәйан»: фарсы телендә улан мәүляна Хөсәен әл-Вагыйз әл-Кяшифи хәзрәтләренең тәфсиренең тәрҗемәседер / тәрҗ. Мөхәммәдсадыйк әл-Иманколый. – Казан: Үрнәк, 1911. – Б. 438–439.
[25] Тәфсире Ногмани тәкмиләсе. [2 җөзъә]. – Казан: Милләт, 1911. – Б. 193.
[26] Мәсәлән, «Әл-Әнбийа» сүрәсенең 83–84 нче аятьләрендә һәм «Сад» сүрәсенең 41–44 нче аятьләрендә.
[27] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 281.

Болардан Адәм галәйһиссәламне һәм Хауа ананы Аллаһы Тәгалә яраткан.

«Исмәгыйль кучкары»на килсәк, Коръәндә Ибраһим пәйгамбәр үз улын корбан итәргә хәзерләнгәч, Аллаһы Тәгалә аның улы урынына «җәннәттән бер зур тәкә бирдек» диелә[28]. Ягъни, Ибраһимның улы Исмәгыйль урынына бирелгән тәкә хикәяттә «Исмәгыйль кучкары» дип аталган. Әлеге вакыйгалар Рабгузи китабында тәфсилләп язылган һәм корбанлык мал анда да «кучкар» буларак тасвирланган[29].

Салих «тәвәсе» (дөясе) турында Коръәннең «Әл-Әгъраф» сүрәсендәге 73 нче аятьтә Салих галәйһиссәламнең пәйгамбәрлеген раслаучы дәлил-билге булуы әйтелгән. Ногмани тәфсирендә бу турыда «Сәмуд кавеме бервакыт Салих галәйһиссәламнән могҗиза итеп ошбу таштан дәвә чыгар дәйү сорадылар. Салих галәйһиссәлам дога кылды – дәвә чыкты...» дип язылган[30]. Ягъни, ул таштан дөягә әверелгән.

Кыйссаның 108–114 нче бәйтләрендә сөйләнгән Йосыф пәйгамбәргә бәйле хәлләрнең төп нигезе – Коръәннең «Йосыф галәйһиссәлям» сүрәсендә тасвирланган. Ул вакыйгалар белән халкыбыз күп гасырлар дәвамында укып килгән мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре аша да таныш булган. «Кыйссаи Йосыф галәйһиссәлям» бүлеге Рабгузи әсәренең иң зур бүлеге булып, китапның 80 биткә якын күләмен алып тора[31]. Йосыф белән Зөләйхага бәйле вакыйгалар бу бүлектә шактый киң тасвирлануыннан тыш, ул китапта аерым «Кыйссаи Зөләйха» бүлекчәсе дә бар[32].

Поэмада кызның егеткә биргән кайбер сораулары гади, бер яки берничә сүз белән генә җавабын бирерлек булмыйча, катлаулы рәвештә төзелгәннәр. Мәсәлән, 129–130 нчы бәйтләрдәге сораулар шундыйлардан:

Ул кыз әйдүр: «Канкый агачдур, вир хәбәр,
Ул агачуң унике бодагы вар,

Дәкмә бер бодакда вардур утуз йабрак,
Һәр беренүң иче – кара, ташы – ак?»

---

[28] «Әс-Саффат» сүрәсенең 107 нче аяте; Тәфсире Ногмани тәкмиләсе. [2 җөзъэ]... – Б. 191.

[29] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 98–102.

[30] Тәфсире Ногмани тәкмиләсе. Җөзъэ әүвәл. – Казан: Милләт, 1911. – Б. 228.

[31] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 125–203.

[32] Шунда ук. – Б. 203–208.

Бер агачның унике ботагы, аларда исә утызар яфрак турындагы табышмак, ихтимал, борынгырак заманнардан ук яшәп килә торгандыр. Чөнки бу табышмак әлеге сюжетка язылган текстларның күбесендә очрый[33]. Шулай ук Нәкый Исәнбәт туплап чыгарган табышмаклар арасында

«Бер өянкедә унике ботак,
Ботак саен утыз яфрак:
Һәр яфракның бер ягы кара, бер ягы ак»,

– рәвешендәге һәм шул табышмакның башка төрдәшләре бирелгән[34].

Хикәятнең 134–135 бәйтләрендә Гайса пәйгамбәрнең кош ясавы турында сорау һәм җавап бар:

Кыз әйдүр: «Ул нә кошдур, әй, йегет,
Йомырдламаз, йыглар? Аны әйт!»

Йегет әйдүр: «Ул йарасадыр гайан,
Кем Гайса дөзде аны, бәллү бәйан».

Бу мәгълүматның башлангычы Коръәннән килә. «Әл-Маидә» сүрәсенең 110 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әмере белән Гайса галәйһиссәламнең балчыктан кош сыман әйбер (таир) әвәләп аңа сулышын өргәч, ул Аллаһ фәрманы белән кошка әверелүе турында язылган. Коръән тәфсирләрендә ул шулай ук «кош» дип кенә язылган[35].

Ә Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» әсәрендә бу кошның исеме гарәп телендә «хөффаш» дип һәм төрки телдәгечә «йараса» (ярканат) булган дип язылган. Шулай ук аңа «бу кош... үзгә кошлар тик йомурт-

---

[33] Казан федераль университеты китапханәсе. – «467 т» кулъязма. – 11а кәгазь; Мәликә китабы. – Казан, 1883. – Б. 10; Мәҗмугыл-хикәят. Нәҗип Исмәгыйль күчермәсе. – Казан, 1994. – Б. 146–147; Гоцци К. Сказки для театра: пер. с ит. – М.: Правда, 1989. – С. 239; Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. И.Һадиев, Р.Батулла. – Казан: Җыен, 2011. – Б. 118; Шиһабеддин бине Габделгазиз бине Рәхмәтуллаһ. Каләф берлә Турандук хикайәте: «Әлфе нәһар»дан алынып тәртип ителде. – Казан: Типо-литография и словолитня Т. Д. Бр. Каримовых. – 1903. – Б 90; Китабе мәликәи данишмәнд һәзар сөали мәшһүр мәга сөали мөтәфәррика. – Ташкент: В.М.Ильин типо-лит.-се, 1904. – Б. 21.

[34] Татар халык табышмаклары. Кереш мәкалә һәм аңлатмалар белән / җыючысы һәм төз. Н.Исәнбәт. – Казан: Татар. китап нәшр., 1970. – Б. 113, 470.

[35] Тәфсире Ногмани тәкмиләсе. Җөзъә әүвәл. – Казан: Милләт, 1911. – Б. 185; [Әлмөҗәлләдел-әүвәл] мин тәфсири «Тәсһилел-бәйан»... – Б. 313.

каламас, эт тик агызы-теше бар, йәнә кешеләр тик күләр, йәнә балаларыйга сөт бирүр имчәкләре бар» дигән сыйфатлама бирелгән[36].

«Кыз хикәяте»нең 136–140 нчы бәйтләрендә Коръәндә мактап телгә алынган җиде кош турында сүз бара. Кыйсса текстында алар «кош» дип аталса да, дөресе – канатлылар, ягъни очу сәләтенә ия кош һәм бөҗәкләр күздә тотылган. «Кыз хикәяте»ндә аларның гомуми рәвештә «кош» исеме астында язылуы – авторның хатасы яки кимчелеге түгел. Чөнки бу очракта гарәп телендәге «очу» тамырыннан ясалган күплек сандагы «тойур» (оча торганнар) сүзенә охшатып әйтелгән. «Кыз хикәяте»ндә шундыйлардан җиде нәрсә аталган: күгәрчен, гораб, чәкүргә, бал орусы, һөдһөд, сәңлә, йараса. «Гораб» дигәне карга (козгын) сүзенең гарәп телендәге аталышы. Чәкүргә – чикерткә яисә саранча, бал орусы – бал корты, һөдһөд – кош исеме, сәңлә (сәңәк) – чебен-черки, йараса – ярканат. Текстта болар Коръәндә телгә алынган диелсәләр дә, аларның һәммәсе дә Коръән текстында юк. Кайберләре, чынлап та, Коръән текстында булса да, башкалары Коръән тәфсирләрендә, хәдисләрдә һәм дини кыйссаларда телгән алынган. Мәсәлән, Коръәндә «Ән-Нәхл» (Бал кортлары) исеме белән аталган аерым сүрә бар. Ә «гораб» (карга) исеме Коръәннең «Әл-Маидә» сүрәсенең 31 нче аятендә телгә алынган. Коръәннең «Ән-Нәмл» (Кырмыскалар) сүрәсенең 20 нче аятендә һөдһөд кошы телгә алынган. Әмма Коръәндә ярканат турында язылмаган. Бу әсәрдә ярканат буларак искә алынган нәрсә, югарыда әйтеп үткәнебезчә, Коръәндә «таир» дип, ягъни «кош» яисә «оча торган» мәгънәсендә генә әйтелгән[37].

Аллаһы Тәгаләнең бал кортына вәхи кылуы турында әсәрнең 141–143 бәйтләрендә сөйләнгән сүзләр Коръәннең «Ән-Нәхл» (Бал кортлары) сүрәсендә 68 нче аятьтә язылган.

Кызның 144–146 нчы бәйтләрдәге соравы да катлы-катлы рәвештә бирелгән.

Дөрес сөйләсәләр дә, тәмугка керүчеләр турында 150–152 нче бәйтләрдә әйтелгән хәлләр Коръәннең «Бәкарә» сүрәсендәге 113 аятьтә язылган.

153–154 бәйтләрдәге Кояшның зурлыгы турында Коръәндә һәм хәдисләрдә нәрсә дә булса язылганлыгы безгә билгесез. Ихтимал, борынгы фәлсәфи китапларда яисә дини риваятьләрдә, бәлки астрологи-

[36] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 402.
[37] «Әл-Маидә» сүрәсенең 110 нчы аяте.

ягә багышланган әсәрләрдә бу хакта ниндидер мәгълүматлар йөргәндер дип фаразларга мөмкин.

Хикәятнең 155–156 нчы бәйтләрендә Иблиснең баштагы исеме Харис булганлыгы турында әүвәлге Коръән тәфсирләрендә үк (мәсәлән, Габдулла ибне Габбаста) язылган. Рабгузи китабында да бу хакта тәфсилләп бәйан ителгән[38].

Әсәрнең 157–158 нче бәйтләрендәге Адәм галәйһиссәламнең яше турында «Меңнән иллегә кимрәк» дигән сүзләр дини риваятьләрдәге санга туры килә диярлек. Риваятьләрдә Адәм пәйгамбәрнең 960 ел яшәгәнлеге әйтелгән. Аның җитмеш мәртәбә хаҗ кылуы да дини риваятьләрдә сөйләнгәннәргә туры килә. Рабгузи китабында Адәм галәйһиссәламнең тәкъдирдә язылган буенча, мең ел яшәргә тиеш булганлыгы һәм шуның кырык елын Аллаһы Тәгалә Дауд пәйгамбәргә биргәнлеге язылган. (Башта Даудка алтмыш яшь билгеләнгән булып, аңа Адәм галәйһиссәламнең 40 елы өстәлгән)[39].

Кыйссадагы 161–163 бәйтләрдә сүз барган җил турындагы мәсьәлә Коръәннең «әт-Тәквир» сүрәсенең 18 нче аятенә бәйле.

164–165 нче бәйтләрдәге сорау һәм җавапта Адәм пәйгамбәрнең ике улы турындагы вакыйга күздә тотылган. Коръән текстында Адәм галәйһиссәлам улларының исемнәре язылмаган. Ә төрле риваятьләрдә һәм кыйссаларда, шулай ук Рабгузи әсәрендә алар Кабил һәм Һабил исемнәре белән тасвирланган[40]. «Кыз хикәяте»ндә дә шушы исемнәр күрсәтелгән.

«Кыз хикәяте»нең 166–169 нчы бәйтләрендәге оҗмах һәм тәмуг телләре турындагы сүз «Гарәп теле – җәннәт теле» дигән ялган хәдискә бәйләп чыгарылган уйдырмага нигезләнгән. Ышанычлы дини чыганакларда ул турыда язылмаган.

Хикәятнең 183–219 нчы бәйтләрендә гөнаһлары өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан төрле хайван, кош һәм башка нәрсәләргә әйләндерелгән затлар (мәнсухлар) турындагы өлеше Коръәндә язылганнарга туры килеп бетми. Шулар эчендә 193–197 бәйтләрдәге Гайса пәйгамбәрдән ваз кичүчеләр турындагы өлеше Коръәннең «әл-Маидә» сүрәсенең 112–116 аятьләренә аваздаш. Бу мәсьәлә Рабгузида да тас-

---

[38] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 8–9, 27.

[39] Шунда ук. – Б. 35–36.

[40] Шунда ук. – Б. 29–32.

вирланган[41]. Калганнары халык инануларына һәм риваятьләренә, ырымнарга нигезләнгән.

«Кыз хикәяте»ндә мәнсухлар мәсьәләсендә бераз буталчыклык бар. Кызның соравына җавап итеп егет 19 исемне атый (186–191 бәйтләр) Алар: дуңгыз, мәймүн, аю, сыртлан, Сөһәйл, Зөһрә, таушкан, кызыл ару, бөдүр, чәкүрәк, гакрәб, яшел кәлтә, гораб (козгын), байгыш, сәрчә, шаһин, Малик-хәзин, картал, фил. Ләкин кыз боларны шул хәлгә дучар иткән сәбәпләрне сорагач, егетнең җавабында (193–219 бәйтләрдә) мәнсухлар саны 19 булса да, алар алда әйтеп үтелгәннәргә тәңгәл килмиләр. Ягъни, өчәүнең: гакрәб, Малик-хәзин һәм карталның гөнаһлары күрсәтелмәгән. Тик алар урынына, алда исемнәре бөтенләй аталмаган башка өч җан иясенең нинди гөнаһлары өчен бу хәлгә төшерелү сәбәпләре язылган. Алар: үрмәкче (үрмәкүч), сычкан һәм эт (205, 209, 210 нчы бәйтләрдә).

Хикәятнең 203–204 бәйтләрендәге Зөһрәнең азгынлыгы, йолдызга әверелдерелүе һәм Һарут белән Марут турында Рабгузи әсәрендә дә язылган[42].

Монда тасвирланган мәнсухлар һәм аларның гөнаһлары турындагы сораулар һәм җаваплар «Мәликә китабы»нда да бар. Андыйлар «Мәликә китабы»нда 23 дип соралса да, дөреслектә унбишенең генә исемнәре язылган[43]. «Мәликә китабы»ндагы мәнсухларның «Кыз хикәяте»ндәгеләргә туры килә торганнары: таушкан, аю, мәймүн, дуңгыз, үрмәкүч, сыртлан, сычкан, фил. Тик боларның ике текстта тасвирланган гөнаһ-сәбәпләре бер-берсенә тәңгәл килеп бетми. Мәсәлән, «Кыз хикәяте»ндә «айу хаҗилар малын алур иде» (200 бәйт) диелсә, «Мәликә китабы»нда ул хәрамлык кылучы гына дип аталган (11 бит), «Кыз хикәяте»ндә «эт – кәфен суйучы иде» (210 бәйт) диелсә, «Мәликә китабы»нда «сыртлан ... кәфен суйгучы ирде» (11 бит) дип язылган.

---

[41] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 404–405. Андагы хикәятнең ахыры болай тәмамланган: «...Түртенче көн Мәүля Тәгалә камугларының сурәтен бәдәл кыйлды – туңуз булуб йөрделәр. Өч көн тәкый туңуз булуб йөрделәр, түртенче көн Мәүля Тәгалә кодрәте берлә уларны йир йотты».

[42] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 40–42.

[43] Мәликә китабы. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1883. – Б. 11–12.

## Әсәрнең тасвирлау чаралары

«Кыз хикәяте»нең төп геройлары егет белән кызны автор түбәндәгечә сыйфатлаган. Әсәрдә егет «Галим иде һәм фәсыйх иде дели», «Хуш гыйлем вирмеш иде Аллаһ аңа» һәм

Холкы ләтыйф, күреклү иде сурәте,
Һәм күрке ляик эде сийәрәте,

– дип тасвирланган. Кыз исә бу рәвешле сурәтләнгән:

Күк алында ул кызыйның мисле йук,
Гашыйклар улды шәһәрдә аңа чук.

Шулай ук кызны автор «...галимдер – кемсә аны йиңмәз», «Ул кызуң һәрбер сүзе, угул, бали», «Гаҗлы китәр – һәркем күрсә йөзени», «Кайгулу улан күрүрсә, сәвенә» дип сыйфатлаган.

Кыз белән егетнең шушы хасиятләре поэмада гамәлләре белән бәйләп күрсәтелә һәм дәлилләнә.

Хикәяттә кыз белән егет бер-берсенә бик зурлап, хөрмәт белән эндәшәләр. Кыз гади генә «әй, йегет» дип җиде мәртәбә эндәшсә, «әй, хуш кеше», «сыйлә» (кардәш), «пөрһөнәр» (һөнәр иясе, оста), «әй, паке дин» (изге дин әһеле), «әй, мөһтәди» (иман әһеле), «әй, әһле дил» (акыл иясе), «әй, пишкадәм» (укымышлы кеше), «әй, хуш нәһад» (гүзәл табигатьле) дип ихтирамын да белдерә, шулай ук «ай, җаным җаны», «йара» (сөекле дус), «әй, кандәләб» (татлы ирен) рәвешендәге гыйшык сүзләрен дә әйтә.

Егет тә, кызның белеменә хөрмәт йөзеннән, «пишкадәм», «әй, дәдә» (дәрвиш), «әй, һөмам» (тырыш кеше) кебек мактау сүзләре белән, солтан кызының югары дәрәҗәсенә һәм аксөяк затына күрә, «әй, хатун» һәм «хуш нәһад» дип, гүзәллегенә сокланып «әй, күрекле йөз», «әй, таң йолдызы», «әй, җаным», «әй, нигяр» һәм «йа, нигярин» (чибәр кыз) дигән татлы сүзләр белән эндәшә.

Әсәрдәге башка әңгәмәдәшләрнең мөгамәләсе дә итагатьле. Мәсәлән, егет әтисенә «газизем», солтанга «әй, хуш нәһад» һәм «әй, шаһе җәһан» (җиһан шаһы), карчыкка «и, ана» дигән мөрәҗәгать сүзләре куллана. Солтан егеткә ихтирам белән «әй, хуҗа» дип, ә карчык егеткә «угыл җаный», «җаным» һәм «җаным угыл» дип, якын итеп сөйләшә.

Әсәрнең төп өлеше әңгәмәгә, кара-каршы сорау һәм җавапка корылган. Бигрәк тә кыз белән егетнең диалогы текстның күпчелеген биләп тора. Автор урыны-урыны белән укучыга да мөрәҗәгать итә.

Мәсәлән, ул «Гариблекдә мөфлис улмаңыз, әй, йар!» дип тели *(18 бәйт)*. Хикәятнең авторы җанландырып җибәрә торган эндәш сүзләр дә куллана. Мәсәлән, «Торды йегет, күр, нә дир атасына» *(22 бәйт)*, «Морады күр, нәфәка!» *(34 бәйт)*, «Күргел имди – Хак Тәгалә нәләр идәр!» *(39 бәйт)*, «Йегетә, күр, нә кылур!» *(251 бәйт)*, «Күр, нәләр деләр» *(312 бәйт)*.

Автор, үзе дә вакыйгалар эчендә катнашкан кебек, егет белән кыз әңгәмәсе арасында шәхси мөнәсәбәтен белдереп үтә. Мәсәлән,

Бер салават әйдәлүм Мөхәммәдкә,
Хак гыйнайәт әйләйә ул йегетә. *(94 бәйт)*

220–223 бәйтләрдә автор укучыга мөрәҗәгать итеп болай ди:

Бу җанварлар, дәхи ишедүң каму,
Адәм иде һәрбересе, әй, гаму!

Тәңре бойругын сыйыб, мәнсух улдылар,
Һәрбересе шөйлә харис улдылар.

Һәркем боларның эшендин бер эше
Эшләсә, даим йыйа тәшвише.

Ул сурәтле куписәр йәрен гайан,
Сакласун сези-безе бу эшдән!

Кыз егеткә сораулар биргәндә ашыктыра, ягъни уйланырга мөмкинлек тә калдырмый. Мәсәлән, «тиз хәбәр виргел...» *(108 бәйт)*, «тэз хәбәр вир...» *(155 бәйт)*, «тэз әйт!» *(164 бәйт)*. Өстәвенә, ул егетне төрле бәлагә дучар итү белән куркыта *(118 бәйт)*, «бүген башың кан булыр» ди *(179 бәйт)*, «башыңны кисәм һәм асам» дип яный *(180 бәйт)*. Кыз, хәтта үз хәле мөшкелләнгәч тә, егеткә «һәр заман асылмыш егетләр солтаны!» *(236 бәйт)* дип, һаваланып маташа.

Егет исә җаваплар биргәндә җебеп төшми, Аллаһның ярдәменә һәм үзенең гыйлеменә ышанган хәлдә, «буны белүр каму йуксул-бай» *(132 бәйт)*, «ушак угылы белә» *(138 бәйт)*, «буны белүр углан ушак, җөмлә белүр бу сүзе» *(167 бәйт)*, «сорур ирсәң мөшкилендән сор бәңа» *(168 бәйт)* дип гайрәтләнеп сөйләшә. Әсәр авторы мондый алымнар кулланып, вакыйгалар агышының һәм тасвирланган хәлләрнең киеренкелеген гәүдәләндерә.

299–300 нче бәйтләрдәге:

Бер күгүрчен кыз сарайындан очар,
Канчару варурса, ганбәр сачар.

Кәлде кунды безем эүнүң эченә,
Сөчлекдә бән гәрибүң сөченә.

– юлларына охшаш манзаралар Рабгузи кыйссаларында да бар. Мәсәлән, Әюп галәйһиссәлам кыйссасында муйнында энҗе, аягында йакут тагылган бер ак күгәрчен килеп керүе, патша кызы аны тотам дигәндә очып китүе турында язылган. Бу күгәрчен исә фәрештә булган икән[44]. Шулай ук Дауд галәйһиссәлам турындагы кыйссада да «Мәүля Тәгалә кодрәте берлә бер кош очуб килде: башы – йенҗүдин, күзләре – кызыл йакутдин, аяклары – яшел зөбәрҗәддин, канатлары – алтундин». Бу кош Дауд галәйһиссәлам алдына кунгач, пәйгамбәр аны тотмакчы була – ләкин кош очып китә[45]. Рабгузи әсәрендәге бу күренешләр белән «Кыз хикәяте»ндәге егет янына күгәрчен очып керүе аваздаш тасвирлардан икәнлеген искәртергә тиешбез.

Хикәятнең 54 нче бәйтендәге «Пул йиренә анда йөрүр акчалар» дигән шигъри юл вак бакыр акча урынына зур берәмлектәге көмеш акчалар кулланылуын белдерә. Ягъни, шәһәрнең бай һәм мул тормышлы булуы аңлатыла. Алтын Урда дәүләтендә «пул» сүзе язылган татар бакыр тәңкәләре XIV гасырның беренче яртысында Сарай, Болгар, Хаҗитархан кебек шәһәрләрдә сугыла башлаган[46].

«Кыз хикәяте»нең төп үзенчәлеге һәм шушы сюжетка нигезләнгән бүтән әсәрләрдән аермасы – аның нинди дә булса җирлеккә һәм урынга (патшалык, шәһәр һ.б.) бәйсез тасвирлануында. Автор бу әсәрен аерым географик һәм тарихи хасиятләргә бәйләмичә язып, аның таралыш һәм укылыш офыкларын киңәйткән.

Әсәрнең бер икеюллыгы текстның ике урынында – 261 һәм 334 бәйтләр буларак кабатланган:

Бер заман йийеб-эчеб, көлүшделәр,
Бер-беренә әрзләрен ачышдылар.

[44] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 211.
[45] Шунда ук. – Б. 300.
[46] Мөхәммәдиев Ә. Гомуми һәм төрки-татар нумизматикасы: югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 25, 150.

Әмма бу очраклы кабатлану гына булмыйча, автор тарафыннан махсус кулланылган алым дип каралырга хаклыдыр. Ягъни, егет белән кыз арасындагы бер төрле үк халәт ике төрле вәзгыятьтә күрсәтелгән.

Шагыйрь Ибраһимның 1382 елгы әсәрендә бу юллар бер генә мәртәбә бирелгән, ягъни анда кабатлану юк. Ул әсәрдә әлеге бәйт:

Бер заман йийеб-эчеб хуш кэчделәр,
Бер-беригә хуш фәрех күрүшделәр,

– рәвешендә язылган.

Поэманың сәнгати тасвирлау чаралары, әлбәттә, болар белән генә чикләнми. Без монда аларның барысына да тукталмадык.

### Хикәятнең теле һәм кульязманың палеографик үзенчәлекләре

«Кыз хикәяте»нең теле мәсьәләсенә килгәндә, ул урта гасырлардагы Идел буе төрки-татар язма теленнән аермалы түгел. Хикәятнең теле Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Мөхәммәтәминнең «Могҗизнамә» һәм «Кыйссаи Мансур», Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур», шулай ук башка әдәби ядкәрләр теленә бик якын.

Борынгы чор кульязмаларына хас булган күп кенә үзенчәлекләр бу текстта да бар. Ягъни, «ч» һәм «җ», «т» һәм «д», «б» һәм «п» хәрефләрен үзара бутап язулар очрый. Мәсәлән,«анча» сүзе урынына انجا (анҗа) дип, «чаһ» сүзе урынына جاه (җаһ), «чөн» сүзе урынына جون (җөн), «бөрҗ» урынына بورچ (бөрч), «пәнҗәрә» урынына پنچره (пәнчәрә), «һәп» урынына هب (һәб), «капу» урынына قبو (кабу), «тапусына» урынына طابوسنا (табусына), «ошбу» урынына اوشپو (ошпу), «чабар» урынына چپر (чапар), «бең» урынына پنك (пең) рәвешендә язылган сүзләрне әйтергә була. Әмма тексттагы мондый бутап язулар тотрыксыз: дөрес язылган сүзләр белән янәшәдә үк диярлек ялгыш язылганнары да бар. Болар нинди дә булса кагыйдә һәм имля үзенчәлеген белдерми, ә кульязманы күчергән кешенең белем кимәленә һәм үз чорының имля кагыйдәләрен үзләштерү дәрәҗәсенә бәйле.

Бу текстка, борынгы төрки-татар текстларындагыча, сүздә ике тартык авазны белдергән хәрефләр янәшә килгәндә бер хәреф кенә язу күренеше хас.

Гарәп язулы борынгы текстларда озын «ө» һәм «ү» авазларын белдерү өчен و (уау) хәрефеннән соң ا (әлиф) язу очраклары «Кыз хикәя-

те» кулъязмасында да бар[47]. Мәсәлән, قموا (қаму), عموا (ғаму), ايچروا (ичрү). Мондый язылыш үзенчәлеге XIII–XIV гасырлардагы ташъязмаларда, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында, Казан ханлыгы чоры татар шагыйрьләреннән Мөхәммәтәмин һәм Мөхәммәдьяр әсәрләренең кулъязма күчермәләрендә очрый. Шунысы игътибарга лаек, әлеге әсәрләрне XVIII–XIX гасырларда күчереп язучылар да аерым сүзләрдәге бу үзенчәлекне элекке рәвешенчә күчереп килгәннәр. Хәтта борынгырак дәверләрдә иҗат ителгән әсәрләрдәге мондый имля хосусиятен кайбер XIX гасыр басма китапларында да күрергә мөмкин. Ягъни, кулъязмалардагы традиция басмаларга да күчкән. Әмма, шунысы кызыклы, татар авторларының XVII гасырда иҗат ителгән әсәрләрендә андый үзенчәлекле язылышны очратканыбыз булмады. Бары тик бер хезмәттә – Кадыйргали бәкнең 1602 елда иҗат ителгән «Җамигыт-тәварих» исемле тарихи әсәрендә «ошбу» сүзе اوشبوا (ошбуа) рәвешендә язылганлыгы билгеле[48].

Кулъязмада «бөти» сүзенең بتوى рәвешендә язылган булуы да әсәр текстының борынгы чорга караганлыгына бер дәлил. Сүз ахырында وى хәрефләре белән язу үзенчәлеге Идел-Урал җирлегендә XIII–XIV гасыр ташъязмаларында да сакланган[49].

«Кыз хикәяте» текстындагы «улисәр», «килисәр», «кәрисәр» рәвешендәге киләчәк заман фигыль формасының язылышы шулай ук күбесенчә борынгырак текстларда очрый.

Хикәятнең 299 нчы бәйтендәге «канчару» сүзенең борынгы төрки сүз формасы булганлыгын искәртеп үтәргә кирәк. «Кая» мәгънәсендә-

---

[47] Мондый палеографик үзенчәлек турында галим Габдрахман Таһирҗанов язган иде (Таһирҗанов Г. Тарихтан – әдәбиятка. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – Б. 28–29). Тарихчы Рәшит Кадыйров хезмәтендә дә бу мәсьәләгә кагылышлы фикерләр бар (Кадыров Р.М. Источники по истории старотатарской письменности (XIII–XVIII вв.) и их палеографичекие особенности: дисс. ... канд. истор. наук. – Казань: КГУ, 1999. – С. 26–28).

[48] Рахим А. О новом списке татарского исторического сочинения XVII века // Вестник научного общества татароведения. №7. – Казань: Издание Академического центра Татнаркомпроса, 1927. – С. 143; То же // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 208.

[49] Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.; Л.: изд-во АН СССР, 1960. – С. 85–86. – Приложение (табл. 1–48).

ге бу сүз «Кыйссаи Йосыф» әсәренең дә бер урынында бар[50]. Йосыф Баласагунлының 1069 елда язылган «Котадгу белек» әсәрендә «канчару» сүзенә охшаш ясалган, «табару» (таба) сүзе булган[51]. Иске телдә юнәлешне белдергән мондый сүз формаларыннан шулай ук «ташкару», «эчәрү» кебекләре дә булган. Татар телендә хәзер дә кулланыла торган «эчкәре» формасы шул борынгылык ядкәре.

Бу кулъязманың текстында төрки-татар сүзләрен хәрәкәләр белән язу мисаллары да бар. Андый язылыш шулай ук борынгырак чорда иҗат ителгән әсәрләрнең күчермәләренә хас. Дөрес, «Кыз хикәяте» текстында хәрәкәләрнең урынсыз һәм хаталы язылган очраклары да бар. Мәсәлән, 165 бәйтнең ахыргы сүзләре булган «әшикяр» һәм «көффар» сүзләренең соңгы хәрефләре өстенә куелган «сәкен» хәрәкәләре кулъязмада түбәнгәрәк, аерым хәреф кебек язылып, «әшикярә» һәм «көффарә» дип укылырлык рәвештә, ялгыш язылганнар. Текстта сүз ахырындагы «ан», «ән» кушымчалары урынына хәрәкә язылган сүзләр дә очрый. Мәсәлән, «бән» сүзе بًا , «сәндән» сүзе سنداً, «алан» сүзе الاً рәвешендә язылганнар.

Әсәр кулъязмасындагы «күрде» сүзен كردى, «алучы иде» сүзен الجدى, «кәсүче иде» сүзен كسجدى, «эдүбән» сүзен ادبن рәвешләрендә, ягъни сузык авазларны белдергән хәрефләрдән башка гына язылганлыгы һәм боларга охшаш язылышларның тагын да очравы – «Кыз хикәяте» тексты башлангыч чорда, гомумән, хәрәкәләр куелып язылган булгандыр дигән фикергә этәрә. Кулъязма тексттагы байтак кына сүзләрнең ахырларында сузык авазларны белдергән «ә, е, и, ы» хәрефләренең бөтенләй язылмыйча калган булуын да күчерүче хатасы дип уйлау дөрес булмас. Чынлыкта, ул сүзләр элеккерәк кулъязмаларда хәрәкә белән белдерелгән булганнардыр. Поэма текстындагы андый очраклар (барлыгы ике дистәгә якын) астөшермәдә искәртелде.

Хикәятнең башында (7 бәйттә) «ул хуҗаның вар иде бер гыйали...» дигән юлдагы «гыйали» (гыйалы) сүзенә өстәмә аңлатма бирү сорала. Гарәп телендә «гыйал» сүзенең «өй җәмгате, гаилә, бала-чага» дигән мәгънәләре булганлыгы билгеле. Ләкин «Кыз хикәяте»ндә әлеге сүз

---

[50] Китабе кыйссаи хәзрәти Йосыф галәйһиссәлям. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1884. – Б. 40; Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе) / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын язучы Ф.С.Фәсиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – Б. 186.

[51] Малов С.Е. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 425.

«угыл» мәгънәсендә кулланылган. Бу – хата яисә ялгыш дип каралырга тиеш түгел. Чөнки төрки телдәге борынгы язма әдәбиятта «бала» яки «угыл» мәгънәсендә «гыйал» сүзе кулланылган мисаллар бар. Мәсәлән, Рабгузи китабының «Йосыф галәйһиссәлям» кыйссасында зур балыкның догасын Аллаһы Тәгалә кабул итеп, «аңа ике гыййал бирде» диелгән, ягъни ике бала бирүе күздә тотылган. Шул ук китапның Әюп галәйһиссәлам турындагы кыйссасында «Баһил әйде: Әй, Әйүб! Кырык йыл булды Тәңремдин бер угул теләрмен – миңа бирмәс. Әгәр синең Тәңрең миңа бер гыйал бирсә, иман килтүрәйен» дигән юллар бар[52].

Кулъязмада хикәят иҗат ителгән чорның палеографик үзенчәлекләреннән тыш, текстны күчергән кешенең имлядагы шәхси хосусиятләре дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, күп кенә сүзләрдәге «т» хәрефе урынына мул рәвештә «д» язылган булуы – шундыйлардан. Кулъязманың бик күп урыннарында «йегет» сүзе «йегед» буларак, «илтә» сүзе «илдә» рәвешендә язылган. Шулай ук «әйт», «эшет», «ут», «ришвәт» сүзләре урынына «әйд», «эшед», «уд», «ришвәд» дип язылган. Хәтта 274 нче бәйттәге «һушны җую» мәгънәсен белдергән «тари һуш» сүзтезмәсендәге «т» (ط) хәрефенә башлана торган гарәп сүзе дә бу кулъязмада «дари» дип, хаталы язылган. Мондый күренеш бернинди имля үзенчәлекләренә бәйле булмаган һәм шул сәбәпле хикәят текстын басмага әзерләгәндә без андый урыннарны дөресләп, «т» хәрефе белән бирдек. Ә кайсы сүзләрдә нинди хәреф язылганлыгын ачыкларга ихтыяҗ туса, аларны кулъязманың факсимилесеннән күрергә мөмкин.

Тексттагы башка сүзләрдә «т» урынына «д» язылуы очракларына килгәндә, алар борынгы язма традициягә ят күренеш түгел. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә «уд», «дөш», «дорды», «дөрлү», «дыңла», «корд», «дөн» кебек язылышлар бик күп.

Гомумән, борынгы кулъязма әсәрләрне күчереп язучылар автор текстын һәм имлясын үзләренчә үзгәрткән булулары билгеле нәрсә. «Кыз хикәяте» текстының Татарстан Милли китапханәсендәге кулъязмасында «д»лаштырып язылган сүзләрнең Казан университеты кулъязмасында «т»лаштырып язылганлыгын күрәбез. Мәсәлән, Милли китапханә күчермәсендәге «дөшде» (22 бәйт), «деләрсән» (32 бәйт), «дүрт» (54 һәм 104 бәйтләр), «деләрсә» (68 бәйт), «йатдылар» (125 бәйт) сүзләре университет күчермәсендә *төште, теләрсән, түрт,*

[52] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 142, 210.

*теләсә, йаттылар* рәвешләрендә язылганнар. Менә мондый очракларда, аерым әсәр текстының берничә кульязмасы нигезендә генә, авторның үз язылышы ничек булганлыгын ачыклау бик читен.

«Кыз хикәяте» әсәренең Казан университеты китапханәсендәге кульязма күчермәсендә, архаик сүзләрнең мәгънәләре җиңелрәк сүзләргә алыштырылган мисаллар да күренә. Мәсәлән, 46 нчы бәйттәге «арайын» сүзе университет нөсхәсендә «ачайын» дип, 74 нче бәйттәге «алнума» сүзе «башыма» дип үзгәртелгән. Ә кайбер очракларда мәгънәләре бөтенләй беленмәслек архаиклашкан сүзләр урынына университет күчермәсендә башка сүзләр язылган. Моны күчергән кешесе, искергән сүзләрне аңламаганлыктан, шулай язарга мәҗбүр булган дип фаразлау дөрес булыр.

«Кыз хикәяте»нең кульязмасында «иде» ярдәмче фигыле күпчелек очракта үз алдындагы сүзләргә «де» буларак кушылып язылган. Ләкин бу һәр очракта да шигъри үлчәмгә туры килми. Шунлыктан, басма текстка без андый урыннарны «иде» рәвешендә аерып бирдек. Кульязма текстындагы төшеп калган дип фаразланган сүзләрне һәм кушымчаларны квадрат җәяләр эчендә өстәп бастырдык.

## «Кыз хикәяте» сюжетының төп өлгесе

Бу әсәрнең сюжеты борынгы чорларның Шәрык әкиятенә нигезләнгән. Мең елдан әүвәл үк мөселманнарның изге китабы Коръәндә һәм аның тәфсирләрендә, XII гасырда яшәгән мәшһүр шагыйрь Низами иҗатында, Рабгузиның XIV гасыр башында язылган «Кыйссасел-әнбия» әсәрендә, халык авыз иҗатында тасвирланган охшаш һәм уртак тема төрки-татар әдәбиятында да төрле дәрәҗәдә чагылыш тапкан һәм үз урынын алган. Күләмле шигъри әсәрләр язу белән беррәттән, хикәят һәм әкиятләр рәвешендә телдән сөйләнгән, шулай ук кульязмалары күчерелеп халкыбыз арасында таралып укылган. Шулар тәэсирендә XX гасырга кадәр татар әдипләре (мәсәлән, Фатыйх Халиди һәм Нәкый Исәнбәт) үзләренең яңа әсәрләрен иҗат иткәннәр. (Болар хакында һәм, гомумән, әлеге сюжетка бәйле һәм турыдан-туры шуңа корылган төрле әсәрләр турында бу китабыбызда аерым мәкаләбез бирелде).

Урта гасырлардагы Шәрык һәм татар әдәбиятында нәзыйрә (өлге, үрнәк, җавап, күчермә) иҗат ысулы, ягъни поэтик калыбы киң таралган булган. Нәзыйрә – башка бер авторның әсәре тәэсирендә туган, аңа охшатып язылган әсәрне белдерә. Әдәбият теориясендә бил-

геләнгәнчә, «әдип үзенә тикле яисә үз чорында иҗат ителгән нинди дә булса бер билгеле әсәрнең темасын, сюжет схемасын һәм төп геройларын ала да, башка әсәр иҗат итә. Кагыйдә буларак эпик әсәрдә төп чыганакның темасы, еш кына исеме, сюжетының төп мотивлары саклана. Ә инде лирик парчаларда, әгәр дә алар чыганаклар белән бер үк телдә булсалар, темадан һәм үлчәмнән тыш, рифманың, еш кына аерым сурәтләрнең дә саклануы шарт. Нәзыйрәдә шагыйрь мәгълүм теманы ачуда һәм сюжетны эшкәртүдә үзе сайлаган автор белән ярышка чыга, шигъри җавабында ул үз көндәшенең, яисә үз остазының әсәрендәге теге яки бу моментларны ныграк яктыртырга, я аларны кире кагарга, пародия объектына әйләндерергә, я булмаса бүтәнчәрәк аспектта чагылдырырга омтыла. Көнчыгыш әдәбиятының күп кенә классик әсәрләре нәзыйрә рәвешендә иҗат ителгәннәр. Татар әдәбиятында нәзыйрә һәм иҗат ысулы, һәм поэтик форма буларак күптәннән үк кулланылып килә. Котб, С.Сараи, Мөхәммәдьяр, Ш.Зәки һәм башкалар аңа еш мөрәҗәгать иткәннәр»[53].

Гомумән, кешелек тарихында нинди дә булса бер теманың яшәеше һәм үстерелеше, элекке әсәрләрнең соңгырак чорларда заманга муафыйк рәвештә яңаруы әдәбият-сәнгать дөньясына хас күренеш. Борынгы әдәби әсәрләрнең соңгырак дәвердә дә замана вәзгыятенә күрә яңача гәүдәләнешенә мисаллар бар. Шундыйлардан берсе – борынгы Түләк дастаны. Танылган галим Марсель Бакиров әлеге дастанның бик әүвәлге дәверләрдәге халык иҗаты әсәре булганлыгын дәлилләп язды[54]. Күренекле әдип һәм галим Нәкый Исәнбәтнең (1899–1992) Түләк турында яңача патриотик рухта иҗат ителгән драматик поэмасы Бөек Ватан сугышы елларында сәхнәгә куелган булуы – борынгы әсәрнең заманча яңгырашына бер үрнәк[55].

Шәрык әдәбияты тарихы белгече Евгений Эдуардович Бертельс (1890–1957) элек нинди дә булса әдәби әсәрнең сюжетын кулланганда һәр автор оригиналь мәгънә салырга омтылган дип яза. Ул шулай ук, сюжетларның төрле халыклар арасында күчеп йөрүенә мисал итеп, борынгы чорда грекларның бер сюжетны фарсылардан үзләштереп, күп

[53] Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1990. – Б. 124.
[54] Бакиров М.Х. Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 200–206.
[55] Түләк китабы: дастан / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – Б.5. – («Татар археографиясе» сериясе; 2 нче китап).

гасырлар узгач аның яңадан Шәрык әдәбиятына кайтуы турында искә алган[56].

Бу җыентыкта басыла торган текст сюжетына Ибраһим исемле авторның 1382 елда иҗат иткән поэмасы нигез булганлыгы турында мәкаләбезнең башындарак язып үткән идек. Аның сакланган өлеше белән «Кыз хикәяте»н чагыштырып чыккач, без мондый нәтиҗәгә килдек: ике әсәрнең дә эчтәлеге бер-берсенә охшаш булса да, аларның авторлары бер үк кеше булмаган. Фикеребезчә, 1382 елгы әсәрне икенче бер әдип нигез итеп алып, аны иҗади эшкәрткән, нәзыйрә рәвешендә үз поэмасын язган.

«Кыз хикәяте» – 1382 елда иҗат ителгән поэманың бер күчермә варианты гына түгел микән дип карау – мәсьәләне гадиләштерү һәм ялгышлык булыр иде. Ике әсәрдәге бәйтләрнең исәп ягыннан тәңгәл килмәвен күчерүче игътибарсызлыгына сылтарга яисә күпмедер өлеше максатчан төшереп калдырылган дип нәтиҗә ясарга, бер карашка, мөмкин кебек тоелса да, мәгънәви төрлелекләрнең күплеге андый ихтималны кире кага. Текстка күчерүчеләр тарафыннан гына бу хәтле үзгәрешләр кертелгән булуы мөмкин хәл түгел. Чөнки әлеге ике поэмадан шактый борынгырак чорда Кол Гали иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» әсәренең өч йөзгә якын күчермәсе булып, мондый дәрәҗәдәге күп аермалар аларда да юк. Шулай ук «Кыз хикәяте»нең хәзергә безнең тарафтан ачыкланган өч кульязма күчермәсендәге текстлар арасында бер-берсеннән бик зур аерымлыклар юклыгын да әйтергә тиешбез. Моны раслар өчен дәлилләргә мөрәҗәгать итик.

Ибраһим әсәренең тулы тексты 420 бәйтне тәшкил иткән (шулардан 154 бәйт безгә мәгълүм). Ә «Кыз хикәяте» барлыгы 348 бәйттән тора. Беренче аерма менә шунда. Чөнки «Кыз хикәяте»нең өч кульязмасын чагыштырып өйрәнү күрсәткәнчә, аларда бәйтләр саны аермалы булганлыкка дәлилләр юк. Бары тик ике кульязманың (Казан университеты һәм Петербург нөсхәләре) тулы түгеллеге һәм дефектлы булулары сәбәпле, текстлары бөтен түгел. Ә аларның сакланган кадәр өлешләрендә Татарстан Милли китапханәсендәге нөсхәдән аермалы яңа бәйтләре юк.

Ибраһим әсәре язылган кульязманың һәр битендә «Кыз хикәяте»ндә булмаган, бөтенләй бүтәнчә бәйтләр бар. Алар 1а һәм 1б кә-

[56] Бертельс Е.Э. Избранные труды: история персидско-таджикской литературы. – М.: изд-во Вост. лит., 1960. – С. 315–316.

газьләрдә – унар, 2а һәм 2б кәгазьләрдә – бишәр, 3а кәгазьдә – бер, 3б кәгазьдә – өч, 4а һәм 4б кәгазьләрдә – алтышар бәйтне тәшкил итә. Ягъни, бу текстның барлыгы 46 бәйте «Кыз хикәяте»ндә бөтенләй юк. Шул исәптән, 1382 елгы әсәрнең ахырында аның авторы, иҗат ителү датасы һәм бәйтләр саны күрсәтелгән булса, «Кыз хикәяте»ндә боларның берсе дә язылмаган.

Әйтелгәннәргә өстәп, Ибраһим әсәрендәге тагын 12 бәйтнең «Кыз хикәяте»ндәге юллардан бик зур аермалы булуларын да искәртик. Шулай итеп, 1382 елда иҗат ителгән әсәр текстының билгеле өлеше буенча фикер йөрткәндә, аның өчтән бере «Кыз хикәяте» поэмасының текстыннан аермалы.

Ә «Кыз хикәяте» текстындагы 25 бәйт (287–293, 302, 305, 306, 308, 316, 317, 321, 323, 328, 331, 332, 334, 335, 342–346 бәйтләр) Ибраһим әсәренең сакланган өлешендәге бәйтләре арасында бөтенләй юк. Димәк, бу 25 бәйт бүтән, ягъни әсәрне яңартып, үз поэмасын тудырган авторныкы дип саналырга тиеш.

1382 елда иҗат ителгән әсәрнең сакланган тексты кызның егет янына килүе белән башланган. Кыз хәйлә белән егетне сөйләтә. Кызның егетне сөйләтү өчен «Буйнундан кочуб сөрде йөзенә-йөзен» кебек юллар «Кыз хикәяте»ндә юк. Егет исә шаһ кызы белән икесе арасында булган сорау һәм җавапларны бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Тик сораулар һәм җаваплар «Кыз хикәяте»ндәгегә тәңгәл килми. Әсәрнең бу өзегендә телгә алынган ун сорау һәм җавапның бишесе генә «Кыз хикәяте»нә туры килә. Кызның пәйгамбәрләргә, әсхабе Кәһәфкә бәйле, шулай ук башка сораулары һәм аларга егет биргән җаваплар «Кыз хикәяте»ндә бөтенләй юк. Ибраһим әсәрендә нәсех ителгәннәр дип барлыгы 27 зат күрсәтелгән булса, «Кыз хикәяте»ндә андыйларның (мәнсухларның) саны – егерме ике. Ике әсәрдәге мондый затларның күбесе бер-берсенә туры килсә дә, аермалылары да бар.

Тагын шуңа да игътибар итәргә кирәк, әлеге ике әсәрнең охшаш булган бәйтләренең дә сүзе-сүзгә тәңгәл килә торганнары бөтенләй юк. Һәр шигъри икеюллыкта нинди дә булса аерма бар. Бу ике әсәрдә бер-береннән аермалы урыннары бик аз булган бәйтләр санаулы гына диярлек. Ике текстагы иң охшаш бәйт дип 252 нче бәйтне китерергә мөмкин. Петербург кульъязмасында:

Йегет бакды – қаршыдан күрде қызы,
Диде: «Хуш кәлдүң, әй, таң йолдызы!»

«Кыз хикәяте»ндә бу юллар түбәндәгечә:

Бакды, күрде йегет қаршыдан қызы,
Әйтде: «Хуш кәлдең, әй, таң йолдызы!

Ике поэма текстларындагы охшашлык һәм аерымлыклар дәрәҗәсен түбәндәге юллардан да күзалларга мөмкин.

| ***«Кыз хикәяте»ндә (Татарстан Милли китапханәсе, «1764 т» шифрлы кульъязма)*** | ***1382 елда язылган кыйссада (С.-Петербург, «В 4060» шифрлы кульъязма)*** |
|---|---|
| *163 бәйт*<br>Ашикярә бу айәт вардур бәс<br>Кем, Қөръәндә «вәс-собхи иза тәнәффәс». | *1б кәгазь*<br>Ашикярәдүр бу айәт ғамә вә хас<br>Кем, диде «вәс-собхи иза тәнәффәс». |
| *166 бәйт*<br>Ул қыз әйдүр: «Таму әһле нә дел дәхи?<br>Бу хикайәтне [имди] сән бел дәхи!» | *1б кәгазь*<br>Қыз әйтүр: «Сөйләгел, әй, бәхте вар!<br>Ожмах әһле нәчә тел үзрә сөйләр?!» |
| *168 бәйт*<br>Сорур ирсәң, мөшкилендән сор бәңа<br>Кем, эшедәнләр қаму қала таңа! | *1б кәгазь*<br>Сорарсаң, мөшкүлендән сор бәңа,<br>Бән әйдәйем – ишедәнләр қалсун таңа! |
| *172 бәйт*<br>Қыз қаты пошуқды уғлан эшенә,<br>Ул кәчдә сонмады әлен ашына. | *2а кәгазь*<br>Қыз қаты ғосса улубән уғлан эшенә,<br>Усанмады ул кәчә улған ... (?) |
| *192 бәйт*<br>Дүнде қыз, әйтүр: «Хәбәр вир, әй, йегет!<br>Нә сәбәбдән мәнсух улдылар? Әйт!» | *2б кәгазь*<br>Қыз әйдүр: «Анлар дүндеке нәдәндүр,<br>Нә сәбәбдән нәсех улдылар ки? Әйт!» |
| *194 бәйт*<br>Өммәтейде Ғәйсаның җөмлә болар,<br>Чөн Ғәйсадан маидә деләделәр. | *2б кәгазь*<br>Өммәте иде хәзрәти Ғәйсаның болар,<br>Ғәйсадан бер моғҗиза деләделәр. |
| *197 бәйт*<br>Йөз чәверүб Ғәйсадан, улды ғәду,<br>Әйтделәр: Зәһи! Йаланчы! Җаду! | *2б кәгазь*<br>Йөз чәверде Ғәйсадан ул қәүмләр, әйде: «Ғәду!»<br>Диделәр кем Ғәйсаға һәм: «Йаланчы сән кем, җаду!» |
| *199 бәйт*<br>Чөнкем ул инҗедмәге қыйлды исә,<br>Сурәтен дүндүрде ул Қадыйр са. | *2б кәгазь*<br>Чөнки эшләсә инҗедүмәге эркәк-теши,<br>Сурәтендән тәбдил идәр ул Падишаһи. |
| *200 бәйт*<br>Айу хаҗилар малын алур иде,<br>Анлары мәймүн зәлил қыйлур иде. | *2б кәгазь*<br>Айу улдур – хөҗҗаҗларның малын алур,<br>Анлары мәғбүн әйләб, мәхрүм қылур. |
| *268 бәйт*<br>Ул атлу кәндүйә йулда йитдекен,<br>Сөйләде кәндүйә бөти вирдекен. | *2б кәгазь*<br>Ул бер атлу кәндүзенә ирдүкен,<br>Сөйләде бөти вирүбән дүндүкен. |
| *278 бәйт*<br>Әйтде: «Ай-вай, аңламадум эшем,<br>Кәсерсә золым илә ул қыз башым...» | *3а кәгазь*<br>Йегет әйдүр: «Аңламадум эшеми,<br>Кәсдүрәсирдүр ул залим бәнем башыми». |
| *280 бәйт*<br>Қашы йағқут ул йөзүк алтун иде,<br>Қашында ул қызың ады йазулу иде. | *3а кәгазь*<br>Күрде қашында йазу – қызның адын,<br>Қашы йақут ул йөзүк үзе алтун. |

| | |
|---|---|
| *301 бәйт* | *3б кәгазь* |
| Тору көлдем шул сағәт, тотдым аный,<br>Бәрк бағладым ул қошнуң айағыный. | Дийәр: «Аңладум, аулайуб тотдум аный,<br>Бақладум бәк әлени-айағыный». |
| *327 бәйт* | *4а кәгазь* |
| Солтан әйдүр: «Сәне вирдем йегетә.<br>Бунуң кеби ғалим улмаз дөнйада!» | «Бән сәне вирәм ошбу йегедә,<br>Бончалайын улмайа һич дөнйада!» |
| *337 бәйт* | *4а кәгазь* |
| Ғақибәт, солтан үлде. Қалды ул,<br>Солтан әйләмешде аны уғул. | Ғақибәт, ул йегет улды солтан,<br>Аны уғул өвүтде солтан тәмам. |
| *338 бәйт* | *4а кәгазь* |
| Ул бәкләр разый улды хөкеменә,<br>Солтанлығ вирделәр ул уғылына. | Қаму бәкләр мотыйғ улдылар уңа,<br>Диделәр: «Солтанлық мөбарәк улсын сәңа!» |
| *339 бәйт* | *4а кәгазь* |
| Чықды тәхтә, хөкем эрде элләрә,<br>Ғадил ирде ул қаму йуқсуллара. | Тәхтә чығыб, хөкем идәр анлара,<br>Ғадел улур байлара-йухсуллара. |
| *348 бәйт* | *4б кәгазь* |
| Сабыр илә ирде йегет солтанлығға,<br>Қаму ғалим торды анда аңа қолға. | Сабыр белә ирүшделәр солтанлығға,<br>Қаму бәкләр аңа дорды қоллуқға. |

Ике поэмада охшаш һәм аваздаш шигъри юллар булган очракта да рифмалашкан сүзләре бер төрле үк түгеллеге дә күзәтелә.

Мәгънәви аермаларга килгәндә, шушы – югарыда китерелгән – мисалларны гына күздән кичерү дә шактый нәрсәне төшенергә ярдәм итә. Мәсәлән, 172 бәйттәге «ғосса улубән» (кайгырып) сүзен «Кыз хикәяте»нең авторы «пошуқды» дигән җиңелрәк гыйбарәгә алыштырган. Шул ук бәйтнең икенче юлындагы «усанмады» (әһәмият бирмәде) дигән сүз урынына «сонмады» рәвешендә, бүтәнчәрәк мәгънәле сүз кулланган.

192 бәйттә «дүнде» сүзе ике текстта да бар, ләкин ул икесендә төрле кешеләргә карата кулланылган.

194 бәйттә Ибраһим әсәрендә «могҗиза» дигән сүз «Кыз хикәяте»ндә «маидә» дип, Коръәндәгечә төгәлрәк мәгънәсендә бирелгән.

Ибраһим әсәрендә башка бәйтләрдән үзенең иҗек саны күбрәк булуы белән дә аерылып торган 197 бәйт «Кыз хикәяте» авторы тарафыннан җыйнакландырылып, тиешле калыпка кертелгән.

200 бәйттә Ибраһим әсәрендә «хөҗҗаҗлар» сүзе «Кыз хикәяте»ндә татар укучысына аңлаешлы гади генә «хаҗилар» дип алыштырылган. «Хөҗҗаҗлар» дигәндәге «хөҗҗаҗ» – үзе үк гарәп телендә күплек санны белдерә, ә шуңа күплекне белдерә торган *«–лар»* кушымчасын өстәү текст өчен грамматик кытыршылык тудырган.

278 бәйттә «Кыз хикәяте» авторы элекке әсәрдәге юлларга «айвай» ымлыгын кертеп, эчтәлеккә тагын да җанлылык өстәгән.

301 бәйттә Ибраһим әсәрендәге күгәрченнең кулын (әлен) һәм аягын бәйләү турындагы юлларга «Кыз хикәяте» авторы, кошка карата «кул» сүзе куллануны урынсыз күрептер, «аягын» дигән сүзне генә калдырган.

327 бәйттә Ибраһим әсәрендәге «бончалайын» (мондый, моның кебек) сүзе «Кыз хикәяте»ндә «бунуң кеби галим» дигәнгә үзгәртелеп, егетнең галимлеге игътибар үзәгенә куелган.

339 бәйттә Ибраһим әсәрендәге яшь солтанның бәкләр белән идарә итү мәгънәсендәге юллары «Кыз хикәяте»ндә илләр белән идарә итүе, ягъни киңрәк хакимлеккә ия булуны тасвирлый. Шул ук бәйттә әүвәлге әсәрдә солтанның байларга-юксылларга гадел булуы турындагы сүзләрнең «Кыз хикәяте»ндә «юксыллар» дип кенә калдырылуы да очраклы түгелдер.

348 бәйттә Ибраһим әсәрендә солтанга бөтен бәкләрнең буйсынуы турында әйтелгән булса, «Кыз хикәяте»ндә солтанга барлык галимнәрнең буйсынуы белдерелгән. Ягъни, «Кыз хикәяте» авторы максатчан рәвештә ил-дәүләт хакименең галимлеген – тирән белемгә ия зирәк зат булырга тиешлеген ассызыклавы күренеп тора.

Чагыштырма таблицадагыдан тыш, тагын берничә мисалны өстәп әйтик. 1382 елгы текстта 161 бәйттә «ите-тәне йуқ» дигән гыйбарә «Кыз хикәяте»ндә «ите-қаны йуқ» буларак язылган.

Ибраһим әсәрендә кол-каравышлар кыз сараена куйумчы (ювелир) килгәнне күргәнлекләренә таныклык биргән булсалар, «Кыз хикәяте»ндә (326 бәйттә) алар ике йөзекнең төрле булуына шаһитлек итәләр. Шуннан соң 1382 елгы әсәрдә язылган:

Падишаһ сүкде, диде: «Қызый!
Нәчә монча рисвай идәрсән бези?!

Нәчә кэсәрсән йегетләр башыни,
Ақдурурсән анларый күз йәшени?!

– дигән һәм бүтән юллар «Кыз хикәяте»ндә юк.

Менә бу китерелгән мисаллар Ибраһим әсәренең сакланган 154 бәйтенә генә бәйле булуын искә төшерик. Ул поэманың әле хәзергә билгесез калган 266 бәйтендә дә «Кыз хикәяте» текстыннан аермалары шактый булганлыгын чамалап була.

«Кыз хикәяте» Ибраһим поэмасына нәзыйрә рәвешендә иҗат ителгәнгә, башка бер авторның тулаем үз оригиналь әсәре булмаганга

күрәдер, аны язган каләм иясе әсәрнең ахырында исемен һәм язылу датасын белдерүне кирәк тапмагандыр дип фаразларга мөмкин.

Хикәятнең лексик составы һәм кулъязма күчермәләренең палеографик үзенчәлекләренә күрә, аның иҗат ителү вакытының гомуми чикләрен XV гасыр башыннан алып XVI гасырның уртасына кадәрге арада язылган дип билгеләп була.

## Авторы кем икән?

Бу әсәрнең авторы кем булу мәсьәләсен төгәл ачыклау бик катлаулы, аны фаразлап кына әйтергә мөмкин. «Кыз хикәяте» үзенең шигъри үзенчәлекләре, фикер сөреше ягыннан Мөхәммәдьяр әсәрләренә шактый якын тора. Моңа дәлил булырдай берничә мисалга гына тукталабыз.

«Кыз хикәяте»нең «Бер хикайәт кәлде, әйдәм, дилимә» дигән иң беренче юлы ук Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасының 247 бәйтендәге «Бер хикайәт килде күңлемгә нәзыйр» дигәненә бик охшаш. («Кыз хикәяте»ндәге «дилимә» сүзе «күңелемә» дигәнне белдерә). Мөхәммәдьярның шул ук әсәрендәге 293 бәйттә «Бер хикайәт килде йадга дилпәзир» һәм 410 бәйттә «Бер хикайәт килде йадга уш нәзыйр» дигән шигъри юллары[57] да боларга бик охшаш.

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасындагы аерым шигъри юлларның «Кыз хикәяте»нә охшаш булган берничәсен түбәндә күрсәтеп китәбез.

| ***«Кыз хикәяте»ндә (Татарстан Милли китапханәсе, «1764 т» шифрлы кулъязма)*** | ***Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь. (Казан: Татар. китап нәшр., 1997) китабында*** |
|---|---|
| *35 бәйт* | *413 бәйт* |
| Солтанә хуш кәлде чөн сөйләдеге | Шаһга хуш килде аның бу сүзләри |
| *89 бәйт* | *587 бәйт* |
| Кэчде йегет, сандал үзрә утырур | Үзе алтун сандәлида ултуруб |
| *317 бәйт* | *489 бәйт* |
| Әйдер остад: «Ғәйебләмәңез бәни?» | Ғәиб қылмаңыз бу сүздә сез мәни |

Болардан алдагы ике юлны шагыйрь Ибраһим әсәре белән чагыштырып карау мөмкин түгел, чөнки ул әсәр язылган кулъязма текстта

[57] Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь. – Казан: Татар. китап нәшр., 1997. – Б. 55, 58, 67.

аның башлангыч өлеше сакланмаган. Ә таблицадагы өченче мисалга килсәк («Кыз хикәяте»нең 317 бәйте), Ибраһим әсәрендә 316 һәм 318 нче бәйтләргә аваздаш юллар булган хәлдә, 317 нче бәйткә туры килердәе бөтенләй юк.

«Нуры содур» поэмасында шаһның хакимлекне вәзиренә тапшыруын бәйан иткән 414 нче бәйтендәге

Чөн аның гақиллыгыны белде ул,
Мәмләкәтне аңа тәслим қылды ул,

– дигән юллары «Кыз хикәяте»ндәге солтанның үз тәхетен зирәклеге белән дан казанган егеткә тапшыруына бик охшаш. Сүз уңаеннан искәртик, Мөхәммәдьяр әсәрләрендә бер үк затка карата *падишаһ–-шаһ–солтан* сүзләре параллель кулланылган булса, «Кыз хикәяте»ндә дә шундый ук күренеш белән очрашабыз.

Мәшһүр шагыйрь Мөхәммәдьяр «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларында «егет» һәм «ишет» сүзләрен гомумән һәм рифма өчен дә күп кулланган. Шунысы игътибарга лаек, аңа кадәр төрки телләрдә иҗат иткән төрле авторларның шигъри әсәрләрендә бу сүзләрнең рифма пары булып килгән очраклар аз. «Егет» һәм «ишет» сүзләренең рифмалашуы Ибраһим әсәрендә ике урында очрый, ә «Кыз хикәяте»ндә аларны өч бәйттә күрәбез. Шулардан 331 нче бәйт Ибраһим әсәрендә бөтенләй юк.

«Уш» һәм «хуш» сүзләренең рифмадаш буларак һәм, гомумән, күп кулланылуы Мөхәммәдьярда һәм «Кыз хикәяте»ндә бер дәрәҗәдә диярлек.

«Кыз хикәяте»нең 53 нче бәйтендәге

Бер моғәззам шәһәр иде, йаулақ олу,
Хуш абадан, эче – адәм туб-тулу,

– дигән юллар Мөхәммәдьярның мәшһүр булган

Бер гаҗиб бу шәһәрнең эче тулуг:
Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг,

– юлларына аваздаш.

«Кыз хикәяте»ндәге солтанлыкка ирешкән егетнең гыйлемлеге, сабырлыгы, гаделлеге кебек сыйфатлар Мөхәммәдьярның моңарчы билгеле булган әсәрләрендә макталганын да искә төшерик. Ягъни, «Кыз хикәяте»нең идеясе дә Мөхәммәдьяр иҗатына бик якын тора.

Әсәрнең идеясе дигәч, тагын бер фикер килә. «Нуры содур» поэмасында идеал хөкемдарда Мөхәммәдьяр күрергә теләгән ун сыйфат (ягъни, гаделлек, рәхим-шәфкать, юмартлык, сабырлык һ.б.) тасвир-

ланган. Тик алар арасында «гыйлемлелек» турында аерым язган бүлекчә юк. Шунлыктан, бәлки Мөхәммәдьяр бу сыйфатның әһәмиятен аңлатып аерым әсәр («Кыз хикәяте»н) иҗат иткәнлектән, «Нуры содур»да гыйлемнең дәрәҗәсе турында бүлек итеп зурлап язмагандыр дип тә фаразларга мөмкин.

Казан университетының фәнни китапханәсендә саклана торган бер үк кулъязмада «Кыз хикәяте» белән Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасының булуы, шулай ук Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган кулъязма җыентыкта Хаҗи Мәхмүднең «Мигъраҗ» әсәре белән бер үк җыентыкта «Кыз хикәяте» тексты булуы да игътибар уңында тотылырга тиешле. Ягъни, бер чор-дәвер әсәрләре кулъязма җыентыкларда бергә язып йөртелгәнлеге авторлык мәсьәләсен ачыклаганда да исәпкә алынырга зарур фактлардан.

«Кыз хикәяте» әсәренең авторы кем булу турында монда язган дәлил һәм фикерләребезне фараз буларак белдердек. Бу мәсьәлә, махсус рәвештә тагын да җентекләп өйрәнүне һәм киңрәк анализ ясауны таләп итә.

«Кыз хикәяте» поэмасының авторы Мөхәммәдьяр дип киләчәктә тәгаен расланса, бу – татар әдәбияты тарихы өчен, һичшиксез, зур яңалык булыр. Ә Мөхәммәдьярның моңарчы билгесез әсәрләре ачыклану эзләнүләр һәм табышлар өлкәсендә гайре табигый күренеш булмас иде. Чөнки археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә моңа хәтле билгесез булып килгән әдәби ядкәрләр табылып тора. Бу мәсьәләдә әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов болай дип язган иде: «Без озак еллар буе Мәүла Колыйны хикмәтләр авторы дип кенә белдек. Әле күптән түгел генә аның поэма жанрына туры килешле ике әсәре табылды (Казан утлары. – 1996. – №10. – Б. 159–171). Шуның кебек, Мөхәммәдьярның да моңа кадәр фәнгә билгесез әсәрләренең табылуы бик ихтимал. Бары эзләнүләрне дәвам итәргә генә кирәк»[58].

***

Бу китапны басмага әзерләү дәвамында аерым мәсьәләләрне ачыклауда ярдәмләшкән өчен Татарстан Милли китапханәсенең директор урынбасары Ирек әфәнде Һадиевка, китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәре Равил әфәнде Бикбаевка ихлас рәхмәтләребезне юллыйбыз.

[58] Миңнегулов Х. Дөньяда сүземез бар... – Казан: Татар. китап нәшр., 1999. – Б. 89.

# ХИКӘЯТНЕҢ
# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ЯЗУЫНА
# КҮЧЕРЕЛМӘСЕ

## ҠЫЗ ХИКАЙӘТЕ

*49а кәгазь*

Бер хикайәт кәлде, әйдәм, дилимә,
Ошбу сүздә файда вардур ғалимә.

Һәркем ғилем илә даим дорыша –
Һич гөман йуқ – соңра ғилем ирешә.

Һәркем ул остазны хушнуд идә,
Ля җәрәм, хур улмайа ул дөнйада.

Ишет имди, бер хикайәт ки, ширин,
Дыңлайанлар очтмаға керсүн йәрин.

Бар ирде кичмеш заманда бер хуҗа,
Белмәз эде йуқсузлық хале нәчә.

Дөнйалеге[1] чуғ иде ул хуҗануң,
Кемсәйә мохтаҗы йуғиде ануң.

Ул хуҗаның вар иде бер ғыйали,
Ғалим иде һәм фәсыйх иде дели.

---

[1] Кулъязмада бу сүз язылмаган. Монда Казан университеты китапханәсендә саклана торган кулъязма текстыннан алып өстәдек.

*кәлде* – килде; *дилимә* – күңелемә; *вардур* – бардыр; *ғалимә – галимгә; дорыша – шөгыльләнсә; соңра* – шуннан соң; *хушнуд* – канәгать, шат; *идә* – итә; *ля җәрәм* – шиксез, әлбәттә; *улмайа* – булмас; *ширин* – күркәм кеше; *дыңлайанлар* – тыңлаганнар; *очтмаға* – оҗмахка; *йәрин* – киләчәктә; *ирде* – иде; *кичмеш* – үткән; *хуҗа* – бай, сәүдәгәр, укымышлы, зур дәрәҗәле кеше; *белмәз эде* – белмәс иде; *йуқсузлық* – юксызлык, фәкыйрьлек; *хале нәчә* – хәле ничек; *чуғ* – күп; *кемсәйә* – кешегә; *йуғиде* – юк иде; *вар* – бар; *ғыйали* – улы; *фәсыйх* – матур; *дели* – теле.

Холқы ләтыйф, күреклү иде сурәте,
Һәм күрке ляиқ эде сийәрәте.

Хуш ғилем вирмеш иде Аллаһ аңа,
Хак үгәрүр – һәркем қалурса таңа.

Бер заман кәлде ки йуқсузлуқ – бөлделәр,
Мөфлислекдән шөйлә хәйран қалдылар.

Бер сағәт – вар икән, бер дәм – зар улур,
Бер сағәт – тарлығ вә бер дәм – вар улур.

Шул қәдәр әксиклек улды ул хужа,
Бер әвен булмаз йийәр[гә] кэчә.

Уғылы әйтде: «Кәтде, баба, малымыз,
Уш күрәрсән – дөшвар улды халемез.

Дошманымыз бонда көләнчә безем,
Йөрийәлем, сыналым, ғәзизем.

Бер ылық шәһәргә без варалум,
Анда дәхи Хақ нәдүр – без күрәлүм».

Ата-ана аны сәбәб күрделәр,
Торубән, йула керүб китделәр.

---

*ләтыйф* – йомшак, күркәм; *күреклү* – күркәм, матур; *эде* – иде; *сийәрәт* – әхлак; *вирмеш* – биргән; *Хақ* – Аллаһ; *үгәрүр* – сөяр, мәрхәмәт кылыр; *қалурса таңа* – таңга калса; *мөфлислек* – бөлгенлек, мохтаҗлык; *шөйлә* – шундый; *дәм* – вакыт; *вар икән* – булса; *улур* – булыр; *тарлығ* – тарлык, читенлек; *әксик* – ким-хур, мохтаҗ; *әвен* – ашлык бөртеге, орлык, җимеш; *йийәргә* – ашарга; *кэчә* – кич; *кәтде* – китте; *баба* – ата; *уш* – менә, хәзер; *күрәрсән* – күрәсең; *дөшвар* – читен, авыр; *бонда* – монда; *көләнчә* – көлгәнче; *йөрийәлем* – йөрик; *сыналым* – сынап карыйк; *ылық* – бай, бәрәкәтле; *варалум* – барыйк; *дәхи* – тагын; *нәдүр* – нишләтер; *күрәлүм* – күрик; *торубән* – торып; *йула* – юлга.

*49б кәгазь* Кидә-кидә кәлделәр бер хуш шәһәрә,
Кемсә белеш ки йуқ, қатына вара.

Мөфлис иде һәм ғәриб иде болар.
Ғәриблекдә[2] мөфлис улма[ңы]з, әй, йар!

Өч көн, өч кэчә шәһәр[д]ә қалдылар,
Мөфлислекдә шөйлә ғаҗиз қылдылар.

Өч көндә бер нәмәрсә йимәделәр,
Сабыр этделәр, кемсәйә димәделәр.

Тәнләре йаулақ бөгүлде. «Ғәзыйм! –
Диделәр кем, – Сән үгәрғыл, йа, Қәдим!»

Торды йегет, күр, нә дир атасына –
«Бер фикер дөшде үгүмә уш йәнә.

Бонда ачлық һәляк идәнчә бези,
Кәлүң, маликкә сатам икегүзи.

Ач хуҗа уланча, туқ қол улуңуз,
Сез нә дирсез? Беләйен[3] уш қәүлүңүз».

Ата, ана бу сүзә разый улур,
Алубән йегет бонлари шәһрә кәлүр,

---

[2] Кулъязмада: ғәриблыкда.
[3] Кулъязмада: бөйләдүр.

*кидә-кидә* – бара торгач; *шәһәрә* – шәһәргә; *вара* – бара; *гәриб* – ярлы; *улмаңыз* – булмагыз; *кэчә* – төн; *шөйлә – шундый; нәмәрсә* – нәрсә; *йимәделәр* – ашамадылар; *димәделәр* – әйтмәделәр; *йаулақ* – бигрәк, бик нык; *Ғәзыйм* – Бөек (Аллаһ Тәгаләнең күркәм исеме); *сән – син; үгәрғыл* – мәрхәмәт кыл; *Қәдим* – Борынгы (Аллаһ Тәгаләнең күркәм исеме); *дөшде* – төште; *үгүмә* – уема, башыма; *идәнчә* – иткәнче; *бези* – безне; *кәлүң* – кил; *малик* – патша, солтан, хан; *икегүзи* – икегезне; *уланча* – булганчы; *улуңуз* – булыгыз; *беләйен* – белим; *қәүлүңүз* – сүзегез; *сүзә* – сүзгә; *алубән* – алып; *бонлари* – боларны; *шәһрә* – шәһәргә; *кәлүр* – килер.

Хуш ғибадәт илә доғалар әйләде,
«Бер қолум вар, бер қаравышум», – дэде. –

«Қаравышум қарый, хужадур – қолум,
Йуқсул улдум, сатарам. Күр бу халүм!»

Солтан әйдүр йегетә: «Ғәҗәб сүзүң,
Тануқлықдур кәндү-кәндүңә үзүң.

Сән әйдүрсән бонлари қарый-хуҗа,
Бонлары сәндән кем ала, әй, хуҗа?»

Йегет әйдүр: «Тәңре өчүн, [ал] бонлари,
Үләрләр, буйнуңа дөшәр қанлари.

Бер пулум йуқдур бәнем, нә бонларуң.
Ғөмере артсун һәмишә солтанларың!»

Падишаһ әйдүр: «Исергярдем, йегет,
Нә деләрсән, имди бәһасен әйт?!»

Йегет әйдүр: «Хуҗа бәһасенә – ат,
Қарыййа – тунлар кәрәк, әй, хуш нәһад».

*50а кәгазь* (Атны, тунны алды. Морады күр, нәфәқа!)
«Тәңре сәнүң ғөмреңне қыйлсун бәқа!»

---

*әйләде* – кылды; *қаравыш* – хезмәтче; *қарый* – карт хатын-кыз; *йуқсул улдум* – фәкыйрьләндем; *тануқлық* – шаһит; *кәндү-кәндүңә* – үз-үзеңә; *буйнуңа* – муеныңа; *дөшәр* – төшәр; *пулум* – вак бакыр акчам; *һәмишә* – һаман; *солтанларың* – солтаннарның; *исергярдем* – кызгандым; *нә деләрсән* – ни теләсәң; *имди* – инде; *қарыййа* – монда: карчыкка; *кәрәк* – кирәк; *тун* – кием; *хуш нәһад* – яхшы холыклы; *морады* – максатын; *нәфәқа* – сәүдәсе унды; *бәқа* – мәңгелек.

Солтанә хуш кәлде чөн сөйләдеге,
Вирәләр нә нәснәдүр теләдеге.

Йегет киде тунлары, бенде атына,
Бонлары керде солтан[4] қатына.

Ул икесе солтана қол улдылар,
Йимәк-кимәккә бул улдылар.

Дәстүр улды йегетә – торды, кидәр.
Тәңре атын телендә зикер идәр.

Йөз орды, ғәриблеқ йулынча кидәр.
Күргел имди – Хақ Тәғалә нәләр идәр!

Йулда күрде нәгяһ, бер атлу кәлүр[5],
Аты чабар, кәнде һәйбәтлү кәлүр.

Йақын кәлде йегеткә, орды сәлям,
«Ғәләйкә» – алды йегет, сөйләде кәлям.

Йегет әйдүр: «Нә эшүң вардур қаты?
«Кем дирләр сәнгә сорарсән бу аты?»[6]

Йегет әйдүр: «Шунда қалаға варам
Кем, бәгенә ошбу мәктүбе[7] вирәм».

---

[4] Кулъязмада: солтан керде.
[5] Кулъязмада бу сүз «көлүр» дип, хаталы язылган.
[6] Кулъязмада бу юлдагы сүзләр начар танылa.
[7] Кулъязмада «мәктүбе» сүзенең ахырындагы «е» хәрефе язылмаган.

*кәлде* – килде; *чөн – өчен; сөйләдеге* – сөйләгәне; *нә нәснәдүр* – ни нәрсәдер; *бенде* – менде; *йимәк* – ашау; *бул* – хак, товар; *дәстүр улды* – рөхсәт булды; *йегетә* – егеткә; *зикер идәр* – кабатлар; *ғәриблеқ* – ярлылык; *күргел* – күр; *нәләр идәр* –ниләр итәр; *нәгяһ* – кинәт; *атлу кәлүр* – атлы килер; *һәйбәтлү* – мәһабәт; *кәлям* – сүз; *мәктүбе* – хатны.

Йегет әйдүр: «Кәлтүр, бән илтәм аны,
Ул йәйгәдүр бәнүм атумнуң йулы».

Доға қылды, мәктүбе[8] вирде аңа,
Дүнде кирү кәнде кәлдеке йәйгә.

Йегет әйдүр: «Мәктүбе арайын,
Нә йазылмыш эченә – бер күрәйен».

Ачды уқыды бөти[йе] йулда,
Йазмышлар: «Һәркем бөти қалаға илтә,

Бөти[йе кем] вирәчәк – кәсең башын,
Анда фәсыйль әйләң аның һәм эшен!»

Чөн йегет уқыды – белде аный,
Әйтде: «Күр ки, нәйләде Йәзидем ул бәни?»

Ару кәлмичә, кидәрде бу башум,
Хақға шөкер, кәндү үгәрде эшем.

Варса идүм қалаға – үлүр идем,
Ачмасайдем бөти – нә белүр идүм?

*50б кәгазь* Шөкер эдүбән кидәрде йул эчрә,
Кидә-кидә йул эрде бер шәһәрә.

---

[8] Кулъязмада «мәктүбе» сүзенең ахырындагы «е» хәрефе язылмаган.

*кәлтүр* – китер; *йәйгәдүр* – якка, тарафка; *дүнде кирү* – китте кире; *кәнде* – үзе; *кәлдеке йәйгә* – килгән якка; *арайын* – карыйм, тикшерим; *нә йазылмыш* – ни язылган; *күрәйен* – күрим; *бөтийе* – язуны; *вирчәк* – биргәч; *кәсең* – кисең; *фәсыйль әйләң* – бетер; *чөн* – кайчан; *нәйләде* – нишләтте; *Йәзидем* – Аллам; *бәни* – мине; *ару* – яхшы; *кәлмичә* – килмичә; *кидәрде* – китәр иде; *үгәрде* – рәхим кылды; *варса идүм* – барган булсам; *ачмасайдем* – ачмаса идем; *эдүбән* – итеп; *йул эчрә* – юл буенча, юл белән; *эрде* – иреште.

Бер моғәззам шәһәр иде, йаулақ олу,
Хуш абадан, эче – адәм туб-тулу.

Дүрт йаны сулаб ақар хуш бағчалар,
Пул йиренә анда йөрүр акчалар.

Күрде – бөрждә асылан адәм баши.
Ғәҗәбләде, таңлады ул бу эши

Кем: «Бу башы нәйә кәсмешләр өйлә,
Бу қәлғә бөрженә асмышлар ула?

Һәлә бер қонуқ йирне күрәйен,
Андан соңра бу сөале[9] сорайын».

Кәлде йегет бер қарыйчық әвенә,
Әйтде: «Қонуқ алурмусән, и, ана?»

Ул қарыйнуң бер уғылы улмыш иде,
Фирақы хатередә қалмыш иде.

Күрәнчә ки ул йегете, қайнар қаный:
«Кәл бэрү, баш өстүнә, уғул җаный!»

Кэчде йегет, анда қарар әйләде,
Қарыййә «ана» дәйү сөйләде,

[9] Кулъязмада «сөале» сүзенең ахырындагы «е» хәрефе язылмаган.

*моғәззам* – бөек, әһәмиятле, хөрмәтле; *йаулақ* – бик; *хуш абадан* – бик төзек, мәдәни; *ақар* – агар; *бағча* – бакча; *йиренә* – урынына; *бөрҗ* – манара; *асылан* – асылган; *таңлады* – таң калды; *нәйә* – нигә; *өйлә* – шулай; *қәлғә* – кирмән, крепость; *ула* – бәйләп; *һәлә* – ниһаять, әле, башта; *қонуқ йир* – төн куну урыны; *күрәйен* – күрим; *соңра* – соң; *сөаль* – сорау; *сорайын* – сорыйм; *әвенә* – өенә; *алурмусән* – алырсыңмы; *улмыш* – булган; *фирақ* – аерылу; *хатередә* – хәтерендә; *күрәнчә* – күргәч; *кәл бэрү* – кил бире; *кэчде* – узды; *қарар әйләде* – урнашты; *қарыййә* – карчыкка.

Әйтүр кем: «Бөрждә туб-тулу адәм баши,
Нәдән үтүрде, асмышлар? Иблис эши?»

Қарый әйдүр: «Бу шәһәрүң маликнең
Бер қызы вар, һич кемсәгә[10] йуқтур кәрәге аның.

Кәй ғалимдер – кемсә аны йиңмәз,
Мәсьәләнүң җавабын һичкем вирмәз.

Күк алында ул қызыйның мисле йуқ,
Ғашиқлар улды шәһәрдә аңа чуқ.

Ничә малик, солтанларның ғыйалы,
Кәлтүрүрләр һәрбере йөк-йөк малы.

Разый улмаз қыз боларуң малына.
Қайғурур һәр көн атасы әленә.

«Һәркем деләрсә бәне алмаға,
Кәлсүн, белсүн мәсьәләм җавабын сормага.

*51а кәгазь* Кем белсүн мәсьәләм – алсун бәни,
Белмәз исә – кәндү буйнында қаный».

Анча кем шаһзадә кәлмеш дорур,
Бу қыз анлара сөаль сормыш дорур.

---

[10] Кульъязмада: кемсәдә.

*туб-тулу* – туп-тулы; *нәдән* – нидән, ник; *шәһәрүң маликнең* – шәһәр патшасының; *кәй ғалим* – бик күп белүче; *йиңмәз* – җиңмәс; *күк алында* – күк йөзендә, дөньяда; *чуқ* – күп; *ғыйалы* – улы; *кәлтүрүрләр* – китерерләр; *әле* – эше, гамәле; *деләрсә* – теләсә; *алмаға* – алырга; *кәлсүн* – килсен; *бәни* – мине; *қаный* – каны; *анча* – күпме генә, ничаклы; *шаһзадә* – шаһ улы; *кәлмеш дорур* – килеп торыр.

Хикайәт бу д[ор]ур ул башларуң,
Хақ қулай кәлтүрсүн сәнүң[11] эшләрүң!»

Чөн бу йегет ошбу сүзе хуш дыңлады,
Ғәҗәбә қалды бу эшә, таңлады.

Әйдүр: «Ана, дәстүр виргел, бән дәхи
Қыз қатына варырум, Тәңре хақый?

Без дәхи ануңлә бәхәс идәрәм,
Алнума [нә] йазылмыш – күрүрәм.

Инша Аллаһ кем, йиңәм, аны алам,
Йә йиңмәсәм, бән дәхи тәслим улам».

Қарый әйдүр: «Тәңре өчүн, җаным, уғул!
Бу фикере хатереңдин қуйғыл!

Кемсә башына чықмады бу қыз иллә,
Нә ғилме илә, нә худ қоры сүз илә».

Йегет әйтүр: «Һәлә, варурым, ана!
Ише бетүрмәз һәркем үлүм сана».

Қарый әйдүр: «Хақ қыла сәңа мәдәд,
Йаричың улсун сәнең Фәрд-ү-Әхәд!»

Килде йегет солтаннуң қапусына,
Күрде кем, қоллар тормыш тапусына.

---

[11] Бу сүз кульъязмада سونك (сүң) рәвешендә хаталы итеп язылган.

*чөн* – кайчан; *ғәҗәбә* – гаҗәпкә; *дәстүр виргел – рөхсәт бир; дәхи* – тагын; *варырум* – барырмын; *ануңлә* – аның белән; *идәрәм* – итәрмен; *алнума* – башыма; *йиңәм* – җиңәм; *тәслим улам* – җиңеләм, һәлак булам; *қуйғыл* – куй; *иллә* – мәгәр; *илә* – белән; *нә* – ни; *худ* – үзе; *һәлә* – ниһаять; *ише бетүрмәз* – эш бетермәс; *сана* – уйлый, фикерли; *мәдәд* – ярдәм; *йаричың улсун* – ярдәмчең булсын; *Фәрд-ү-Әхәд* – бердәнбер һәм тиңдәшсез (ягъни, Аллаһ); *қапусына* – капкасына; *тапусына* – каршына.

Дәстүр улды – керде солтан қатына,
Сөйләде кәндүе шул дәм йатына.

Әйтде: «Шаһа! Дәстүр улса безә,
Без дәхи сөйләйү килдүк бу қыза.

Ғилем илә, хәдис илә, тәфсир илә,
Сөйләшәлүм икебез анда билә».

Солтан әйдүр: «Қаныңа кермә, йегет!
Белмәз ирсәң, үлдүрүрем, сүзүм ишет!»

Йегет әйтүр: «Разыйым бән бу қәүлейә,
Хәбәр әйләң – варалум ул сарайә».

Хәбәр итделәр шул сағәт қыза,
Ул қыз әйтүр: «Аны кәтерүң безә!»

*51б кәгазь* Чаучылар ул йегете кәтэрүр,
Қыз дәхи сарай эчендә утырур.

Қордылар бер қызыл алтун сандали,
Ул қызуң һәрбер сүзе, уғул, бали.

Кэчде йегет, сандал үзрә утырур,
Пәнҗәрәдән қыз ниқабын кәтерер.

Ул йегет фикер әйләде кәндүзенә –
Гәр бақарсам бу нигярнең йөзүнә,

---

*дәм* – вакыт; *йатына* – чит кешегә; *шаһа* – и, шаһ; *безә* – безгә; *сөйләйү* – сөйләргә; *қыза* – кызга; *сөйләшәлүм* – сөйләшик; *билә* – бергә; *үлдүрүрем* – үтерермен; *разыйым* – ризамын; *қәүлейә* – сүзеңә; *хәбәр әйләң* – хәбәр ит; *сарайә* – сарайга; *кәтерүң* – китер; *чаучы* – кычкырып халык җыючы; *сандали* – култыксалы йомшак урындык, кресло; *бали* – тирән мәгънәле; *сандал үзрә* – сандалига; *пәнҗәрә* – тәрәзә; *ниқаб* – пәрдә; *кәтерер* – ачар; *гәр бақарсам* – әгәр карасам; *нигяр* – сокландыргыч, табыну дәрәҗәсендә сөекле.

Күңлүме ала, бәне дәлү қыла.
Дәлү улан мәсьәлә қачан белә?

Йегет әйдүр: «Йа, нигярин, өрүт йөзүң,
Рәва дәгел бәңа күрсәтмәк йөзүң.

Шәреғ илә хәрамдур бақмақ сәнгә,
Йөзүң өрүт! Кил, мәсьәләң сорғыл бәнгә!»

Бер салават әйдәлүм Мөхәммәдкә,
Хақ ғинайәт әйләйә ул йегетә.

Қыз әйтүр: «Элүк сөалем будур сәнгә,
Нәнүң эчендә торурсән? Ди бәнгә!»

Йегет әйдүр: «Әзбәрүмдүр бу бәнүм,
Тыным эчендә торурым, әй, җаным».

Ул қыз әйдүр: «Ул нәдер, сән әйт,
Кем су өчүн орышур бәллү сабит?»

Йегет әйдүр: «Ул балықдур ғайан,
Кем су өчүн орышур, бәллү бәйан.

Диңез эчрә балығ улур тағ кеби,
Шөйлә йөрүр – көймә илә йағ кеби».

Дүнде қыз, әйдүр аңа: «Пөрһөнәр!
Су ичендә батты, қырық көн қылды зар?»

---

*дәлү* – мәҗнүн; *улан* – булган; *қачан* – кайчан; *нигярин* – чибәр кыз; *өрүт* – капла; *рәва дәгел* – ярамый, мәгъкуль түгел; *бәңа* – миңа; *шәреғ илә* – шәригать буенча; *сәнгә* – сиңа; *сорғыл* – сора; *бәнгә* – миңа; *әйдәлүм* – әйтәм; *ғинайәт әйләйә* – ярдәм итә; *нәнүң* – нәрсәнең; *ди бәнгә* – әйт миңа; *әзбәрүмдүр* – күңелем, җаным; *тын* – җан, рух; *бәллү* – чынлап, шиксез; *сабит* – даими; *ғайан* – билгеле, ап-ачык, тәгаен; *бәйан* – монда: әйтәм; *эчрә* – эчендә; *тағ кеби* – тау кебек; *шөйлә* – шулай; *йағ* – яу; *дүнде* – кәефе китте, йөзе караңгыланды, чикте; *пөрһөнәр* – һөнәр иясе, оста; *ичендә* – эчендә.

Йегет әйдүр кем: «Йунысдур ул байық,
Кем аны йотмышде қырық көн балық».

Ул қыз әйтүр кем: «Нәдүр, әй, паке дин,
Күрде сәйэә[12], күрмәде гүр ғазабин?»

Йегет әйдүр: «Ул Әйүбдүр бигөман,
Унсикез йыл сабыр этде ул заман.

Унике бең қорт тәнене йийәрде,
Кем йиде, сөнәсене[13] қалдурды».

*52а кәгазь* Ул қыз әйтүр: «Әй, йегет, биргел хәбәр,
Дүрт нәснә анадин туғмадылар?»

Йегет әйдүр: «Бере – Адәм атамыз,
Икенчесе, бәллү, Хауа анамыз.

Исмәгыйль қучқарыдур ул өчүнчесе,
Ул бере дәхи – Салих тәвәсе».

Ул қыз әйтүр: «Тэз хәбәр виргел бәңа,
Ул нәдер кем, бөһтан этдиләр аңа?»

Йегет әйтүр: «Йосыфның қәрдәшләри.
Салчақ чаһийә Йосыф пәйғамбәри,

Кәлделәр аталарына, дэделәр
Бөһтан эдеб: Қорт йиде, – дэделәр».

[12] Кулъязмада: سنه (сәнә, синә).
[13] Кулъязмада «сөнәсене» сүзенең ахырындагы «е» хәрефе язылмаган.

*байық* – ачык, анык; *паке дин* – изге дин әһеле; *сәйэә* – яманлык, газап; *Әйүбдүр* – Әюптер; *бигөман* – шиксез; *этде* – итте; *йийәрде* – ашар иде; *сөнә* – җан; *биргел* – бир; *нәснә* – нәрсә; *қучқар* – тәкә; *тәвә* – дөя; *бөһтан этдиләр* – ялганладылар; *салчақ чаһийә* – коега салгач; *эдеб* – итеп; *қорт йиде* – бүре ашады.

Чөн қыз әйтүр: «Ул нә қәвемдер, йара,
Уникейде килчәк анлар шәһәрә

Кем, чықачақ алты йөз бең улдылар?»
Йегет әйтүр: «Бу ки кәздер, әй, нигяр!

Йаґқуб кәлде унбер уґлыйлә Мисра.
Кәлде кем, уґылы Йосыф йөзен күрә.

Соңра алты йөз бең улуб чықдылар
Кем, морадына тигделәр улар».

Кичәйә диген йегет вирде җаваб,
Һич йиңелмәде қыза, вирде хисаб.

Қыз әйдүр кем, күңлендә, «бу намидар –
Һәр нә кем сордым эрсә – вирде хәбәр.

Әй, дәриґа, бу бәне йиңмә иде,
Бу мәнем серремә адәм сыймас иде».

Ул қыз әйде: «Бу көн қортулдуң, сыйлә.
Тыңла – қылам бән сәңа дөрлү[14] бәля!»

Йегет әйдүр: «Ул Кәрим Аллаһ бүгүн
Йари[15] қылды қолуна, ачды үгүн.

---

[14] Кульъязмада «дөрлү» сүзе ике мәртәбә язылган.
[15] Кульъязмада: йарин.

*чөн* – шуннан соң; *йара* – и, дус, сөеклем; *килчәк* – килде; *чықачақ* – чыгачак; *ки кәздер* – шулдыр ки; *уґлыйлә* – угылы илә; *Мисрә* – Мисырга; *соңра* – шуннан соң; *улуб* – булып; *морад* – максат; *тигделәр* – ирештеләр; *улар* – алар; *кичәйә диген* – кичкә (төнгә) хәтле; *намидар* – шөһрәтле; *сордым эрсә* – сорасам да; *дәриґа* – үкенеч; *йиңмә* – җиңә; *сыймас* – белмәс; *қортулдуң* – котылдың; *сыйлә* – кардәш, туган; *дөрлү* – төрле; *Кәрим* – Юмарт (Аллаһ Тәгаләнең күркәм исеме); *йари қылды* – ярдәм итте; *үгүн* – мәрхәмәтен.

Йәрен дәхи һәм йәнә қылғай йари».
Халық қаму ғәҗәбләде ул дилбәри.

Ул йегет торды йирендән. Сөйенә.
Кәлде йәнә ул қарыйчуқ өйенә.

Қарый әйде: «Нәчүк қортулдуң, җаным?
Атым җаным эреде бонда бәнүм».

*52б кәгазь* Йегет әйдүр: «Қыз нә кем сорды бәңа,
Әйде – вирдем җавабын бәрабәр аңа.

Шөкре Аллаһ! Ул қордарды бәни.
Нә кем сорды – бән вирдүм җавабыни».

Шад улубән йатдылар ул кэчә.
Уйқу кәлмәз ул йегетә, әй, хуҗа.

Эртә улды, йәнә кәлде күшкенә,
Ул қыз кәлде. Йегетә нәдүр йәнә!

Дәстүр улды – керде йегет эчәрү,
Ул қыз кәлде, тәхтенә кэчде кәрү.

Аваз қылды. Кемсә күрмәс йөзени.
Сөйләде ул мәсьәләләр сүзени.

Ул қыз әйдүр: «Қанқый ағачдур, вир хәбәр,
Ул ағачуң унике бодағы вар,

---

*йәрен* – иртәгә; *қаму* – барча; *ғәҗәбләде* – гаҗәпләнде; *дилбәри* – сөйкемлегә; *қарый әйде* – карчык әйтте; *нәчүк* – ничек; *бонда* – монда; *шөкре Аллаһ* – Аллага шөкер; *қордарды* – коткарды; *шад улубән* – шат булып; *кэчә* – кич, төн; *уйқу кәлмәз* – йокы килмәс; *эртә улды* – иртә булды; *күшкенә* – сараена; *нәдүр* – нишләтер; *эчәрү* – эчкә; *кэчде керү* – кереп урнашты; *қанқый* – нинди; *бодағы вар* – ботагы бар.

Дәкмә бер бодақда вардур утуз йабрақ,
Һәр беренүң иче – қара, ташы – ақ?»

Йегет әйдүр: «Ул әнкин сәһелдүр,
Ул ағачуң мәсьәлә[се] – бер йылдур,

Унике бодағы һәм унике ай,
Буны худ белүр қаму йуқсул-бай.

Һәр бодағында вардур утуз йабрақ –
Төнлә көндер: бере – қара, бере – ақ».

Қыз әйдүр: «Ул нә қошдур, әй, йегет,
Йомырдламаз, йығлар[16]? Аны әйт!»

Йегет әйдүр: «Ул йарасадыр ғайан,
Кем Ғәйса дөзде аны, бәллү бәйан».

Ул қыз әйдүр: «Хәбәр вир, әй, хуш кеши!
Хақ Тәғалә кәлямендә қач қоши

Йад қыйлыб, үгеде Қөръәндә аны?
Сөйләгел бу мәсьәләм җавабыны!»

Йегет әйдүр: «Бу сордығуң мәсьәлә,
Ул ки кәздер – ушақ уғылы белә.

---

[16] Кулъязмада: йиғырлар.

*дәкмә* – һәр; *вардур* – бар; *йабрақ* – яфрак; *иче* – эче; *ташы* – тышы; *әнкин* – ачык, ап-ачык; *сәһелдүр* – җиңел, ансат; *худ* – үзе; *қаму* – бөтен; *төнлә* – төн илә, төн белән; *йомырдламаз* – йомырка салмас; *йығлар* – елар. Монда ярканат күздә тотыла. Аның кеше кебек көлүе-елавы турында борынгы китапларда ук (мәсәлән, Рабгузида) язылган; *йараса* – ярканат; *ғайан* – ап-ачык, тәгаен; *дөзде* – ясады; *бәллү бәйан* – чынлап әйтәм; *кәлям* – сүз; *қач* – ничә; *үгеде* – мактады; *сордығуң* – син сораган; *ки кәздер* – шулдыр ки, ул турыда; *ушақ уғылы* – кечкенә бала.

Йиде қошы үгеде Қөръәндә Чәләб,
Бере – күгүрчүндер, бере – ғораб,

Бере – чәкүргә, бере – бал оруси,
Бере – һөдһөд, сәңлә, йараса берси».

*53а кәгазь* Ул қыз әйдүр: «Әй, қәндәләб!
Кем – вәхи[17] әйләде аңа Чәләб?

Ул вәхи әйләдүге адәм дәгүл,
Нә җинндүр, нә инесдүр. Нәдер ул?»

Йегет әйдүр: «Бал орысыдур ғайан,
Кем Қөръәндә үгде аны Мөстәған».

Ул қыз әйдүр йегетә: «Әй, әһле дил!
Ошбу ике мәсьәләйе дәхи бел:

Ул нә қәвемдүр кем, йалан сөйләделәр,
Ожмаға соңра алар керделәр?

Ул нә қәвемдүр гәрчәк сөйләделәр,
Тәңре әмрилә тамуйа керделәр?»

«Кем анлар сөйләделәр йалан –
Йосыфның қәрдәшләредүр ул ғайан!

---

[17] Кулъязмада (141–142 бәйтләрдә) «вәхи» дип язылысы урында ялгыш «дәхи» сүзе язылган.

*Чәләб* – Аллаһ; *күгүрчүн* – күгәрчен; *ғораб* – карга; *чәкүргә* – чикерткә, саранча; *бал оруси* – умарта корты; *һөдһөд* – һөдһөд кошы; *сәңлә (сәңәк, сиңәк)* – чебен, черки; *қәндәләб* – татлы ирен; *дәхи* – тагын; *дәгүл* – түгел; *нә җинндүр* – җен түгел; *нә инесдүр* – кеше түгел; *Мөстәған* – ярдәм көтелгән зат (Аллаһның күркәм исеме); *әһле дил* – акыл иясе; *йалан* – ялган; *ожмаға* – ожмахка; *соңра* – шуннан соң; *гәрчәк* – чын, дөрес; *тамуйа* – тәмугъка.

Аталарына йалан сөйләделәр,
Йосыфы чөн қорт йиде дэделәр.

Соңра Тәңре йарлықады анлари,
Зирә тәүбә қыйлдылар йаулақ ари.

Анлар гәрчәк сөйләде, керде уда,
Кемләрдер – аны әйдәм, әй, дәдә!

Бере – нәсранидур, бере – йәһүд,
Кем аны Қөрьәндә үгде ул Вәдүд.

Йәһүдиләр әйтделәр – бонларуң
Дине йуқдур, – дид[е], нәсраниларуң».

Ул қыз әйдүр[18]: «Ошбу Көнәшүң ине
Нә қәдәрдүр кем, әйткел, озыны?!»

Йегет әйдүр: «Йиде йөз фәрсәх[19] тәмам,
Ине-озыны Көнәшүң, әй, һөмам!»

---

[18] Кульъязмада бу сүздән соң «йегетә» сүзе язылган. Әмма аның шигъри үлчәмгә сыешмавы ялгыш язылган булуын күрсәтә.

[19] Кульъязмада «фәрсәх» сүзеннән соң «бер йығач» дигән сүзтезмә язылган. КДУ нөсхәсендә дә нәкъ шулай ук. Борынгы төрки телдә ераклык үлчәү берәмлеге «бер йыгач» – 6–7 километр чамасына тиң. (Гарәпләрдә 5,5 километрга туры килгән). Чынлыкта, иң башта «фәрсәх» сүзенә аңлатма буларак, ягъни бер фәрсәхнең – бер йыгачка тәңгәллеген белдергән бу сүзтезмә автор тарафыннан кульъязмадагы төп текст читендә язылган булгандыр. Тик кульъязманы күчерүчеләр аны төп текстның язылмыйча калган сүзләре дип кабул итеп, текст эченә керткәннәр. «Фәрсәх» һәм «йыгач» дигән атамалар белән борынгы чорда ат өстендә бер сәгатьтә үтелә торган юл арасы исәпләнгән.

*чөн* – чөнки; *соңра* – аннан соң; *зирә* – чөнки; *йаулақ ари* – бик ихластан; *уда* – утка; *дәдә* – дәрвиш; *нәсранидур* – христиандыр; *үгде* – әйтте; *Вәдүд* – яхшы бәндәләрне дөнья һәм ахирәт дәрәҗәләренә күтәрүче (Аллаһ Тәгаләнең күркәм исеме); *бонларуң* – боларның; *Көнәшүң* – Кояшның; *ине* – иңе.

Ул қыз әйдүр йегетә: «Әй, мөһтәди,
Тэз хәбәр вир, Иблисүң нәдүр ади?»

Йегет әйдүр: «Әүвәл Иблисүң ады,
Харис эде нитәккем, күкдә ады».

Ул қыз әйдүр: «[Вир] хәбәр, әй, пишқәдәм,
Кем, нэчә йәшәде атамыз Адәм?»

Йегет әйдүр: «Беңдән элле эксү йәшәди».
Йәнә әйдер[гә] мәсьәлә башлади.

*53б кәгазь* Қыз әйдүр: «Сөйләгел сән, йа, йегет,
Қач варды Кәғбәйә Адәм? Әйт!»

Йегет әйдүр: «Ул атамыз Адәм
Йитмеш гиз хаҗ әйләде ул, пишқәдәм».

Қыз әйдүр: «Ул нәдер кем, сөйләмәс,
Ите-қаны йуқ, кәндесе вирүр нәфәс?»

Йегет әйдүр: «Ул йилдер баиқ,
Кем аны Қөръәндә үгеде Халиқ.

Ашикярә бу айәт вардур бәс
Кем, Қөръәндә “вәс-собхи иза тәнәффәс”».

Ул қыз әйдүр: «Тәңре халқындан, йегет,
Кем кәрисәрдүр уда? Тэз әйт!»

---

*эде* – иде; *нитәккем* – ничек, ни рәвешле; *пишқәдәм* – укымышлы кеше; *нэчә* – ничә; *беңдән элле эксү* – меңнән иллегә кимрәк (ягъни, 950); *қач варды* – ничә барды; *Кәғбәйә* – Кәгъбәгә; *гиз* – мәртәбә, тапкыр; *кәндесе* – үзе; *вирүр* – бирер; *нәфәс* – сулыш, тын; *йилдер* – җилдер; *баиқ* – ачык, анык; *Халиқ* – барлык галәмне Булдыручы (Аллаһ Тәгаләнең күркәм исеме); *ашикярә* – ачыктан-ачык; *вардур* – бар; *бәс* – җитәрлек; *«вәс-собхи иза тәнәффәс»* – «Таң белән ант итәмен, һәркайчан суласа (ачылса)» (Коръәннең «әт-Тәквир» сүрәсе, 18 нче аять); *кәрисәрдүр* – керер; *уда* – утка, ягъни тәмугъка.

Ул йегет әйдүр: «Қабилдер әшикяр,
Кем Һабиле[20] түпәләде ул көффар».

Ул қыз әйдүр: «Таму әһле[21] нә дел дәхи?
Бу хикайәтне [имди] сән бел дәхи!»

Йегет әйдүр: «Худ буны белүр уғлан-ушақ,
Җөмлә белүр бу сүзе, санығ чақ.

Сорур ирсәң, мөшкилендән сор бәңа
Кем, эшедәнләр қаму қала таңа!

Ожмақ әһеле сөйләшүр ғәрәб делен[22],
Таму әһле[23] сөйләшүр[24] ғыйбран[25] делен».

Ул қыз әйдүр: «Кәчәдүр, вар эвеңә.
Эртә таңда җаваб виргел бәңа!»

Сәлям вирүб ул йегет торды[26] үрә,
Ул қарыйчуқ әвенә кәлде йәнә.

Қыз қаты пошуқды уғлан эшенә,
Ул кәчдә сонмады әлен ашына.

---

[20] Кулъязмада «Һабиле» сүзенең ахырындагы «е» хәрефе язылмаган.
[21] Кулъязмада: «таму әһел».
[22] Кулъязмада бу юлдагы сүзләрнең урыннары буталып, «Ғәрәб әһел сөйләшүр ожмақ делен» рәвешендә язылган.
[23] Кулъязмада: «әһле» сүзенең «е» хәрефе язылмаган.
[24] Кулъязмада «сөйләшүр» сүзеннән соң «дәхи» сүзе язылган.
[25] Кулъязмада: ғыймран.
[26] Кулъязмада бу сүз ахырындагы «ы» хәрефе язылмыйча калган.

*түпәләде* – башына сугып үтерде; *көффар* – кяферләр; *таму* – тәмугь; *нә дел* – нинди тел (ягъни, нинди телдә сөйләшер); *буны* – моны; *уғлан-ушақ* – бала-чага; *җөмлә* – бөтенесе; *санығ чақ* – гаҗәп хәл, изге эш (?); *сорур ирсәң* – сорасаң; *сор бәңа* – сора миннән; *эшедәнләр* – ишеткәннәр; *қаму* – бөтенесе; *таңа* – таңга; *делен* – телен; *ғыйбран деле* – борынгы яһүд теле; *кәчәдүр* – кич булды; *эвеңә* – өеңә; *виргел* – бир; *сонмады әлен* – сузмады кулын.

Әндишәдән уйқу кәлмәз күзенә,
Хәйран улды ул йегетүң сүзенә.

Қарый эвендә йегетә[27] улды рахәт,
Сабаха[28] диген ойыды ул хуш нәһад.

Чөн сабах улды, йәнә торды үрә.
Кәлде. Дәстүр алды. Керде ичрә.

Сәлям вирүб, шадиман утурды хуш,
Әйтде: «Дәхи нә сорарсән? Кәлдем уш.

*54а кәгазь* Ике көндүр җавабуң вирдүм сәңа,
Бу көн дәхи нә сорарсән? Ди бәңа!»

Ул қыз әйдүр: «Сәңа сордығум хәбәр,
Бүгүндер кем, әйләгел бәндән хәзәр!

Һәм сән дәхи күрдекүң бу дөнйани,
Бүгүндер кем, улисәр башуң қани?!

Белмәз исәң, башыңы кәсәрәм,
Ошбу қәлгә бөрҗенә хуш асарам».

Ул йегет әйдер кем: «Тәңрем ике көн
Йариымы қылды бән зәғифә, әй, хатун!

---

[27] Кулъязмада «йегетә» сүзенең ахырындагы «ә» хәрефе язылмаган.
[28] Кулъязмада «сабаха» сүзенең ахырындагы «а» хәрефе язылмаган.

*әндишә* – борчылу; *уйқу кәлмәз* – йокы килмәс; *сабах диген* – иртәнгә хәтле; *хуш нәһад* – яхшы холыклы; *чөн* – кайчан; *кәлде* – килде; *ичрә* – эчкә; *шадиман* – шатланып; *сордығум* – сораганым; *бәндән* – миннән; *әйләгел хәзәр* – саклан; *күрдекүң* – күргән; *улисәр башуң қани* – булыр башың кайда; *кәсәрәм* – кисәрмен; *қәлгә бөрҗенә* – кирмән манарасына; *асарам* – асармын; *йари* – ярдәм; *бән зәғифә* – мин зәгыйфькә.

Бу көн дәхи [ул] лөтфындән бәңа,
Йари қыла – хуш җаваб әйдәм сәңа».

Ул қыз әйдүр: «Нә қәвемдүр, вир хәбәр,
Бонларың йөзләре мәнсух улдылар:

Адәм икән, хәйван улдылар болар,
Шөйлә хур этде болары Пәрвәрдигяр?»

Йегет әйдер: «Әйайын аны сәнгә,
Әгәр Чәләб йари қыйлурса бәнгә.

Мәнсух уланнуң береседүр – дуңуз[29],
Бере – мәймүн, бере – дәхи айу, хуш.

Бере – сыртлан, бере – Сөһәйл йаман,
Бересе – Зөһрәдүр күкдә ғайан.

Берсе – таушқан, бере – қызыл ару,
Берсе дәхи бөдүр, әй, маһе ру!

Берсе – чәкүрәкдүр, бере[30] – ғәқрәб,
Берсе – йәшел кәлтәдүр, бере – ғораб.

Бере – байғуш, бере – сәрчәдүр, йақин,
Бере – шаһин, берсе – Малик-хәзин.

---

[29] Кулъязмада бу сүз урынына «байғуш» дип ялгыш язылган. Чөнки 190 нчы бәйттә дә «байғуш» бар. Ә мәнсух булганнар исемлегендә «дуңуз» язылмаса да, мәнсухлык сәбәпләре саналган урында (193 бәйттә) «дуңуз» язылган.

[30] Кулъязмада «бере» сүзенең ахырындагы «е» хәрефе язылмаган.

*лөтфындән* – мәрхәмәтеннән*; мәнсух улды* – юкка чыгарылды; *шөйлә* – шулай; *Пәрвәрдигяр* – Аллаһ; *әйайын* – әйтим; *уланнуң* – булганның; *дуңуз* – дуңгыз; *мәймүн* – маймыл; *сыртлан* – ерткыч хайван; *Сөһәйл* – йолдыз исеме; *таушқан* – куян; *қызыл ару* – шөпшә; *бөдүр* – бытбылдык; *маһе ру* – ай йөзле, матур; *чәкүрәк* – чикерткә, саранча; *ғәқрәб* – чаян; *ғораб* – козгын; *сәрчә* – карчыганың бер төре; *йақин* – ышан, бел; *шаһин* – лачын, шоңкар; *Малик-хәзин – җәһәннәм фәрештәсенең исеме.*

Бере – қарталдыр[31], берсе дәхи фил.
Мәнсух уланлар болардур, шөйлә бел!»

Дүнде қыз, әйтүр: «Хәбәр вир, әй, йегет!
Нә сәбәбдән мәнсух улдылар? Әйт!»

Йегет әйдер: «Мәймүн илә ул дуңуз,
Йиде йөз кеше иде ул. Дыңлаңуз!

Өммәтейде Ғәйсаның җөмлә болар,
Чөн Ғәйсадан маидә деләделәр.

*54б кәгазь* Чөн Ғәйса Хақдан деләде маидә[32],
Хақ виреде шул уқ дәм, әй, дәдә.

Қамусы Ғәйсайа кәтерде иман,
Йиде йөз кеше иде ул, бигөман.

Йөз чәверүб Ғәйсадан, улды ғәду,
Әйтделәр: Зәһи! Йаланчы! Җаду!

Әмма сыртлан мур бер ғәүрәт иде,
Хақсыз йирдә халық инҗедер иде.

Чөнкем ул инҗедмәге қыйлды исә,
Сурәтен дүндүрде ул Қадыйр са.

Айу хаҗилар малын алур иде,
Анлары мәймүн зәлил қыйлур иде.

---

[31] Кулъязмада: قورتلدر (қорталдыр).
[32] Кулъязмада «маһидә» рәвешендә, хаталы язылган.

*қартал* – тилгән; *дәхи* – тагын; *дыңлаңуз* – тыңлагыз; *чөн* – кайчан; *маидә* – ризык; *деләде* – теләде; *дәм* – вакыт; *бигөман* – шиксез; *чәверүб* – чөереп; *ғәду* – дошман; *зәһи* – мактанчык, тәкәббер; *йаланчы* – ялганчы; *җаду* – сихерче, күрәзәче; *мур* – азгын; *ғәүрәт* – хатын; *инҗедер* – газаплар, мыскыллар; *чөнкем* – кайчан; *Қадыйр са* – кодрәт иясе, ягъни Алла; *зәлил қыйлур* – мыскыллар, түбәнсетер.

Аны дәхи мәймүн әйләде Чәләб,
Сурәтен дүндерде ул Җәббари Рабб.

Йул кәсүче иде Сөһәйл йаман,
Хәрамлық қылур иде ул заман.

Зөһрә[33] дәхи бер ғәүрәтдүр, әй, хатун!
Һәм қаблугә қызы иде ул фөтүн.

Һарут-Марут аздурды ғайан,
Аллаһ аны йолдуз әйләде бәйан.

205 Үрмәкче бер ғәүрәт иде хәляленә[34],
Һәрқачан кем әре кәлсә қатына,

Дүшәгендин қачар иде ул бәлид,
Сурәтен дәгишүрде ки, ишет!

Таушқан дәхи бер ғәүрәтде, әй, хатун,
Арусыз йөрүр иде ул төн-көн.

Қызыл ары халық илә төн-көн,
Хақсыз йирә чағырышур улды төн-көн.

Сычқан[35] дәхи бер ғәүрәтде сағучы,
Әрейлә сүгешүрде әче-әче.

---

[33] Кульъязмада «Зөһрә» сүзенең ахырындагы «ә» хәрефе язылмаган.
[34] Кульъязмада: халенә.
[35] Бу сүз кульъязмада سجن قان рәвешендә, хаталы язылган.

*Җәббари Рабб* – Үз хөкемен барча галәмнәрдә ирештерүче көчле Боеручы (Аллаһның күркәм исемнәре); *қаблугә* – бу сүз кульъязмада хаталы язылган булса кирәк, мәгънәсен ачыклап булмады; *фөтүн* – аздыручы; *бәйан* – һичшиксез; *үрмәкче* – үрмәкүч; *хәляленә* – иренә; *әре* – ире; *кәлсә* – килсә; *дүшәгендин* – түшәгеннән; *бәлид* – ахмак, юләр; *дәгишүрде* – үзгәртте; *ғәүрәтде* – хатын иде; *қызыл ары* – шөпшә; *хақсыз йирә* – хаксызга; *чағырышур* – кычкырышыр; *улды* – булды; *сычқан* – тычкан; *сағучы* – мәет озатканда түләү бәрабәренә ялланып елаучы хатын-кыз, мәрсияче; *әрейлә* – ире белән; *сүгешүрде* – сүгешер иде,

Эт – кәфен суйучы иде әшикяр,
Тәүбә қыйлмады – эт улды, әй, нигяр!

Ул йәшел кәлтә дә дәхи ғәүрәтдүр.
(Ошбу сүз – ғәүрәтләрә ғибрәтдүр!)

Тунлар кийеб бэзәрде кәндүзени,
Йад кешейә күстәрәйде йөзени.

*55а кәгазь* Бөдүр дәхи[36] йаланны кәндүзенә,
Сәнғәт идеб сөйләмеш иде үзенә.

Һәм чәкүргә зольм идәрде ул заман,
Уғрылық әйләр иде қалтабан.

Байғуш бер мәлик эрде рәғийәтенә,
Җәвер эдәрде әренә-ғәүрәтенә.

Қозғун дәхи бер мәхәл кеше иде,
Халық қыйнамақ аның эше иде.

Сәрчә ришвәт алучы иде ғайан,
Батыйлә хақ дийүб, сөйләде йалан.

Шаһин дәхи тахелен күзләр иде,
Эчендә җәфасын гизләр иде.

---

[36] Кулъязмада хаталы итеп بورخى (бөрхи) рәвешендә, ике сүзнең тиешле хәрефләре төшеп калган. Ягъни, بودوردخى (бөдүр дәхи) дип язылырга тиеш булган.

*суйучы* – кисүче; *әшикяр* – ачык; *бэзәрде* – бизәр иде; *кәндүзени* – үзен; *йад кешейә* – ят кешегә; *күстәрәйде* – күрсәтә иде; *йаланны* – ялганны; *сәнғәт* – шөгыль; *чәкүргә* – чикерткә, саранча; *уғрылық* – караклык; *қалтабан* – әшәке кеше; *мәлик* – патша, солтан, хан; *эрде* – иде; *рәғийәтенә* – халкына; *җәвер эдәрде* – җәберләр иде; *әренә-ғәүрәтенә* – иренә-хатынына; *мәхәл* – дәрәҗәле урын биләүче; *сәрчә* – карчыганың бер төре; *батыйлә* – ялганны; *йалан* – ялган, һәрвакыт; *шаһин* – лачын, шоңкар; *тахел* – бозыклык; *гизләр* – яшерер.

Үчлү кеше ошбу сүздән асылында,
Фил дәхи инсан – итәрде хәйвана».

Бу җанварлар, дәхи ишедүң қаму,
Адәм иде һәрбересе, әй, ғаму!

Тәңре бойруғын сыйыб, мәнсух улдылар,
Һәрбересе шөйлә харис улдылар.

Һәркем боларның эшендин бер эше
Эшләсә, даим йыйа тәшвише.

Ул сурәтле қүписәр йәрен ғайан,
Сақласун сези-бези бу эшдән!

Ул йегет әйдер қызи: «Ий, җарийә!
Өч көн улды, сүз дөште арайә.

Йиңсәйдүң һәм кэсәр идең башыми.
Хақға чуқ шөкер! Үгәрде эшеми.

Бүгүн өч көндүр, сән мәсьәлә сордың бәңа,
Нә сордың ирсә, җавабын вирдем сәңа.

Бән дәхи бер мәсьәлә сорам сәнгә
Ки, җаваб әйдүр улурсаң сән бәнгә,

Шөйлә улсун шартымыз – башың кәсәм,
Илтүб ошбу қәлғә бөрҗенә асам!»

---

*үчлү* – үчле; *қаму* – бөтен; *ғаму* – кардәш, туган; *сыйыб* – тотмыйча; *харис* – комсыз, ачкүзле; *улды* – булды; *даим* – даими; *йыйа* – җыя; *тәшвиш* – бозыклык; *қуписәр* – кубар; *йарен* – киләчәктә; *ғайан* – ап-ачык, тәгаен; *сези-бези* – сезне-безне; *җарийә* – ирексез кыз; *дөште* – төште; *арайә* – арага; *йиңсәйдүң* – җиңсә идең, әгәр җиңсәң; *чуқ* – күп; *үгәрде* – уң итте, мәрхәмәт кылды; *сорам* – сорыйм; *әйдүр улурсаң* – әйтер булсаң; *қәлғә бөрҗенә* – кирмән манарасына.

Ул қыз әйдүр: «Разыйым бу қәүлейә бән,
Йахуд бән өстүн улам, йахуд сән».

*55б кәгазь* Йегет әйдүр: «Кемдүр ул, әй, хуш сурәт,
Анасын тун әйләде, атасын – ат?

Сәйр эдәр көн йитде ардындан үлем,
Чөнки китерде аны ул ғөлям.

Тәңре қортарды үлемдән аны?
Мәсьәләм будыр сәндән, тэз эмди бел буны!»

Чуқ заман фикер әйләде қыз – белмәди,
Мәсьәлә җавабын хәлл қылмади.

Дүнде қыз, әйдүр: «Шаһа! Әй, фөтүн!
Сәнең кеби[37] йуқ иде ғалим бүгүн.

Чуқ йегетләр, чуқ ғалимләр килделәр,
Бәнем илә шөйлә сөаль қыйлдылар.

Сәндән артық кемсә йиңмәде бәни,
Һәр заман асылмыш йегетләр солтаный!

Кәрәмүңдән бәңа миһлят вир[38] бу көн,
Мәсьәләңе фикер идәйен ошбу дөн.

---

[37] Кулъязмада: бәки.
[38] Кулъязмада бу сүз урынына «дер» дип ялгыш язылган.

*разыйым* – ризамын; *қәүлейә* – сүзеңә; *йахуд* – яки; *сәйр эдәр көн* – юл гизгән чагында; *чөнки* – кайчан; *ғөлям – егет; тэз* – тиз; *эмди* – инде; *буный* – моны; *хәлл қылмади* – чишә алмады; *шаһа* – шаһым; *фөтүн* – сөекле, соклангыч; *шөйлә* – шулай; *асылмыш* – асылган; *кәрәмүң* – юмартлыгың, киң күңеллегең; *миһлят* – вакыт, мөмкинлек; *идәйен* – итим; *дөн* – төн.

Гәр белүрсәм, эртәсе әйдәм сәңа,
Белмәз исәм, мотыйғ улам әмреңә».

Йегет әйдүр: «Мәслихәтдүр». Торар.
Ул қарыйчуқ эвенә кәлде. Керәр.

Қыз қалды анда қаты әндишдә,
Мәсьәлә фикер эдүбән әйтә,

Әййүр иде: «Әй, ғәҗәб, бән нидәйен?
Торайын, йегет қатына кидәйен.

Хәйлә илә сорайын әхвалени,
Кемнең уғлыдур – беләйен халени.

Әгәр мәликзадә исә, қылам қабул,
Җан-дил илә бәңа хәлял ула ул.

Әгәр гидай уғылы улдисә, ишкял,
Ул нә ляиқдыр бәңа ула хәлял.

Хәйлә илә мәсьәләсен сорайын,
Эртә кәленчәк җавабын вирәйен.

Дәхи нә қылур, башыны кисәйен,
Аны дәхи ошбу бөрҗдә асайын».

*56а кәгазь* Тора килде, бизәде кәндүзени.
Ғақлы китәр – һәркем күрсә йөзени!

---

*эртәсе* – иртәсе; *әйдәм* – әйтәм; *мотыйғ улам* – буйсынам; *мәслихәт* – хуп, риза, килештек; *торар* – торыр; *әндишдә* – уйда, хәсрәттә; *эдүбән* – итеп; *әййүр* – әйтер; *нидәйен* – нишлим; *торайын* – торыйм; *кидәйен* – китим; *сорайын* – сорыйм; *беләйен* – белим; *мәликзадә* – патша улы, солтан улы; *делилә* – теле белән; *ула* – була; *гидай* – фәкыйрь; *ишкял* – мөшкел; *нә ляиқдыр* – лаек түгел; *эртә кәленчәк* – иртән килгәч; *вирәйен* – бирим; *асайын* – асыйм; *ғақлы* – акылы.

Чуқ китерде бәлә нәфс илә сөче.
Аллаһ ула ул йегетә йаручы.

Дөн бочуғында кәлде қарый әвенә,
Қайгулу улан күрүрсә, сәвенә.

Қакды қапуы, чықа кәлде қарый,
Дэде кем: «Керсәм[39], дәстүр варму, ичәри?»

Икесе қызның ике йанында дорур,
Керде ичәри. Йегетә, күр, нә қылур!

Бақды, күрде йегет қаршыдан қызы,
Әйтде: «Хуш кәлдең, әй, таң йолдызы!

Хаҗәтең нәдүр, нәйә[40] кәлдең бәңа?
Ул қыз әйдүр: «Ғашиқ улдум бән сәңа.

Бер олу таҗир иде бәнүм атам,
Сәндән отру җанымы өтә атам.

Сән нә йегетсән, нәйә[41] кәлдүң шәһәрә?
Сәне таңлашурлар ошбу халық ара.

Мәсьәлә илә йиңмеш дэдиләр қызи,
Йавыз күздин бикләсен чөн Хақ сези.

---

[39] Кулъязмада: күрсәм.
[40] Кулъязмада: йәнә.
[41] Кулъязмада: йәнә.

*бәлә* – шулай; *нәфс илә* – нәфес белән; *сөче* – гөнаһны; *йаручы* – ярдәмче; *дөн бочуғы* – төн уртасы; *әвенә* – өенә; *қайгулу улан* – кайгылы булган; *күрүрсә* – күрсә; *сәүенә* – сөенә; *қапуы* – ишекне, капканы; *чықа* – чыга; *дэде* – диде; *дәстүр варму* – рөхсәт бармы; *ичәри* – эчкә керергә; *йегетә* – егеткә; *нәдүр* – нидер, нәрсә; *нәйә* – нигә; *олу* – олы; *таҗир* – сәүдәгәр; *сәндән* – синнән; *отру* – отыры; *таңлашур* – гаҗәпләнер; *дэдиләр* – диделәр; *қызи* – кызны; *сези* – сезне.

Анча үгде атам кем, сәне бәңа,
Ғашиқ улуб уш кәлдем сәңа!»

Йегет әйдүр: «Хуш кәлдең, әй, күрклү йөз!
Безе сәвәнне без дәхи сәвәрүз».

Ачды ул қыз қасд илә йөзен-күзен,
Ғәрза қыйлды ул йегетә кәндүзен.

Чөн ки йегет бақды[42] қызың йөзенә –
Кэлмәде чөн бер заман кәндүзенә!

Бер заман йийеб-ичеб, көлүшделәр,
Бере-беренә әрзләрен ачышдылар[43].

Қыз әйдүр йегетә: «Әйт, бил-Лаһ, бәңа,
Нә кем сорды шаһ қызы бу көн сәңа?»

Ул йегет һәп-җөмлә тәкрир әйләди,
Нә кем җаваб вирдисә – сөйләди.

*56б кәгазь* Әйтде: «Бил-Лаһи, сән сордың бу көн,
Шаһ қызы белмәде, қылды зәбүн?»

Йегет әйдүр: «Бәнем [бу]дыр сөаль,
Бәнүм чөн әйләдем би мисаль.

---

[42] Кулъязмада «бақды» сүзенең ахырындагы «ы» хәрефе язылмаган.
[43] Кулъязмада: ачдылар.

*анча* – шулкадәр, кайчан ки; *үгде* – мактады; *улуб* – булып; *уш* – менә, хәзер; *күрклү* – күркәм, матур; *безе* – безне; *сәвәнне* – сөйгәнне; *сәвәрүз* – сөярбез; *қасд илә* – яшерен ният белән; *ғәрза қыйлды* – күрсәтте; *чөн ки* – кайчан; *кэлмәде чөн бер заман кәндүзенә* – күпмедер вакыт аңына килә алмыйча торды; *йийеб-ичеб* – ашап-эчеп; *әрз* – хөрмәт, ихтирам; *бил-Лаһ* – билләһи; *һәп-җөмлә* – барча, бөтен; *тәкрир әйләди* – аңлатты, сөйләде; *нә* – ни; *вирдисә* – биргән булса; *қылды зәбүн* – җиңелде; *бәнүм* – мин; *чөн* – кайчан; *би мисаль* – чагыштыргысыз.

Атам[ы]-анам[ы бән] сатдым эди,
Мөфлислекдән анлары тун этдем эди.

Атам бәһасенә вирделәр бер ат,
Анам бәһасенә – тун, әй, хуш нәһад».

Ул атлу кәндүйә йулда йитдекен,
Сөйләде кәндүйә бөти вирдекен.

«Сордығым мәсьәлә будыр аңа,
Ғаҗиз улды, вирмәде җаваб бәңа».

Хәйлә илә ул қыз аңлады аны,
Дүнде қыз. Әйде: «Ай, җаным җаны!

Кэчдән бәрү һич эчмәдүк шәраб,
Шимди[44] кәрү қылалым ғайш-тараб».

Йегет әйдүр: «Мәслихәтдүр, сақи[45] ул,
Бәнем чөн, йа, нигярин, бақи ул!

Шул сағәт қәдәхе алды әленә,
Тулдурубән сонды йегет алына.

Чөн қәдәхе шул дәм нуш әйләди,
Тари һуш-у-райи, сәрхуш әйләди.

---

[44] Кулъязмада бу сүз хаталы язылган.
[45] Кулъязмада «сақи» сүзенең ахырындагы «и» хәрефе язылмаган.

*эди* – иде; *мөфлислекдән* – мохтаҗлыктан; *анлары* – аларны; *этдем* – иттем; *хуш нәһад* – гүзәл табигатьле; *кәндүйә* – үзенә; *йитдекен* – җиткәнен; *бөти вирдекен* – хат биргәнен; *дүнде* – борылды; *кэчдән бәрү* – кичтән бирле; *шимди кәрү* – хәзер; *қылалым* – кылыйк; *ғайш-тараб* – күңел ачу, рәхәт чигү, ләззәтләнү; *сақи* – эчемлек салучы; *бәнем чөн* – минем өчен; *нигярин* – гүзәлем, сөеклем; *бақи* – мәңгелек; *қәдәхе* – касә; *әленә* – кулына; *тулдурубән* – тутырып; *сонды* – сузды; *алына* – каршына, алдына; *чөн* – кайчан; *дәм* – вакыт; *нуш әйләди* – бушатты, эчте; *тари һуш-у-райи* – һушсыз-аңсыз һәм сүзсез калу.

Ул қызың мәсьәлә иде мақсуды,
Торды, китде. Йегете анда қуйды.

Дөн бочуғында кәлде йәнә сарайына,
Нә кем күрмәде нә худ эрәйенә.

Эртә улды, йегетүң ғақлы кәлүр[46],
Шаһ қызыймеш киләнне аңлар-белүр.

Әйтде: «Ай-вай, аңламадум эшем,
Кәсерсә золым илә ул қыз башым...»

Бақды – күрде түшәгедә бер йөзүк,
Әйтде: «Бонуңлә ула сүзүм төзүк!»

Қашы йағқут ул йөзүк алтун иде,
Қашында ул қызың ады йазулу иде.

*57а кәгазь* Алды йегет йөзеге. Торды үрә.
Килде қыз сарайына, керде ичрә.

Хуш әда белә қызға вирде сәлям,
Әйтде: «Һәргиз кэлмәсүн сәңа алям!»

Қыз: «Ғәләйкә» – алды, әйтде: «Әй, йегет!
Мәсьәләңне белдүм уш, бәллү сабит.

---

[46] Кулъязмада: кәлде.

*бочуғы* – уртасы; *нә худ* – ничек; *эрәйенә* – юкка чыгып торуын; *кәлүр* – килер; *кызыймеш* – кызы имеш; *киләнне* – килгәнне; *кәсерсә* – киссә; *бонуңлә* – моның белән; *ула* – була; *йағқут* – йакут; *қызың ады* – кызның исеме; *йазулу* – язулы; *хуш әда* – ягымлы тавыш; *һәргиз* – һичкайчан; *кэлмәсүн* – килмәсен; *алям* – кайгы-хәсрәтләр; *ғәләйкә* – сәламгә каршы җавап сүзе; *бәллү* – чынлап, шиксез; *сабит* – ачык, дөрес.

Атаңны сатмышсән – әйләмешсән ат,
Анаңны тун әйләдүң, әй, хуш нәһад!

Атаң бәһасенә[47] алдың – бер ат,
Мәсьәләңдер – бу сордыгуң хикәйәт.

Кидәр икән, йулда бер атлу сәнгә
Ирде, ғәзмеңез қанқый йәйгә.

Әйтде: “Фәлян қалағадыр йүнүм,
Бән бөти элтүрәм аңа, җанум”.

Сән әйтдүң: “Бөти вир бәңа, дүн сән кәрү,
Бән бу бөти элтәйүн қалаға, әй, маһе ру!”

Вирде бөти[йе], доға қыйлды сәнгә,
Дүнде кәрү кәндү кәлдеге йәйгә.

Сән әйтдең: “Бөтине [бән] арайын,
Нә йазылмыш эчендә – бер күрәйен”.

Ачдың, уқудың бөти[йе], әй, дәдә.
Йазмышлар “Һәр кем бөти қалаға илтә,

Варачақ қалаға – кәсүң башыни,
Фәсыйль эдүң дөнйадан аның эшени”.

---

[47] Кулъязмада «бәһасенә» сүзенең ахырындагы «ә» хәрефе язылмаган.
[48] Кулъязмада «үлүмдән» сүзенең ахырындагы «н» хәрефе язылмаган.

*сатмышсән* – саткансың; *әйләмешсән* – иткәнсең; *кидәр икән* – барышлый; *ireде* – иреште, очрады; *ғәземеңез* – юнәлешегез; *қанқый* – кайсы; *йәйгә* – якка, тарафка; *йүнүм* – тоткан юлым; *бөти* – хат; *элтүрәм* – илтәм; *дүн* – кит, кайт; *кәрү* – кире; *элтәйүн* – илтим; *маһе ру* – ай кебек йөзле, матур кеше; *вирде* – бирде; *бөтийе* – хатны; *кәлдеге* – килгән; *арайын* – карыйм, тикшерим; *күрәйен* – күрим; *дәдә* – дәрвиш; *варачақ* – баргач; *кәсүң* – кис; *фәсыйль эдүң* – бетер.

Чөн белдең – тэзчәк йыртдың аный,
Тәңре қортарды үлүмдән[48], бел, сәни!

Мәсьәләң бу иде – белдем, әй, йегет,
Кәстерәрәм башыңы, бел ки, эшет!»

Ул сағәт чөн укуды қәүлләрени,
Әйтүбән: «Тэзчәк асуң, қоллар[49], буни!»

Ул йегете солтана илтделәр,
«Қыз йәнә чөн буны йиңде», – дэделәр.

Йегет әйтүр: «Бер сүзем вар, шаһ, сәнгә,
Кем шаһид ул сүздә[50] – әман ула бәнгә».

*57б кәгазь* Солтан әйдер: «Сөйләгел! Вирдүм аман».
Йегет әйдер аңа: «Әй, шаһе җәһан!

Бер күгүрчен қыз сарайындан очар,
Қанчару варурса, ғәнбәр сачар.

Кәлде қунды безем эүнүң эченә,
Сөчлекдә бән ғәрибүң сөченә.

Тору кәлдем шул сағәт, тотдым аный,
Бәрк бағладым ул қошнуң айағыный.

---

[49] Кулъязмада «қоллар» сүзеннән соң «сез» сүзе язылган. Ләкин ул шигъри үлчәмгә сыешмый.
[50] Кулъязмада «сүздә» сүзенең ахырындагы «ә» хәрефе язылмаган.

*чөн* – кайчан; *тэзчәк* – тизрәк; *аный* – аны; *қортарды* – коткарды; *кәстерәрәм* – кистерермен; *қәүлләрени* – сүзләрен; *әйтүбән* – әйтеп; *асуң* – ас; *чөн* – чөнки; *буни* – моны; *дэделәр* – диделәр; *әман ула бәнгә* – мине коткара; *вирдүм аман* – рөхсәт бирдем; *шаһе җәһан* – дөнья патшасы; *күгүрчен* – күгәрчен; *қанчару* – кая; *варурса* – барса; *ғәнбәр* – хушбуй, хуш ис; *сачар* – чәчәр; *эүнүң* – өйнең; *сөчлек* – гөнаһлылык; *ғәрибең* – фәкыйрьнең; *сөч* – гөнаһ; *бәрк* – нык.

Деләрдем – ма шаһ ула идем,
Бер заманануң илә ула идем.

Ғафил улдым, әлемдән очды йәнә,
Варды қунды ул қызуң күшәгенә.

Чуқ шөкер, андан ки қалды бу йөге,
Будыр бәнүм сүзүм, әй, шәһәрнең бәге!»

305 Аңлады солтан аны бәркчә.
(Қонуқ улмыш йегетә ул шаһ нәчә!)

Солтан әйдер: «Қани нәйтдең ул йөги?»
Йегет дәхи сона вирде йөзеги.

Йөзек күричәк шаһ қақыды,
Хишем идүбән қызы атын[51] уқыды.

Әйтде[52] бәр гиз: «Һәй-әй, буйнун өзүң!
Бу йегет қатында нәйләр йөзүгүң?

Қыз әйдер: «Бу йөзүк бәнүм дәгүл.
Айрығу[53] күр – бәңа бөһтан әйләр ул!»

---

[51] Кулъязмада бу сүз «ата» дип ялгыш язылган.
[52] Кулъязмада «әйтде» сүзенең ахырындагы «е» хәрефе язылмаган.
[53] Бу сүз кулъязмада ايرىغو рәвешендә, хаталы итеп язылган.

*деләрдем* – теләр идем, теләсәм; *ма* – хәтта; *ула* – була; *ғафил улдым* – сизми калдым; *әлемдән* – кулымнан; *күшәгенә* – сараена; *йөге* – каурые; *бәркчә* – ныклап, яхшы; *қонуқ улмыш* – кунган; *йегетә* – егеткә; *нәчә* – нишләтә; *қани* – кая; *нәйтдең* – әйткән; *сона вирде* – кулын сузып бирде; *йөзеги* – йөзекне; *күричәк* – күргәч; *қақыды* – ярсыды; *хишем идүбән* – ачуланып; *атын* – исемен; *бәр гиз* – шунда ук; *буйнун өзүң* – муенын өз; *нәйләр* – нишли; *бәнүм дәгүл* – минеке түгел; *айрығу* – чит кешене; *бөһтан әйләр* – ялган сөйләр.

Солтан әйтде: «Йөзегүң кәтүр, күрәйен!
Бу йегетә бән җәзасын вирәйен[54].

Қурқусындан шаһ қызы дүнде кәрү,
Варды сарайына, керде ичәрү.

Бойырды – бер қуйумчы кәтүрделәр.
Хадимә[55] әйдер шаһ қызы (күр, нәләр деләр):

«Ошбу сағәт йөзүк дөзүң бәңа!
Нә деләрсәң, вирәйен бу көн сәңа.

Йөзүк – алтун, йақутдан улсун қаши,
Шөйлә улсун – икесе бердәй иши!»

*58а кәгазь* Бер сағәт[дә] дөзде остад аный,
Қашы үзрә йазды ул қыз адыный.

Иллә бәңзәтде аны ул йөзүккә,
Қыз вәлә кем анда туғры күзүккә.

Ул остада вирделәр бең алтунни,
Әйдер остад: «Ғәйебләмәңез бәни?!»

Алды ул қыз йөзүге, кәлде кәрү,
Ата сарайына керде ичәрү.

---

[54] Кулъязмада: вирәм.
[55] Кулъязмада «хадимә» сүзенең ахырындагы «ә» хәрефе язылмаган.

*кәтүр* – китер; *күрәйен* – күрим; *вирәйен* – бирим; *кәрү* – кире; *қуйумчы* – алтын-көмеш эшләре остасы, ювелир; *хадимә* – хезмәтчегә; *нәләр* – ниләр; *деләр* – теләр; *дөзүң* – яса; *бәңа* – миңа; *улсун* – булсын; *қаши* – кашы; *шөйлә* – шундый; *иши* – ише; *остад* – оста; *аный* – аны; *қашы үзрә* – қашына; *адыный* – исемен; *иллә* – бигрәк, бик тә; *бәңзәтде* – охшатты; *вәлә* – таң калды; *күзүк* – охшашлык.

Сону вирде йөзеге атасына.
Әйтде: «Нәчөн керден қызуң сарайына?

Ушда бәнүм йөзүгем будыр ғайан.
Кемдер ул йөзүге бәнүм дийән?»

Солтанның йанындағы вәзирләр:
«Нәтдүң ул йөзеге? Бонда күстәр[56]!»

Кәтүрделәр ул йөзекне арайә,
Элтүбән күстәрә һәм бәкләрә.

Бәкләр икесене бәлә күрделәр –
Бер нәқешдә икесене белделәр.

Бәкләр әйдүр: «Иске йөзүкдүр бу йөзүк,
Йаңы йөзүкдүр бу соңрағы йөзүк.

Рәнге – бер, қалыбы – бер һәм қашы – бер,
Бу аның дәгелдүр! – дэделәр, – Йа, әмир!»

Қол-қаравыш, хадим-бәкләр қаму,
Танық вирделәр солтана, ғаму.

Солтан әйдүр: «Сәне вирдем йегетә.
Бунуң кеби ғалим улмаз дөнйада!»

---

[56] Кулъязмада: күстәр бунда. Ләкин рифма таләбенчә «бунда күстәр» дип язылуы дөрес.

*сону вирде* – кулын сузып бирде; *нәчөн* – ни өчен; *қызуң* – кызның; *ушда* – менә; *ғайан* – билгеле, тәгаен; *бәнүм* – минеке; *дийән* – дигән; *нәтдүң* – нишләттең; *күстәрә* – күрсәтә; *арайә* – шунда; *элтүбән* – илтеп; *бәлә* – шунда, шулай, чынлап та; *рәнге* – төсе; *дәгелдүр* – түгел; *қаму* – һәммәсе; *солтана* – солтанга; *ғаму* – кардәш, туган; *әйдүр* – әйтер; *улмаз* – булмас.

Уқудылар, қазый кәтүрделәр,
Солтан қызын ул йегетә вирделәр.

Никях идделәр қызы ул йегетә,
Мақсуда эрде ул йегет, әй, дәдә.

Йиде көн-төн көн улды дәкүн,
Чалынур җәшдә дағи төн-көн.

Бизәделәр, гирдәккә керде йегет,
Қыз илә икесене береге эшет!

*58б кәгазь* Бизәделәр шәһәре. Йиде көн тәмам
Чалынур, зөрнә өрелде башдан.

Ул кэчә керде чөн йегет гирдәккә,
Сынасән шаһин салдуң үрдәккә.

Бер заман йийеб-эчеб, көлүшделәр,
Бер-беренә әрзләрен ачышдылар.

Чуқ заман бер-беренә қыйлды ғитаб,
Бер-беренә қылды сөаль-у-җаваб.

Мөрәүвәтә эрде икесе ул кэчә,
Бу хикайәт ахыр улды, әй, хуҗа.

---

*мақсуда эрде* – максатына иреште; *дәкүн* – тоташ; *чалынур* – уйнар; *җәшдә* – чәштә, ягъни кыллы уен коралы; *дағи* – кызып; *гирдәк* – никахлашу, зөфаф кичәсе; *береге* – кавышуын; *эшет* – ишет; *чалынур* – кыллы уен коралында уйнау күздә тотыла; *зөрнә* – сорнай; *чөн* – кайчан; *сынасән* – гүяки; *шаһин* – лачын; *әрз* – хөрмәт, ихтирам; *чуқ* – күп; *ғитаб* – шелтә; *сөаль-у-җаваб* – сорау һәм җавап; *мөрәүвәтә* – риясызлыкка, затлылыкка; *эрде* – ирешге; *кэчә* – төн.

Ғақибәт, солтан үлде. Қалды ул,
Солтан әйләмешде аны уғул.

Ул бәкләр разый улды хөкеменә,
Солтанлығ вирделәр ул уғылына.

Чықды тәхтә, хөкем эрде элләрә,
Ғадил ирде ул қаму йуқсуллара.

Атасына-анасына хальне ул,
Йаздырыб белдүрде әхвальне ул.

Ата-ана чөн эшетделәр аный,
Шөкер эдеб, тупраға орды йөзләрени.

Тэз хәбәр этде ул мәликкә атасы.
Торды, баласына вирде атасы.

Әйтделәр: «Әй, шаһ! Безе сатды сезә,
Ул уғланнуң хәбәре[57] кәлде безә.

Шаһ, әгәр дәстүр вирсәң чөн безә,
Анда доғачы улавыз без сезә».

Солтан әйдүр: «Бән сезе бағышладым,
Бән бу эшне Хақ йулына эшләдем».

---

[57] Кулъязмада «хәбәре» сүзенең ахырындагы «е» хәрефе язылмаган.

*ғақибәт* – соң, ахыр; *тәхтә* – тәхеткә; *эрде* – иреште; *элләрә* – илләргә; *ғадил ирде* – гадел иде; *йуқсуллара* – фәкыйрьләргә; *чөн* – кайчан; *эдеб* – итеп; *тупраға* – туфракка; *тэз* – тиз; *этде* – итте; *мәлик* – патша, солтан, хан; *безе* – безне; *сезә* – сезгә; *дәстүр вирсәң* – рөхсәт бирсәң; *улавыз* – булабыз; *бағышладым* – азат иттем.

Чөн ки күрделәр йул улдуғын,
Вардылар чу үбделәр шаһың әлен.

Ата-ана сәвенүшүбән кәлделәр,
Бақый ғөмер анда билә улдылар.

Сабыр илә ирде йегет солтанлығға,
Қаму ғалим торды анда аңа қолға.

---

*чөн* – кайчан; *йул улдыгын* – азат булуны; *чөн* – кайчан; *йул улдыгын* – азат булуны; *вардылар чу* – баргач; *үбделәр* – үптеләр; *әлен* – кулын; *сәвенүшүбән* – сөенешеп; *кәлделәр* – килделәр; *бақый* – мәңгелек; *билә* – бергә; *ирде* – иреште; *солтанлыгга* – солтанлыкка.

# «КЫЗ ХИКӘЯТЕ» КУЛЪЯЗМАСЫНЫҢ ФАКСИМИЛЕСЕ



*«1764 т» шифрлы кулъязма (Татарстан Милли китапханәсе). 49а кәгазь.*



*49б кәгазь.*



*50а кәгазь.*


اشگر الاین کوردی یول اچره
بر معظم شهر یتشدی یولق ادلو
درت یانی اسلان اقوخوش عجد
کوردی بو چیره اصلان ادام باشنی
کم بو باشنی نیه کسمشلار اوله
علار تخنوق یرنی کورا یین
کلدی یکت بر قرچیق او یینه
اول قرچیقنونک بر اوغلی اولمشلار
کورکلی اول یکدی قیندار قنه
کچدی یکت انلا اقرار ایلدی
ایتدی کم بو رجد الکلاشلاو ادام باشنی
قرچیق ایدور بو شهرونک ملکنک
کوبک علاملداری کمسه الی یکسن
کوکس النده اول قزینک مثل یوق
بچه مالک سلطانلرینک عیالی
زالتی اولماز قز بولارکی ما لنه
یار کم اولسه بنی آلمغه

کیده کیت یول الدی بر شهره
خوش ابادان اچی الام تبلالو
یول یرینه انده یوردلر اقچه لار
عجب لندی تنلادی اول بو اشنی
بو قلعه بورجینه اسمشلار اولا
اندان انلکده بو سوال سولا یین
ایتدلر قنوق الور دوسن ای انا
واقع خاطریده قاشدی
کلبر و باش ادستونا اوغول جانی
قاریه انا دیو سویلدی
ندن اوتورالی اسمشلار ایلبر اشنی
بر قزی وار بیچه کمسه ایو قتوار کی اینگ
مسئلهنونک جوابن بیلچه کم دریمان
عاقل اولدی شهرده انکا جوق
کلتولر لار بری بری یول یوق مالی
قیغوردر بار کون اتاسی الینه
کلسون بلسون مسئله جوابن کورمغه
کم بلسون

*50б кәгазь.*



*51а кәгазь.*



*51б кәгазь.*

52

اول قز ایتور ای یکت بر کیل خبر    وارت نسنه انا اوین توغمادیلار
یکت ایدور بری آدم آتا مین    ایکنچیسی بلو حوا انا مین
اسماعیل قوچقارلار اول اوچونچیسی    اول بری رخ صالح توالسی
اول قز ایتور قز خبر ویر کیل بنکا    اولاندر کیم بهتان اتدیلار انکا
یکت ایدور یوسف نینک قرداشلاری    صالحیق جاهیه یوسف پیغامبری
کلدیلر اتالرینه اولار    بهتان اولوب قورتیدی اولار
جون قز ایتور اول نه قوم ور ییرنی    اونی ایکلادی یکجک انلر شهره
چقیق آکتی یوز پیک اولدیلار    یکت ایتور بو کاکیزدر ای بیلار
یعقوب کلدی اوزی بر اوغلیله مصره    کلدیکم اوغلی یوسف یوزین کورا
صنکره آیتی یوز پیک اولوب جقدیلار    کم مز اوینا اتکدیلار اولار
بجیه لکن یکت ویردی جواب    بلیج یکلمادی قز دردی حساب
قز ایدور مونکه کلینده بو نامدار    یارینه کیم صورادم ارسا دیردی خبر
ای ارغه بو بشنجی ییتما ایدی    بو منم سنم آدم [illegible] ایدی
اول قز ایدی بو کون قورتولدونک حیله    تنکلا قلام بن سنکا ارلو بلا
یکت ایدور اول کریم الله بو کون    یارین قلادی قولونه اجلادی اوکون
یاریلیادی سمرینا قیلغانی یاری    خلق قام بجبلادی اول لبری
اول یکت [illegible] سوینه    کلدی ینه اول قزیجق اوینه
قزی ایدی جوک قورتولدونک جانیم    آتمجانم اردی بو نزه بنم

*52а кәгазь.*



*52б кәгазь.*



53

اول قز ایلدورای قند لب
اول آخر ایلدوکی آدم دکل
یکت ایدور بال ارسلور عمیان
اول قز ایلدور یکدم ای اسل ایل
اول نه قومدر کم یلان سیلد یلر
اول نه قوم دور کم چکل سیلد یلر
کم انلار سیلدیلر یلان
اتالارنه یلان سیلد یلر
صنکره تکری یرلقادی آنلری
انلر کم چکل سیلدی کمرادی اول
بری نصرانی ادور بری یهود
یهود ایلر ایتلر بونلر نک
اول قیز ایلدور یکده اوشبو کوناشول ایکی
یکت ایلدور یدی یوز فرسخ بر یغاچ تمام
اول قز ایلدور یکده ای مجتهدی
یکده ایلدور اول ایلسوکی آرا ک
اول قز ایلدور جزای بشقدم
یکت ایلدور بلکان الکی کشی یشادی

کم دخی ایلدی انلار جلب
نه جنتدور نه اندور نه اولور ادل
کم قرانده اوکلاری ای مستعان
اوشبو ایکی مسئلانی دخی بیل
اوجماغه اسونکرا الرکرد ایلر
تکری امر یله طلاموجها کتوریلر
یوسف تک قرداشلار یدور اول نجات
یوسفنی جون قورت یدی دیدیلر
زیرا اتوبه قیلد یلر یولوق آری
کم دور انی ایلدم ای ادا
کم آنی قرانده اوکلاری اول ودود
دینی نه قلدور ادو نصرانیلار دکل
ناقدر ادور کم ایتکیل اول زودنی
انی اوزون کوناشو کم ای اصمام
تنز خبر ور ایلسوکی ندور الام
حادیث اول نتا کم کوکدا آیه اول
کم بنه یشادی اتامیز آدم
بنا ایدر مسئله بشلدی

*53а кәгазь.*



*53б кәгазь.*



*54а кәгазь.*



چون عیسی حقدان الدی مائده
قمادیلر عیسی یاکردی ایمان
یوز جوروب عیسیدان ادلاری عدو
امالسرتلانی صور برعدد ر تدی
چون کم اول انجدهکی قیلدی سما
ایه ها جاره مالی الوردی
ای اخی میمون ایلدی جلب
یول کمسجدی سیهل یمان
زنهار اخی برعورت دور ای خاتون
نیاددن ساردت ارداوردای عیان
اولمکی برعورت ای حکما لنا
دو یشا کملاین تجار ار اول پلیدی
ای عاشقان اخی بعورتدر ای خاتون
قزیل ار خلقله تون کون
سیجن قان اخی برعورتدای صباغوچی
ایت کفن صو یوجی دای الشلا ره
اول یالشل کالتلدا اخی عورت دور
کونکز نیب بزرار کندن لی

حق دریدی شکر قیلدی ای اداه
یلدی یور کشی ایدی اول بی گمان
ایلدیلار زهی یلانچ جادو ا
حق سزیدی خلق انجدردان
صورتین دوندردی اول قادر سما
انلری میمون لیل قیلدردی
صورتین لاندردی اول جبار رب
حرام لیق قلدردی اول زمان
بدقابلوکا قزی یلدی اول فتون
الیه انی یوللدرز ایلدی بیان
سارجان کم آرتر حلمی قاتنا
صورتین کمشوردی کی اتشیت
اردکس یولادریلدی اول تهاکوه
حق سزیره چفشر اولادی توکوه
اریله سوکمشوردی اجی اجی
توبه قیلمادی ایت اولدی ای نکار
ادشبوسز عورتلره عبرت دور
یاد کتیه کمسه دای یورلی

بولاخ

*54б кәгазь.*

55

بو ارخ یلان نی کندر مینا
بهر جاکسورکا ظلم اردی اول زمان
یا یغوش بر ملک اردی رعیتنا
قورغون دور بر محال کیشی دی
سرجه رشوه الجدی عیان
شاهین ارخ تاخلن کنز ردی
اوحیله کیشی الشیوه زدان الصلاة
بوجان سورلار ارخ ایتندی ک قاجوا
تنکری بوری دنخیان لیب منوچر اولار
بهر بولار تنک التشدین بر اشی
اول صورت لی قنو یسار یارین عیان
اول یکدایدر قدس آکی جار ریه
یکسه دکو بهر کسر اکی بارشمی
بو کون اوچ کند درسن هر اکره کی بلنا
بلا ارخ بر مسئله سورم سنکا
شیله اولسون شرطلری باشنک کسم
اول قز ایلا ورا ختیم بو قولیه بن

لعنت ایلدیب سیاست شوری اورینا
اوغری یالیق ایلدی قلتبان
جار اولردی اریند عور تنا
خلق قینا معنا اینکی امشیدر
بالله حق دیوب سیلادی یلن
اجنده جفاسن کز لاردی
فیل دی الانسان ایتاردی خیوانه
آدم آدی بهر رسمی آکی عمو
بو بیرسه شیله کارس اولدیلر
ایشلمسه لار لایم سیا تشویش
سقلسون لسزی برنی بو کشرن
اوچ کون اولدی سوز دوشتی ارایه
حق عنه چق شکر اوکیردی اشم
تا اسرار اکی ایرسا جواب ورایم سنکا
که جواب ایلادر اوسوز سالس بلکا
ایلتوب اوشه قلعه بر جنا اقسام
یاخدابن اوستون اولام یا خود سن

*55а кәгазь.*



*55б кәгазь.*



*56а кәгазь.*


ایتدی باللّه سن صورلک بوکون
یکد ایدر بنم دارسو [illegible] آل
اتام اتام صاتدیم الرک
اتام بهاسنه ویردیلر آلا
اول آتلو کنلویه یتده یتلکن
[illegible] مسکنه بولدر ا تکا
حیلیله اول قز الدی الہ
یکیدونه بر دایج احماد اوک شراب
یکد ایدور ملیحت اودرساق اول
شول ساعت قدح الدی الینه
جلونه قدح کشولدم نوش ایلدیم
اول قزک [illegible] صقه ولاف
ون بی غنره کلدی ینه سر اینا
[illegible] اولدی یکدوک عقل الدی
ایتدی ای وای کلدم ایشتنم
ایقدی کوردی تولشنکده بر یوزوک
قیشی حقوت اول یوزوک التولدی

شاه قزی باشمدی قلدی زبون
بنوم جون ایلدیم بی مثال
مفسلکدا نه انلری تونه الدیم اولی
انام بهاسنه طلون ای خوش نهاد
سیلدی کندیه بتوی وردکین
عاجز اولدی وردی جواب یکد
دلنک قز ایلدی ای جانم جانی
بشدونه کر قلالم عشق طراب
بنمجونه یانکارین باقی اول
طولادرین صولدی یکد الینه
لادر ساونش [illegible] خوش ایلدی
تواره تکدی یکدانده قویدی
تاکم کوره اولی باخوده ارا [illegible]
شاه قزی میش کلیه الکلاریبلد
کاسه [illegible] اول قز باشم
ایتدی بنوکله اولکوز وم تو روک
قشنده اول قزک آدی یارلو ایدی
الدی یکد

*56б кәгазь.*



*57а кәгазь.*


ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЬЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ

*57б кәгазь.*



*58а кәгазь.*



*58б кәгазь.*

## «КЫЗ ХИКӘЯТЕ» ӘСӘРЕ ТЕРКӘЛГӘН КУЛЪЯЗМА ҖЫЕНТЫК ТАСВИРЛАМАСЫ

Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1764 т» шифры белән саклана торган кулъязма җыентыкка гомуми күзәтү китапның кереш мәкаләсендә язылды. Монда кулъязмага палеографик җәһәттән тулырак тасвир бирәбез.

Җыентыкның башындагы һәм ахыргы битләре төшкән. Гомуми күләме 85 кәгазьдән гыйбарәт. Кәгазе Россиядә эшләнгән, зурлыгы 16х20,5 см. Тышлыгы юк.

Сакланышы уртача. Төбе юан җеп белән тегелгән. Иң ахырдагы кәгазе төбеннән аерылган.

Җыентыктагы әсәр һәм язмалар түбәндәгечә тәртиптә.

1а–18б кәгазьләрдә «Мигъраҗ» исемле шигъри әсәр тексты теркәлгән. Аның тулы исеме, бәлки, «Мигъраҗнамә» булгандыр. Авторы – Хаҗи Мәхмүд. Әсәрнең һәм авторының исемнәре текст ахырында (18б кәгазьдә) күрсәтелгән. Бу поэманың башы юк, ахыры бар. Тексты һәр биттә икешәр баганалы итеп язылган.

«Мигъраҗ» әсәренең барлыгы 459 бәйте (икеюллыгы) сакланган. Башындагы юллары бөтенләй танылмый. Ахыры (18б кәгазьдә):

*Тупрақ әйлә йөзүңе Мостафайа,*
*Арттыруңыз сыйдқуңы ул сафайа.*

«Мигъраҗ» әсәре текстының борынгы чор иҗаты булганлыгын дәлилли торган мисаллар күп. Мәсәлән, кереш мәкаләбездә әйтелгәнчә, «қаму» сүзен قموا, «таму»ны طموا рәвешендә, төрки-татар сүзләренең хәрәкәләр һәм тәнвиннәр белән язылышы бу әсәрнең шактый әүвәлге икәнлегенә ишарә итә. Шулай ук «керисәр», «вирисәрәм» кебек борынгы грамматик формалар, «оҗмах» сүзен اوچمق (очмақ) дип язу да – борынгылык күренеше.

Җыентыкның 18б–20а кәгазьләрендә исемсез, «Һәркем гаурәтенә инана...» дип башланган шигъри әсәр тексты язылган. Аның күләме 40 бәйтне тәшкил итә. Авторы күрсәтелмәгән. Тексты шулай ук һәр биттә икешәр баганада язылган.

Бу әсәрнең башы (18б кәгазьдә):

*Һәр кем [ирсә] гәүрәтенә инана –*
*Вирмеш ула җөмлә эшен зыйана.*

Ахыры (20а кәгазьдә):

*Хале Хақдан хаҗәт деләрәва,*
*Йавыз гәүрәт шәррене Аллаһ сава.*

20а кәгазьдә мондый кыйтга язып куелган: «Биш төрлүк қошны үлтүрмәк олуғ гөнаһ торур. Әүвәл – күк қарға, Адәм ғәләйһиссәлямнең қолавызы ирде. Икенче – қарлуғач. Өчүнче – һөдһөд, Сөләйманның илчесе ирде. Түртүнче – йары қанат*, Сөләйманның хисабчысы ирде. Бишенче – байғуш, Сөләйманның пәнд вә нәсихәт виргүчесе ирде. Валлаһу әғләм...»**

20б–26б кәгазьләрдә «Әбелфәварис хикәяте» теркәлгән. Аның тексты тулы. Хикәятнең башы (20б кәгазьдә): «*Би-исмиһи Сөбханәһә вә биһи нәстәгин. Равийане әхбар, нәқиляне асар, хакийане шәһир хикайәт қылмышлар кем, диңез йақасында...*».

Ахыры (26б кәгазьдә): *«...һәркем йавызлық итсә – йавызлық килүр, йахшылық қылса – йахшылық килүр. Ғақлы вар кеше ошбундан ғибрәт алса кирәк. Рәхмәт бу китаб, буның мөәллифенә, кятибенә, қариэнә, самиғына бөйлә улсын. Амин».*

26б–30а кәгазьләрдә төрки-татар телендәге дини риваятьләр язылган.

Җыентыкның 30б кәгазендә теркәп куелган кечкенә генә риваятьне монда күчерәбез. «Атамыз Адәм ғәләйһиссәлям сабан сөрде. Җәбраил ғәләйһиссәлям оҗмахдан ике үгүз кәлтүрде. Үгүз сабанны тартмады. Шәйтан вәсвәсә бирде – Адәм ғәләйһиссәлям сукды. Үгүз йығылды, күз йәшен түкде – борчақ андан булды тиделәр тәсныйфлар». Шул ук биттә әбҗәд тәртибе язылган.

31б–44б кәгазьләрдә «Шубан кыйссасы» исеме белән билгеле, төрки телдәге шигъри әсәр язылган. Бу кулъязмада аның исеме «Дәр мәдхе Җәлалетдин [Ру]ми» дип күрсәтелгән. Кыйссаның башында әсәр-

---

* Бу язмадан ярканатның башлангыч (элекке) чордагы атамасы «яры канат» рәвешендә булганлыгы аңлашыла.

** Моңа охшаш риваять, Мөхәммәт галәйһиссәлам сүзе буларак, Рабгузи әсәрендә дә язылган (Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1881. – Б. 25). Шулай ук «Мәликә китабы»нда дүрт төрле кошны үтерү гөнаһ булуы һәм аның сәбәпләре турында язылган (Мәликә китабы. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1883. – Б. 7–8).

нең Җәлалетдин Руми (1197–1275) «Мәснәви»сеннән алып, Раушани исемле кеше тәрҗемә иткәнлеге әйтелгән. «Шубан кыйссасы»ның теле борынгы һәм безнең җирлектә иҗат ителгән әсәрләрдән авыррак, шигъри аһәңе-тасвиры урыны-урыны белән бик нәфис һәм бай. Текст кульъязманың һәр битендә икешәр баганада язылган.

«Чубаннамә» дигән икенче төрле исем астында да билгеле булган әлеге кыйссаның XVIII гасыр һәм XIX гасыр башына караган, Идел-Урал буйларындагы татар җирлегендә табылган дистәләп күчермәсе бар. Бу әсәр татар галимнәре игътибарын җәлеп итеп килгән. Мәсәлән, Зәйнәп Максудова (1897–1980) үз тупламасында булган «Шубан» (Чупан) кыйссасы» кульъязмасының читендә искәрмәләр язган бер нөсхә Татарстан Милли музеенда саклана. Аерым алганда, З.Максудова бу кыйссаны Гомәр Раушани исемле автор XV гасырда язган дип билгеләгән. Галимә шулай ук әсәр текстындагы قزان сүзенә мөнәсәбәттә бу әсәрнең авторы Казан белән бәйле булган дип фаразлаган. Әмма кыйсса текстындагы «Казан» дип тә укырга мөмкин булган قزان язылышы бу очракта «қызан» – текстта «дәрд кызан» – ягъни, кайгы кызган дигән мәгънәгә ия. Әдәбият галиме Нил Юзиев (1931–1996) белән археограф Альберт Фәтхи (1937–1992) дә «Кем ул Раушани?.. Аның исеменнән башка мәгълүмат юк. Тик әсәренең теленә карап кына бу шагыйрьнең борынгырак чорда яшәве турында фикер йөртергә мөмкин» дип язганнар иде[*]. Дмитриева каталогында «Шубан кыйссасы»ның авторы Ибраһим ибне Мөхәммәд ибне Ибраһим ибне Шиһабеддин Гөлшани (1426–1533) буларак күрсәтелгән[**]. (Гәрчә әлеге кыйсса текстының бер җирендә дә Гөлшани дигән исемгә ишарә юк). Дмитриевага ияреп, безнең кайбер галимнәр дә «Чубан кыйссасы»ның авторы Ибраһим Гөлшани дип яздылар. Ә борынгы төрек әдәбияты тарихын өйрәнгән төрек галиме М.Мәнги «Чубаннамә» әсәренең Ибраһим Гөлшани тарафыннан түгел, ә аның остазы – мәшһүр суфый Раушани иҗат иткәнлеген ачыклаган[***].

---

[*] Юзиев Н., Фәтхи А. Уралда саклanган әдәби хәзинәләр // Казан утлары. – 1963. – №12. – Б. 118–119; Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Тамга» нәшр., 2007. – Б. 33.

[**] Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской академии наук. – М: Вост. лит., 2002. – С. 298–299.

[***] Мөхәммәтов И. Татар-төрек бәйләнышларында Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәм–мәдия» китабы. – Казан: ТФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих ин.-ты, 2007. – Б. 27–28.

Бу җыентыктагы «Шубан кыйссасы»ның башы (31б кәгазьдә):

*Ул ки дийенелмеш аңа мәхзүбе Хақ*
*Ул, үзе кеби, сүзе, мәхбүбе хақ.*

Ахыры (44б кәгазьдә):

*Раушан ула чәшме дил Раушани,*
*Нура дүнә көлли гөл раушани.*

Бу әсәрнең төп текстына карата битләрнең читендә һәм юл араларында вак хәрефләр белән аерым сүзләргә тәрҗемәләр, аңлатма-шәрехләр язылган.

Кулъязманың 45а–46а кәгазьләрендә төрки-татар, гарәп һәм фарсы телләрендәге шигырьләр (робагый, мисраг һәм мөнәҗәтләр) язылган.

46б–47б кәгазьләрдә төрки-татар телендәге дини риваять, 48а–48б кәгазьләрдә гарәп телендә «Догаи конут» теркәлгән.

Кулъязма җыентыкның 49а–58б кәгазьләрендә «Кыз хикәяте» дип аталган шигъри кыйсса язылган. Әсәрнең исеме башында (49а кәгазьдә) «Қыз хикайәтедүр» дип кызыл кара белән күрсәтелгән. Текстның башы (49а кәгазьдә):

*Бер хикайәт кәлде, әйдәм, дилимә,*
*Ошбу сүздә файда вардур ғалимә.*

Ахыры (58б кәгазьдә):

*Сабыр илә ирде йегет солтанлыға,*
*Қаму ғалим торды анда аңа қолға.*

Поэманың 50а кәгазендәге 42 нче бәйте битнең сул читендә язылган. Ягъни, ул күчерүче тарафыннан текст язылганда төшеп калган булып, шул ук кул белән өстәлгән. Бу икеюллыкның язуы бик начар танылa.

«Кыз хикәяте» кыйссасындагы палеографик үзенчәлекләр турында кереш мәкаләдә язылганнарга тагын кайберләрен өстәп күрсәтәбез. Текстның борынгы чорда иҗат ителгәнлегенә ачык дәлилләргә килсәк, мәсәлән, 326 бәйттә: قموا (қаму), عموا (ғаму), 127 һәм 311 бәйтләрдә: اچروا (эчәрү), 311 бәйттә: كروا (кэрү) кебек сүзләрнең язылу рәвешенең серләре турында алда язып үткән идек. Әсәрнең текстында хаталы язылган һәм хәрәкәләр ялгыш кулланылган сүзләр дә бар. Мәсәлән, سويلكل (сөйләгел), كلدىم (кәлдем), مثلم (мәсьәләм), قامُ (қаму), تامُ (таму). Боларга өстәп кайбер сүзләрнең ахыргы хәрефләре язылмаган булуын да искәртергә кирәк.

Җыентыкның 59а–64а кәгазьләрендә «Мәсаилес-салават» исемендәге, төрки-татар телендәге шигъри әсәр язылган. Исеме башында

(59а кәгазьдә) «Һәза әл-китаб мәсаилес-салават» дип язылган. Тел үзенчәлекләренә караганда, бу әсәр борынгы чорда иҗат ителгән. Аның тексты 18 вак-вак бүлекчәгә бүленгән, бүлекчә исемнәре кызыл төстәге кара белән язылган. Төп текст икешәр баганада язылган.

«Мәсаилес-салават» әсәренең башы (59а кәгазьдә):

*Даим әйтәй Ходайға хәмд-ү-сәна,*
*Биргән Улдур күңелгә нуре сафа.*

Ахыры (64а кәгазьдә):

*Нәзым итте аны, һәркем уқыса,*
*Күңлеңдә салғай нуры Һөда.*

64а–85б кәгазьләрдә «Мәфатихел-колүб» исемле, өлешчә гарәп телендәге, нигездә төрки-татарча дини эчтәлекле чәчмә әсәр (хәдисләр һәм риваятьләр) язылган.

Җыентыкның төп текстлары караңгы көрән, уртача һәм сыек көрән төсләрдәге, 45а–46а кәгазьләрдәге «мисраг» һәм «робагый»лар кара төстәге кара белән язылганнар. Әсәрләр, алардагы бүлекләр һәм мисраг-робагый исемнәре кызыл кара белән язылган.

Кульязманың язу-почеркы – нигездә нәстәгъликка якын.

Кустодлар бөтен текстларда да бар.

Кульязманың 1а кәгазендәге тексты бөтенләй укылмый диярлек. 1б–8б кәгазьләрдәге текстлар да дефектлы, яртылаш кына танылалар. Җыентыкның иң соңгы бите шулай ук начар хәлдә: читләре ертылган, кәгазе тишкәләнгән, язуы өлешчә һәм начар танылa.

Җыентыктагы бөтен текстларда да югарыда күрсәтелгәннәргә охшаш палеографик үзенчәлекләр һәм хаталы язылышлар, *т–д, п–б, җ–ч* хәрефләрен үзара бутап язу, шулай ук س (син) хәрефенең астында һәм و (уау) хәрефенең өстендә өчәр нокта кую, төрки тамырлы сүзләрне хәрәкәләр белән куллану бар.

Кәгазендә аерып танырлык филиграньнәр юк. Җыентыктагы текстларның палеографик үзенчәлекләренә нигезләнеп, аны XVIII гасырның соңгы чирегенә нисбәт итәбез.

Бу җыентыкның төрле битләрендә кеше исемнәре язылган урыннар бар. Мәсәлән, «Ишмәт» (9а кәгазь), 20а кәгазьдә «Биш төрлүк қошны үлтүрмәк...» дигән язманың ахырында «Исмәгыйль мулланың мәктүбдә* йаздым. Ишмәт мулла, җомга көн ирде. Тәмам булды» диелгән. Кульязмада шулай ук «Кәшшафетдин, указный азанчы угылы»

* Бу сүзнең дөресе «мәктүбендән» тиеш булгандыр.

(16а кәгазь), «Гобәйдулла» (30а кәгазь), «Мөхәммәдхәсән» (31а кәгазь) исемнәре дә бар. Кулъязма җыентыктагы текстларның бөтенесе дә диярлек менә бу исемнәр арасыннан берсе – Ишмәт мулла тарафыннан күчерелгәнлеге аңлашыла. Чөнки аның язу рәвеше-почеркы төп текстларныкына тәңгәл килә. Ә җыентыкның төрле битләрендә исемнәре язып куелган бүтән затлар – китапның соңгырак чордагы ияләре һәм аны укыган кешеләр дип уйларга кирәк.

Кулъязма җыентык китапханәгә Казан шәһәрендә 2000 елның 3 октябрендә алынган иде.

# «КЫЗ ХИКӘЯТЕ»НЕҢ СЮЖЕТ ТАМЫРЛАРЫ ҺӘМ ТАРМАКЛАРЫ

«Кыз хикәяте» кыйссасының борынгы Шәрыктән башлангыч алган сюжеты бөтен дөнья әдәбияты һәм мәдәниятендә шактый билгеле. Аны төрле чорларга һәм төрле диннәргә нисбәтле әдипләр үз әсәрләренә нигез итеп алганнар.

Әлеге мавыктыргыч сюжетка нигезләнеп иҗат ителгән һәм XIX гасырда Казанда күп мәртәбәләр нәшер ителгән «Мәликә китабы» уңаеннан әдәбият галимнәре Гали Рәхим белән Газиз Гобәйдуллин язган фикерләргә игътибар итик. Алар болай дигән: «Бу мәүзуг Шәрык дөньясында бик борынгы заманнарда ук ясалган булырга кирәк, чөнки легендаларда Сәба мәликәсе Бәлкыйснең дә Сөләйман патшага шундый читен сөальләр биреп, Сөләйман аларга җавап табып, Бәлкыйстән бик күп мал вә хәзинә алганлыгы сөйләнә (Робгузи. Сөләйман кыйссасы). Югарыда сөйләнгән типтагы хикәяләрдән мәшһүр «Кәлаф белән Турандык» хикәясе дә Шәрыктә бик таралган мәүзуг (Шиллер бу мәүзугны пьеса хәлендә эшләп чыгарган)»[1].

Бу мәкаләдә әлеге борынгы тема-сюжетның тамырларына һәм кайбер тармакларына, бигрәк тә безнең татар җирлегендәге үрнәкләренә күзәтү ясап, кыскача рәвештә эчтәлекләре белән таныштырып үтәбез. (Ибраһим исемле төрки-татар шагыйренең 1382 елда иҗат иткән шигъри әсәре турында кереш мәкаләбездә шактый язылганлыктан, монда аңа кабат тукталмыйбыз).

## Сөләйман пәйгамбәр һәм Бәлкыйс кыйссасы

Гали Рәхим һәм Г.Газиз телгә алган Насыйретдин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» әсәре 1310 (1311) елда язылган. Китап авторы

---

[1] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. – Икенче басма. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты, 1925. – Б. 256.

Галимнәр әлеге сюжетның Рабгузи әсәрендә чагылыш тапканлыгын искәртсәләр дә, алардан соңгы чор әдәбият белгечләре бу мәсьәләгә тиешле игътибар биреп җиткермәделәр.

үзеннән элгәреге (иң әүвәлгеләре VII–VIII гасырларда язылган) хезмәтләрдән файдаланган булуын күрсәткән[2]. Гомумән, Ислам дөньясында «Кыйссасел-әнбия», «Тарихе әнбия» исемендәге әсәрләр, ягъни пәйгамбәрләргә багышланган китаплар, Коръән сүрәләренә киңәйтелгән аңлатма-тәфсирләр һәм хәдисләр борынгы чордан ук – Мөхәммәт пәйгамбәр һәм аның сәхабалары заманыннан ук килә. Димәк, бу сюжетның да тамырлары Ислам мәдәниятенең башлангыч дәверләрендә үк билгеле булган дип әйтә алабыз. Коръәнгә тәфсир язуны Мөхәммәт галәйһиссәламнең икетуган энесе Габдулла бине Габбас (619–686) башлап җибәргән. Мөхәммәт галәйһиссәлам һәм аңа кадәрге пәйгамбәрләр тарихы турында VIII гасырның беренче яртысындагы галимнәр арасында Ибне Исхак (704–767) тәфсилле хезмәт язучы буларак танылган.

Ислам дине турындагы белешмәләрдә әйтелүенчә, мөселман риваятьләренең күбесендә патшабикәнең исеме Бәлкыйс дип аталган булса, кайчагында ул Йалмака дигән исем астында да язылган. Бусы борынгы йәмәнлеләр табынган Алмаха исеменә бик якын икән[3]. Белешмәләрдә шулай ук Бәлкыйс турындагы риваятьләрнең борынгы әсәрләр һәм елъязмалардагы, Тәүрат китабындагы Сава патшабикәсе (Царица Савская) турындагы хикәятләрдән башлангыч алуы, эфиоп халкының борынгы бер эпосына охшашлыгы әйтелгән[4].

Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» әсәренең Сөләйман пәйгамбәр турындагы бүлегендә «Кыйссаи Бәлкыйс» дип исемләнгән аерым бүлекчәсе бар[5]. Бу кыйссада Кояшка табынучылар яши торган Сәба вилайәтенең бик гүзәл һәм зирәк моликәсе (патшасы) Бәлкыйс турында сүз бара. Аның дәүләтенең һәм сараеның чиксез байлыгы, бик зур тәхетенең зиннәтлелеге тасвирланган. Сөләйман пәйгамбәр Бәлкыйсне Ислам диненә күнәргә өндәп хат язып, һөдһөд кошы артыннан юллый. Бәлкыйс Сөләйманның пәйгамбәрлеген сынау өчен төрле байлыклар (алтыннар, гәүһәрләр, энҗеләр һ.б.) җибәреп, үз сорау-табышмакларын күндерә. Бәлкыйснең илчеләре, Сөләйман пәйгамбәргә килеп, үзләренең кайбер эшләр белән «имтихан» кылырга җибәрелүләрен әйтәләр.

---

[2] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1881. – Б. 268.
[3] Ислам: энциклопедический словарь. – М.: Наука. Гл. ред. вост. лит., 1991. – С. 42.
[4] Шунда ук. – Б. 42.
[5] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 334–344.

Бәлкыйс Сөләйманга барлыгы биш төрле сынау-табышмак бирә. Ягъни, унике егетне кызлар киеменә һәм унике кызны егетләр киеменә киендереп, кайсысы кем икәнлеген аерырга кушкан була. Энҗегә һичбер адәм һәм пәри кулы тимичә җеп үткәрергә, икенче бер тишексез энҗегә шулай ук кагылмыйча гына, тишек тишәргә кирәк була. Ун ала ат, ун кара ат һәм ун акбүз атны аерып белергә, җир һәм күктә булмаган су белән ике касәне тутырырга кушыла. Аллаһы Тәгаләнең олы нигъмәтенә – кош-кортлар һәм табигать белән идарә итү сәләтенә ия булган Сөләйман галәйһиссәлам кушуы буенча агач корты энҗене тишә, җир корты аңа җеп үткәрә. Пәйгамбәр Җәбраил фәрештәнең ярдәме белән атларны аера. Атларны чаптырып, аларның тирләре белән ике савытны тутыра. Кызлар һәм егетләр кулларын юган чакта карап торып, суны азрак салганнары егетләр булуын, оялудан йә күбрәк яисә аз гына салганнары кызлар булганлыгын белә[6].

Сөләйман галәйһиссәлам биремнәрне башкарганнан соң Бәлкыйс үзе һәм аның халкы Аллаһы Тәгаләгә иман китерәләр. Сөләйман пәйгамбәр гаҗәеп чибәр Бәлкыйсне хатынлыкка ала. Рабгузи әсәренең Бәлкыйс турындагы кыйссасы текстында патшабикә үз исеменнән тыш, шактый урында «мәликә» дип аталган. Бу хикәяттә Бәлкыйснең йөзен ачып күрсәткәч, аның чибәрлегеннән Сөләйман пәйгамбәрнең һушсыз калуы, парсыз яшәүне шәригать хупламавы турында Сөләйманның Бәлкыйскә әйткән сүзләре бар. Бәлкыйс кыйссасының гомуми корылышы «Кыз хикәяте»нә һәм түбәндәрәк тасвирланачак башка әсәрләрнең сюжетларына шактый якын.

«Кыйссасел-әнбия»дә Бәлкыйс һәм Сөләйман пәйгамбәр турында сөйләнгән вакыйгалар Коръәннең «ән-Нәмел» сүрәсенә нигезләнгән. Бу сүрәнең 22–45 нче аятьләрендә һөдһөд кошының Сөләйман пәйгамбәргә Сәба[7] дигән җирдә Кояшка табынучылар яшәвен, аларның мәликәләре, байлыклары, зиннәтле зур тәхете турында хәбәр китерүе турында сөйләнә. (Коръәннең төп текстында ул патшабикәнең исеме әйтелмичә, «мәликә» дип кенә язылган). Сөләйман галәйһиссәламнең

---

[6] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 339–340.

[7] Татар телендәге элекке тәфсирләрдә Сәба атамасы төрлечә аңлатылган. Мәсәлән, «Сәба кабиләсе» (Тәфсире Ногмани тәкмиләсе. [2 җөзъэ]. – Казан: Милләт, 1911. – Б. 105) һәм «Сәба шәһәре» (Әл-мөҗәлләдес-сани мин тәфсири «Тәсһилелбәйан»: фарсы телендә улан мәүляна Хөсәен әл-Вагыйз әл-Кяшифи хәзрәтләренең тәфсиренең тәрҗемәседер / тәрҗ. Мөхәммәдсадыйк әл-Иманколый. – Казан: Үрнәк, 1911. – Б. 250).

хат язып һөдһөд кошы артыннан мәликәгә юллавы турында сүрәнең 28–33 аятьләрендә әйтелгән. 35 нче аятьтә мәликә тарафыннан Сөләйманның пәйгамбәрлеген сынау өчен бүләкләр җибәрүе турында язылган.

Коръәннең гарәп һәм фарсы телләрендәге электән килгән тәфсирләрендә язылганнарны дәвам итеп, татарча тәфсирләрдә Сәба патшабикәсе Бәлкыйс исеме белән шәрехләнгән[8]. Тәфсирләрдә бу вакыйгалар шактый иркен хикәяләнгән. Сөләйман галәйһиссәлам үзе дә Бәлкыйснең тәхетен алыштырып, аның акылын тикшереп карый. Бәлкыйснең иман китерүе турындагы сүзләрдән соң Ногмани тәфсирендә: «Соңра Бәлкыйсне Сөләйман галәйһиссәлам никахладымы яки юкмы – мөфәссирләр ихтилаф идәрләр» диелгән[9]. Ягъни, никахлашулары турында тәфсирчеләрнең фикерләре каршылыклы булуы әйтелә. «Тәсһилел-бәйан» тәфсирендә «Кыйссасел-әнбия» китапларында Бәлкыйснең Йәмән вилайәтенең падишаһы Шәрәхил бине Маликнең кызы булганлыгы турында әйтелгән дип искәртелгән[10]. Аның әтисе Шәрәхил, ә әнисе – җен кызы булган, имеш. Бәлкыйс атасыннан соң патша булып калган. «Тәсһилел-бәйан»да Бәлкыйскә бәйле язылган бик күп вакыйгалар Рабгузидагыга охшаш рәвештә, ләкин аермалары да бар. Рабгузида биш сорау-табышмак булса, бу тәфсирдә табышмаклар өчәү генә. Китапта ул вакыйга болай тасвирланган. «Бәлкыйс биш йөз егеткә кәнизәк кызлар киемене киертеп, кызлар кеби бизәде вә биш йөз кәнизәкне егетләр киеме киендереп, егетләр сурәтендә кыйлды». Шулар белән алтыннар һәм асылташлар белән бизәлгән бер таҗ, төрле бүләкләр арасында тишексез бер энҗене Сөләйман пәйгамбәргә җибәрә. Бу бүләкләрне алып барган ышанычлы кешесенә: «Әгәр ошбу егетләрне һәм кызларны аерып белсә, һәм тишексез энҗене тишекле әйләсә, һәм кыек вә кәкре тишелгән гәүһәрдән йеп үткәрсә – пәйгамбәрдер», – ди. Сөләйман пәйгамбәр энҗеләр мәсьәләсен кортлар ярдәмендә хәл итә. Ә егетләре белән кызларны шулай ук юынганда аера, ләкин башкачарак. Ягъни, егетләр сул кулларына комган тотып уң кулларына су салсалар, кызлар берсенең кулына икенчесе су сала[11].

---

[8] Тәфсире Ногмани... – Б. 105–108; Әл-мөҗәлләдес-сани мин тәфсири «Тәсһилел-бәйан»... – Б. 251–257.
[9] Тәфсире Ногмани... – Б. 108.
[10] Әл-мөҗәлләдес-сани мин тәфсири «Тәсһилел-бәйан»... – Б. 251.
[11] Шунда ук. – Б. 253.

XX гасыр башында татар авторларының пәйгамбәрләр тарихына багышланган күп санлы «Кыйссасел-әнбия» китапларында Сөләйман галәйһиссәлам һәм Бәлкыйс турында язылган. Мәсәлән, Габдрахман Гомәри китабында Йәмәндә падишаһлык иткән мәшһүр Бәлкыйс исемендәге патшабикәнең Сөләйманга килеп иман китерүен белдергәнлеге турында язылган[12].

Соңгы чорда басылган Коръән аңлатмалары китапларында да, элеккe тәфсирләргә нигезләнеп, «Кояшка табына торган бу гүзәл патшабикәнең исеме Бәлкыйс иде...» дип язылды[13].

Сөләйман пәйгамбәр белән Бәлкыйс вакыйгаларын галимә Әлфинә Сибгатуллина да кыскача тасвирлаган иде. Ул «Бәлкыйс исеме һәм шәхесе хакында Иран, һинд, хабәш, яһүди, төрки халыклар арасында риваятьләр иҗат ителгән» дип язды[14].

Рабгузи китабында Бәлкыйс кыйссасыннан башка да бу сюжетка охшаш урыннар очрый. Мәсәлән, Сөләйман галәйһиссәлам турындагы кыйссада түбәндәгечә рәвештә тасвирланган кыйтга бар. «Сөләйман ғаләйһиссәлям... бер шәһәрғә йитте. Ул шәһәрғә керде, мәлик сарайыға барды. Күрде кем, бер йирдә ғимарәт эшләйүрләр. Ул ғимарәт мәликнең қызының ирде. Ул қыз бүгүн тәфәрреҗ қыйлғалый килмеш ирде. Қыз үзе килеб, ул күшәккә тәфәрреҗ қыйлурда нагяһ Сөләйман ғәләйһиссәлямне күрде. Бисйар җәмаллық күңледә кичте... Қыз Сөләйман ғәләйһиссәлямғә әйде: «Әй, йегет! Ничек қайғулуқсын?.. Андин соң Сөләйман ғәләйһиссәлямне үз сарайыға алыб барды, кичә Сөләйман ғәләйһиссәлямғә қунуқлуқ қыйлды. Әйде: «Әй, йегет! Мин сәнгә тигәрмен». Сөләйман ғәләйһиссәлям әйде: «Мин – бер ғәриб, қачыб килгән кешемен, син – мәлик қызысын. Үзеңгә лайық кешегә тиггел», – тиде. Әйде: «Мин үзүмгә лайық бүгүн сине табыбмын. Мине мәликләр уғылы теләде – разый булмадым. Атам берлә ғәһед қыйлыбмын – һәркемне теләсәм, үзүмгә қабул қыйлсам, атам мине аңа биргәй...»[15]

---

[12] Әл-Әштерхани Габдрахман. Кыйссасел-әнбийаил-гыйзам вә тәрҗемәти әхвале дөвәлел-Ислам. – [Казан, 1900]. – Б. 17.

[13] Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре һәм аңлатмалары / матбугатка хәзерләүче – Р.Батулла. – Казан, 2000. – Б. 356.

[14] Сибгатуллина Ә. Суфичылык серләре (төрки-татар шигъриятендә дини-суфичыл символлар, образлар, атамалар). – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 1998. – Б. 68.

[15] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 329.

Садыйк Иманколый тәфсирендә «Ән-Нәмл» сүрәсенең 16 нчы аятенә аңлатмага өстәмә рәвештә «Задел-мәйсир» исемле китапта сөйләнгән бер риваять китерелгән. Анда Дауд галәйһиссәламнең 19 угылының һәркайсы әтиләре урынына падишаһ булуны дәгъва кылулары әйтелгән. Аллаһы Тәгалә күктән мөһерләнгән бер хат җибәргән. «Аның эчендә ничә мәсьәлә язылган иде вә боерылмыш иде кем: синең балаларыңдан кайусы ошбу мәсьәләләргә җавап бирсә – синдән соң урыныңга ул падишаһ булсын!» Дауд галәйһиссәлам аксакалларны җыеп, улларына мәсьәлә-табышмакларны бирә. Арадан бары тик Сөләйман гына дөрес җавапларны биреп, аксакалларның хуплавына ирешкән. Дауд галәйһиссәлам патшалыкны Сөләйман галәйһиссәламгә тапшырып, үзе икенче көнне вафат булган[16]. Менә бу мисалдан күренүенчә, мәсьәлә-табышмакларга дөрес җавап биреп, падишаһлыкка һәм, гомумән, мәртәбәгә ирешү турындагы риваятьләр әүвәлдә үк Коръәнгә һәм пәйгамбәрләргә бәйләп сөйләнелгән. Ләкин бу вакыйга Рабгузида бүтәнчәрәк хикәяләнгән. Анда Дауд галәйһиссәламнең угыллары унау булганлыгы, һәммәсе дә «галим вә фәкыйһ» (ягъни, шәригать хөкемнәрен яхшы белүче) булуы, Дауднның гомере ахырына җиткәч, Җәбраил фәрештәнең хат китергәнлеге әйтелгән. Җәбраил Дауд галәйһиссәламгә шул хатны ачмыйча укый алган угылың синең урыныңа калачак ди. Улларыннан фәкать Сөләйман гына хатның бер хәрефен дә ялгышмыйча укый алган[17]. Монда мәсьәләләр чишеп, җавап бирү турында сүз булмаса да, хатны ачмыйча укырга дигән сынау – үзе үк читен мәсьәлә булып тора.

## Борынгы әрмән телендәге «Егет һәм кыз турындагы хикәят»

Мөселман дәүләтләре белән чиктәш һәм күршедә яшәгән әрмән халкында да бу сюжетка иҗат ителгән әсәрләр киң таралган булган. Әрмән телендәге зирәк кыз турындагы хикәятләр үз галимнәре тарафыннан шактый өйрәнелгән. Моңа безнең әдәбият галиме Нәҗип

[16] Әл-мөҗәлләдес-сани мин тәфсири «Тәсһилел-бәйан»... – Б. 237. Монда әйтелгән «Задел-мәйсир» исемле тәфсир китабының авторы мәшһүр ислам дине белгече, фәкыйһ Ибне әл-Җәүзи (Җамалетдин Әбелфәраҗ Габдеррахман бине Гали, яшәгән еллары якынча 1116–1201) булган.

[17] Кыйссасел-әнбийаи Рабгузи... – Б. 304–305.

Исмәгыйлев игътибар итеп, А.Н.Срапян мәкаләсе турында мәгълүмат бастырган иде[18].

Срапян, нәкъ безнең «Кыз хикәяте»нә охшаш әсәрнең X гасырда гарәп теленнән әрмәнчәгә тәрҗемә ителеп, күп санлы кульязмалар рәвешендә һәм телдән сөйләнгән вариантларда таралганлыгы турында язган[19]. Әрмәннәр арасында бик популяр булган «Егет һәм кыз турындагы хикәят» (Повесть о юноше и деве) һәм «Кызның егеткә биргән сораулары» (Вопросы девы к юноше) исемнәре белән билгеле булган хикәятнең 33 кульязма күчермәсе мәгълүм булуын ачыклаган. Кульязмалар Ереван шәһәрендә Месроп Маштоц исемендәге Матенадаран борынгы кульязмалар фәнни үзәгендә саклана икән. Галим шулай ук чит илләрдәге китапханәләрдә һәм шәхси коллекцияләрдә әлеге әсәрнең күп күчермәләре булуын искәрткән. Хикәятнең Римда саклана торган иң әүвәлге – XIV гасыр кульязмасында әсәрнең X гасырда әрмән теленә тәрҗемә ителгәнлеге искәртелгән дип яза ул[20].

Әрмән галиме А.Н.Срапян тасвирлавынча, әрмән телендәге әсәрнең кыскача эчтәлеге бу рәвешчә. Бер байның бик акыллы улы әтисенең мал-мөлкәтен туздырып бетергән, әти-әнисен дә саткан. Шуннан соң бәхет эзләп чит илгә киткән. Ул, акылы-зиһене белән үзен уздырачак егеткә кияүгә чыгачагын игълан иткән чибәр һәм зирәк патша кызы турында ишетеп, сарайга юл тоткан. Анда 99 батыр егетнең башлары киселгәнлеге турында белгән. Бай улы кыз белән өч көн очрашып, сорауларга җавап биреп, җиңүгә ирешкән. Кызга өйләнеп һәм әтиәнисен дә үз янына алдырып, бәхетле тормыш кичергән.

Бу әсәр сюжеты башлангычта гарәп теленнән әрмәнчәгә тәрҗемә ителгән булса да, ул җирле шартларга һәм христиан диненә яраклаштырылган. Әлеге сюжетка нигезләнеп, әсәрнең төрле вариантлары һәм тармаклары язылган.

Шунысы кызыклы, әрмәнчә хикәят версияләрендә кыз белән егетнең өч мәртәбә көрешүләре, кызның егеткә барлыгы 21 сорау биргәнлеге, туй бәйрәменең җиде көн-төн дәвамында уздырылуы кебек күренешләр татарча «Кыз хикәяте»нә аваздаш, хәтта татар һәм әрмән телләрендәге әсәрләрнең исемнәре дә бер-берсенә охшаш булуы бик мөһим. Ягъни, әрмәннәр дә, татарлар да нигез итеп алган төп әсәр чы-

[18] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет // Казан утлары. – 1985. – №9. – Б. 181.
[19] Срапян А.Н. Армянские редакции повести о мудрой деве // Русская и армянская средневековые литературы. – Л.: Наука, 1982. – С. 70.
[20] Шунда ук. – Б. 71.

ганагы бер үк булган дип уйларга җирлек бар. Хәтта төп чыганакның X гасырдан әүвәл үк иҗат ителгән булуы да аңлашыла.

А.Н.Срапян хикәят вариантларында сюжетка яңача өстәмәләр кертелгәнлеген һәм сорауларның да күбәйгәнлеген язган. Ул шулай ук әрмән телендәге әсәр сюжетының нигезе «Мең дә бер кичә»дәге зирәк кыз Тәвәддүд турындагы хикәяткә аваздаш булганлыгын да искәрткән, аның әрмәнчәдән грузин һәм төрек телләренә дә тәрҗемә ителгән булуы турында язган[21].

## Низами поэмасы

Шәрыкнең мәшһүр шагыйре Низами Гәнҗәвинең (1141–1209) фарсы телендәге «Һәфт пәйкәр» (Җиде гүзәл) исемле поэмасының бер өлешендә шушы ук сюжет тасвирлана[22].

Низами «Һәфт пәйкәр» поэмасын 1197 елда язып тәмамлаган. Бу әсәрдә Бәһрам Гур исемле шаһ турындагы риваять язылган[23]. Иран шаһы Бәһрам җиде мәмләкәт патшаларының иң чибәр кызларына өйләнеп, һәрберсенә аерым зиннәтле сарайлар төзеткән. Үзе атнаның бер көнен шул сарайларның берсендә үткәргән. Бәһрамга һәр хатыны элеккеге сихри хикәят сөйләгәннәр. Сишәмбе көнне шаһның славян иле (төп текстта «вилайәте Рус» диелгән) хатыны дүртенче хикәятне сөйләгән. Менә шул хикәят «Кыз хикәяте»нә охшаш.

Анда әкияттәгедәй бай шәһәр патшасының ай кебек якты йөзле искиткеч чибәр, зифа буйлы һәм гаять белемле кызы булганлыгы сөйләнә. Дөньяда ул укымаган китап калмаган. Кыз шулай ук җанварлар һәм кошларның телләрен дә белгән, табигатьтәге бөтен серләрне аңлаган. Тик үзен кияүгә алырга теләүчеләрнең һәммәсен кире каккан. Ул кызның шөһрәте җир йөзенә көннән-көн киңрәк таралган саен, аның күңелен берсе көч белән, икенчесе алтыны-байлыгы белән яулап алырга теләүчеләр арта барган. Кызның әтисе – карт патша да бу хәлдән йөдәп беткән. Кызы кыя-тау башында кирмән төзеттереп, йөдәтүчеләрдән азат булыр өчен шунда яши башлаган. Чит-ятлар

[21] Срапян А.Н. Армянские редакции... – Б. 70–79.
[22] Низами Г. Собрание сочинений. В 5-ти т. Т. 4: Семь красавиц / пер. с фарси В.Державина; редкол.: Р.Алиев, М.Джафаров, М.Ибрагимов и др.; науч. подгот. текста, коммент. и словарь Р.Алиева. – М.: Худож. лит., 1986. – С. 199–217.
[23] Бәһрам Гур – Иран шаһы, сасанидлар династиясенең 421–438 еллардагы хакиме.

кирмәнсарайга кермәсен өчен кыз мәкерле тозак-җайланмалар көйләтеп куйдырган.

Кыз үзен алырга теләгәннәрдән бөтен хәйлә-тозакларны көче һәм акылы белән җиңәрлек, табышмакларына дөрес җавап бирердәй кешегә генә кияүгә чыгачагын, ә бу шартларны үти алмаучылар һәлак ителәчәген яздырып, рәсеме белән бергә шәһәр капкасына беркеттерә. Хәбәр бөтен дөньяга тарала. Үз яшьлекләре һәм кайнарлыклары белән шактый патша һәм солтаннар башлары чабылып, шәһәр диварына асыла. Бер егет, каннары түгелгән йөз меңләп баһадир өчен үч алу һәм башка күп асылзатларның гомерләрен саклап калу өчен дип, кызны яулау уена килә. Патшадан рөхсәт ала. Кызның мәкерле тозакларын җимереп, кирмән янына үтеп керә. Шуннан соң кыз бу егеткә үз әтисе сараенда көрешеп, табышмаклар әйтеп сынарга теләвен, дөрес җавап бирсә – никахлашырга риза булуын әйтеп, хәбәр күндерә. Егет атын шәһәргә юнәлтә һәм кирмән диварларындагы киселгән башларны хөрмәтләп җирләргә боера. Шәһәр халкын үз янына җыеп зур бәйрәм ясый. Халык егеткә «шаһ үз кызын сиңа бирмәсә, шаһны үтерәчәкбез дә, сине бөтен дөньяның падишаһы итеп күтәрәчәкбез» – ди. Кыз җир асты юлыннан әтисе сараена килеп, бу егеткә дүрт табышмак әйтәчәген белдерә. Иртән каһарман егет йөзе каплаулы кыз янына килеп, табышмакларга тоткарлыксыз җавап бирсен ди. Олыгайган шаһ иртән үз янына олуг галимнәр, укымышлы аксакалларны җыеп, шунда егетне дә чакырып, зурлап кунак итә. Кызның табышмаклары сүзсез генә, символик рәвештә була[24]: егеткә энҗе бөртекләре бирү, аларны ватып шикәргә бутау, сөткә кушу, йөзекләр, асылташлар алмашу һәм башка шундый нәрсәләр... Ахыр чиктә кыз әтисенә үзенең җиңелүен һәм моңа чиксез шат булуын белдерә. Кыз: «Бу егет кебек акыллы һәм матур кеше бөтен дөньяда булмас», – ди. Патша кызының бу сүзләренә чиксез шатлана һәм бизәнгечләр, йөзекләр белән сүзсез генә нинди серле сорау-җаваплар алышуларын аңлатуны сорый. Кыз табышмакларның серен аңлатып бирә. «Колаклардагы ике энҗене салып егеткә биреп, «тормыш ике көнлек кенә, аңлыйсыңмы?» – дидем. Ә егет үзеннән та-

[24] Низами поэмасында егет белән кызның бер-берсе белән төрле нәрсәләр аша мәгънәләр белдереп, сүзсез аңлашуына охшаш чалымнар XVII гасыр татар шагыйре Мәүла Колыйның «Береккәннәр сыйфаты» поэмасында да бар (Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Мәрданов Р.Ф. – Икенче басма. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2011. – Б. 27–29, 44–46.

гы өч энҗе бөртеге кушты һәм шуның белән «биш булса да, бик тиз үтәр» дигәнне аңлатты. Мин энҗене ватып, шикәр белән кушып удым һәм егеткә бирдем. Бу ике матдәне бер-берсеннән аеру мөмкин булмавы – бергә тормышның берничек тә – гыйлем белән дә, сихер белән дә аерылмаслыгын белдерә. Егет бу кушылманы сөткә салды: шикәре эреп, энҗе вагы савыт төбендә калды. Егет мәсьәләне шулай чиште. Аңа йөзегемне биреп, никахлашырга риза булуымны белдердем. Ә егет миңа кыйммәтле асылташ биреп, дөньяда бүтән лаеклы пар таба алмаячагын аңлатты. Мин исә аның асылташы белән бергә шундый ук икенчене кушып биреп, без икәү пар бит дигәнне белдердем. Егет шундый ук өченче асылташ эзләп һәм сайлап караса да, таба алмады. Бәхетенә күз тимәсен өчен миңа фирүзә ташы бүләк итте. Мәхәббәт асылташы түшемне бизәсен дип һәм егеткә буйсынуымны белдереп мин аны үзем тактым». Шаһ үз кызын зирәк егеткә кияүгә бирә, иртән оҗмах табынидай мул сый хәзерләтеп, туй мәҗлесе үткәрә. Бәхетле яшь пар гыйшык-мәхәббәт назына күмелә. Бу хикәят шуның белән тәмамлана[25].

«Һәфт пәйкәр» әсәренең башка урынында Бәһрамның төрки хатыны Ягманаз сөйләгән хикәяттә Бәлкыйс белән Сөләйман пәйгамбәрнең авыру уллары турында сүз бара. Ләкин анда безне кызыксындырган сюжет чалымнары юк.

Шагыйрь Низами иҗатын өйрәнгән галимнәр «Һәфт пәйкәр» поэмасының төп чыганакларын ачыклау шактый читен дип белдергәннәр[26]. Академик Бертельс бу уңайдан Низаминың халык авыз иҗатына бәйле төрле чыганакларны иркен фантазиясе белән кушып язганлыгын гомуми рәвештә генә искәрткән[27].

Галим Е.Э.Бертельс «Һәфт пәйкәр» поэмасын Низаминың аеруча камил әсәре дип бәяләгән[28]. Мәшһүр шагыйрь Низаминың иҗаты күп гасырлар дәвамында бөтен Шәрык, хәтта дөнья әдәбиятына көчле йогынты ясаган. Аның болгар-татар әдәбиятына, аерым алганда Кол Га-

---

[25] Низами Г. Собрание сочинений. В 5-ти т. Т.4: Семь красавиц.... – С. 199–217.

[26] Бертельс Е.Э. Низами: творческий путь поэта. – М.: изд-во АН СССР, 1956. – С. 158; Алиев Г.Ю. Темы и сюжеты Низами в литературах народов Востока. – М.: Наука, 1985. – С. 56.

[27] Бертельс Е.Э. Низами: творческий путь... – С. 173.

[28] Шунда ук. – Б. 195.

ли, Котб һәм Мөхәммәдьярга иҗади тәэсире турында галимнәребез язып килделәр[29].

Низаминың «Һәфт пәйкәр» әсәрен Шәрыкнең XIII–XIX гасырларда яшәгән утыздан артык авторы тәрҗемә иткән, аның сюжетына шундый ук яки башкача исемдәге үз поэмаларын язган. Шулай ук бу сюжетка чәчмә әсәр язучылар да булган. Аларның күпчелеге фарсы телендә иҗат итсәләр, төрек, азәрбәйҗан, үзбәк, төркмән, уйгыр, урду, һинд, грузин һәм бүтән телләрдә язучылар да булган[30].

Европа халыклары әдәбиятына да Низами иҗатының тәэсире зур булган[31]. Андыйлардан мисал өчен латин һәм итальян телләрендә иҗат иткән Лудовико Ариосто (1474–1533) поэмаларын, француз язучысы Ален Лесажның (1668–1747) 1729 елда куелган комик операсын, итальян драматургы Карло Гоццининың (1720–1806) «Турандот» трагикомик әкиятен, немец әдибе һәм фикер иясе Иоһанн Вольфһанг Гёте (1749–1832) әсәрләрен, австрияле Юзеф фон Хаммер (1774–1856) поэмасын атарга мөмкин.

Низаминың «Һәфт пәйкәр» поэмасының бик нәфис итеп күчерелгән 1611 елгы бер кульъязмасы Казан федераль университетының гыйльми китапханәсендә саклана.

Казан университетының Шәрык телләре кафедрасы профессоры, гарәп һәм фарсы телләрен укыткан Фридрих Франц Эрдман (1793–1863) Низаминың «Һәфт пәйкәр» поэмасындагы рус (славян) патшабикәсенең хикәятен 1832 елда фарсы телендә һәм немецчага тәрҗемәдә китап итеп бастырып чыгарган. «Хикайәте дөхтәри падишаһи

---

[29] Тарихтан – әдәбиятка. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – Б. 101–102; Шәрипов Ә. Фарсы һәм төрки-татар әдәбиятлары багланышы тарихыннан (XIII–XVI гасырлар) // Урта гасыр татар әдәбияты тарихыннан. – Казан: СССР ФА, Казан филиалы, 1981. – Б. 19–20; Фәсиев Ф. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы // Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) = Кул Гали. Кысса-и Йусуф (Сказание о Йусуфе) / төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кульъязмаларның тасвирламасын язучы Ф.С.Фәсиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1983. – Б. 186; Абилов Ш. Низами һәм татар әдәбияты // Казан утлары. – 1983. – №3. – Б. 166–171; Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.1: Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 146, 457–458, 481; Миннегулов Х. Татарская литература и восточная классика: вопросы взаимосвязей и поэтики. – Казань: изд-во ун-та, 1993. – С. 15–16, 98–129, 348.

[30] Алиев Г.Ю. Темы и сюжеты Низами в литературах народов Востока. – М.: Наука, 1985. – 332 с.

[31] Шунда ук. – Б. 4.

рус» исемендә Казан университеты матбагасында нәшер ителгән бу китап 1844 елда яңадан басылган[32].

Эрдман бастырган хикәятнең «эчтәлеге мавыктыргыч, халык иҗатына якын» дип бәяләнеп, аның эчтәлеге «Татар әдәбияты тарихы» китабында кыскача бирелгән иде[33].

Мәгълүмат тулылыгы өчен әйтергә тиешбез, бу сюжетка иҗат ителгән әсәрләр турында иң күп язган татар галимнәре Г.Газиз һәм Г.Рәхим, Х.Миңнегулов, Н.Исмәгыйлев татарча хикәятләргә Низаминың «Һәфт пәйкәр» поэмасы аваздаш булуы турында искәртмәгәннәр.

## Борынгы Шәрык хикәятләре

Шәрык әдәбиятында борынгы чорларда ук «Мең дә бер кичә» исеме астында тупланган хикәятләр, кысалы кыйссалар булганлыгы билгеле. Аларның бергә тупланып Шәрык халыклары, шул исәптән төрки-татарлар арасында саклануына һәм бөтен дөньяда популярлашуына гарәп-мөселман мәдәнияте сәбәпче. X гасырда Бәгъдадта хикәят-әкиятләр җыентыгы булган, аның төп нигезен якынча VIII гасырларда фарсычадан гарәп теленә тәрҗемә ителгән «Һәзар әфсанә» (Мең әкият) китабы тәшкил иткән[34]. Соңгырак чордагы хезмәтләрдә «Һәзар әфсанә» җыентыгы Персиядә безнең эрага кадәр 300 нче елда ук тупланган булганлыгы турында язылды[35].

Гарәп әдипләре бу әсәргә күп өстәмәләр һәм үзгәрешләр керткәннәр. Галим Х.Миңнегулов язуынча, «Мең дә бер кичә»нең хәзергәчә килеп җиткән төп редакциясе XIV–XV гасырлар арасында башкарылган. Х.Миңнегулов бу китапның өйрәнелү тарихын тикшереп, болай дип яза: «Димәк, «1001 кичә» – һәм хронологик, һәм урын ягыннан күпкатламлы күренеш. Ул төрле чорлар һәм төрле этник, социаль, идеологик сфералар белән бәйләнешле фольклор һәм язма әдәбиятның, дөресрәге, аларның синтезын үз эченә ала. Генетик яктан ан-

---

[32] Бертельс Е.Э. Низами: творческий путь... – С. 12–13; Каримуллин А. У истоков татарской книги. – Изд. 2-е, испр. и пер. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – С. 141.

[33] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.2: XIX йөз татар әдәбияты. – Казан: Татар. китап нәшр., 1985. – Б. 97.

[34] Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар: Поэтика һәм әдәби багланыш мәсьәләләре. – Казан: ун-т нәшр., 1988. – Б. 74–76.

[35] Гилемшин Ф.Ф. Особенности перевода «Тысяча и одной ночи» на татарский язык (язык и стиль). – Казань: изд-во «Мастер Лайн», 2001. – С. 4, 10.

дагы күп кенә образлар, сюжет-мотивлар, поэтик күренешләр теге яки бу дәрәҗәдә төрле халыкларга барып тоташа. Анда без Һиндстан, Иран, яһүд, грек, төрки һ.б. халыкларның мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән бәйләнешле факт-күренешләрне күпләп очратабыз»[36].

«Мең дә бер кичә»нең язылган вакыты, аның авторы белән кызыксыну электән фарсы һәм гарәп хикәятләренең бергә туплануы, Европа телләренә тәрҗемә ителеп, күп басмалар аша таралуы турында XX гасыр башындагы татар матбугатында да сүзләр булган[37].

«Мең дә бер кичә» китабы борынгы дәвердә үк төрле телләргә тәрҗемә ителеп, дөньяда киң таралган. Бу китаптагы сюжетларның төрки-татар әдәбиятына тәэсире көчле булган. Хатыйп Миңнегулов бу хакта болай яза: «1001 кичә»нең, андагы аерым хикәят-кыйссаларның безнең әби-бабаларыбызга бик күптәннән үк мәгълүм булуы, озак гасырлар буе халкыбызга гарәп, фарсы һәм кайбер төрки телләр аша да, татарча тәрҗемәләре һәм версияләре аркылы да рухи хезмәт күрсәтүе, күп кенә әсәрләр тууда материал-чимал, өлге итеп файдаланылуы язма әдәби фактлар белән дә раслана»[38].

Бу китапны Европа телләренә XVIII гасыр башында өлешчә һәм төрле вариантларда тәрҗемә итә башлаганнар. Француз теленә беренче тәрҗемәсе 1704–1717 елларда нәшер ителгән. Рус теленә «Мең дә бер кичә» 1763–1764 елларда французча, немецча һәм инглизчә басмаларыннан алынып тәрҗемә ителгән[39].

Бай тарихлы «Мең дә бер кичә» китабының 436–461 нче кичәләрендәге «Тәвәддүд турындагы хикәят»нең «Кыз хикәяте»нә охшаш урыннары бар[40]. Аның эчтәлеген кыскача бәйан итәбез.

Әүвәл заманда Бәгъдад шәһәрендә бик бай сәүдәгәр яшәгән. Ләкин аның бер баласы да юк икән. Варисы булмагач, күпме мал-мөлкәте юкка чыгачагына хәсрәтләнеп, бу сәүдәгәр көне-төне гыйбадәт кылып, Аллага ялынган, ялварган. Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итеп, улы дөньяга килгән. Сәүдәгәр бик шатланып, сәдакалар өләшкән, ятим-толларга ярдәм иткән. Малайга Әбелхәсән дип исем куйганнар.

---

[36] Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар... – Б. 78.
[37] Мөрасәлә вә мөхабәрә // Шура. – 1911. – №9. – Б.285.
[38] Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар... – Б. 114.
[39] Шунда ук. – Б. 79–80.
[40] Книга тысячи и одной ночи: в 8-ми томах / пер. с араб. М.А.Салье. Т. 5. – М, 1959. – С. 9–74.

Әбелхәсәнгә бик яхшы тәрбия биреп, аңа Коръән, шәригать, язу, шигърият, хисап, ук ату кебек гыйлемнәр һәм сәнгатьләр өйрәткәннәр. Ул бик белемле һәм чибәр, телгә-сөйләмгә оста егет булып үсеп җиткән. Тик әтисе үлгәннән соң, барлык байлыкларны таратып, күңел ачып туздырып бетергән. Шулай итеп әтисенең мирасыннан бер җариясе генә калган. Ә бу кыз искиткеч гүзәл һәм гаҗәеп тирән белемле икән. Әбелхәсән мөшкел хәлдә калгач, җария аңа хәлфә Һарун әр-Рәшид янына алып барып, үзе өчен ун мең динар сорарга тәкъдим итә. Әгәр кыйммәтсенсә, белемемне сынап карарга куш, ди.

Тәвәддүд исемле бу җария хәлифкә үзенең Коръәнне, шәригать, фикъһ, шигърият, тел белеме һәм башка бик күп гыйлемнәрне бик яхшы белүен әйтә, җырлап-биесәм – аздырып үтерә дә алам ди. Хәлиф кыз әйткән бөтен төрле гыйлемнәрнең иң яхшы белгечләрен чакыртып, сынап карарга була. Шулай итеп, дини мәсьәләләрдә – фәкыйһләр, дәва-шифа серләре турында – табиб, күк җисемнәре турында – мөнәҗҗим-астролог, дини фәлсәфә хакында – философ, бөтен төрле фәннәр турында ән-Нәззам Тәвәддүд белән очрашалар, кыз барлык сорауларга җавап бирә. Сынау ахырында һәрберсенә ул үзе берәр сорау биреп, белгечләрне җиңә. Җиңелүчеләргә җәза – алар өсләреннән киемнәрен салып, мәсхәрәгә калалар. Аннан соң кыз шахмат, карта һәм нәрд уеннары осталарын да җиңә. Иң ахырдан Тәвәддүд танбурда уйнап, һәммәсен таң калдыра.

Һарун әр-Рәшид күп акчалар биреп, кызны хуҗасына кайтара һәм алар бәхетле тормыш кичерәләр.

Тәвәддүд турындагы хикәяттә кызга бирелгән сораулар арасында «Кыз хикәяте»ндәге кебекләре дә бар. Мәсәлән, очу сәләтенә ия булган тугыз зат (черки, бал корты, һөдһөд, карга, саранча, ярканат һ.б.) телгә алынган. Шулай ук Йосыф пәйгамбәр туганнарының аны бүре ашады дип, үз әтиләрен алдаулары, нәсранилар һәм яһүдләр, балыкның сусыз тора алмавы, Юныс пәйгамбәрне балык йоту, җил, анадан тумаган затлар (Салих дөясе, Исмәгыйль кучкары һ.б.) турындагы сораулар һәм җаваплар «Кыз хикәяте»ндәге кебек. Кызның, үзенә Аллаһ ярдәм итәчәген әйтеп торуы һәм үзе сораулар биргәндә тизрәк җавап бирүләрен таләп итүе дә «Кыз хикәяте»ндәгегә аваздаш.

«Мең дә бер кичә»дән тыш, «Мең дә бер көн» исемендәге хикәятләр һәм кыйссалар җыентыгы да булган. Анысының да асылы борынгы Шәрык хикәятләреннән алынган. Бу китап 1710–1712 елларда француз телендәге басмасы аша таралган дип санала. Аны нәшер

иткән Көнчыгышны өйрәнүче галим Франсуа Пети де ля Круа (Петя де ля Кроа) фарсы теленнән тәрҗемә кылганлыгын белдергән. Ул фарсы телендәге әсәрне 1675 елда Исфаһан суфыйларының башлыгы Дәрвиш Мөхлистән алганлыгын әйткән. Фәндә «Мең дә бер көн»не гарәп, фарсы һәм төрек телләрендәге чыганаклар нигезендә Пети де ля Круа иҗат иткән дигән фаразлар да бар[41].

Галим Нәҗип Исмәгыйлев бу әсәрнең XVIII гасырда француз теленнән төрекчәгә тәрҗемә ителгәнлеген һәм аның «Әлфе нәһар вә нәһар» (Мең дә бер көн) исеме астында басылып таралуын яза[42]. Төрек телендәге әлеге китапны Идел-Урал татарлары да укыган. «Мең дә бер көн» һәм аның төрекчәгә тәрҗемә китапларындагы хикәятләрнең төп сюжетлары төрки-татарларга әүвәлдән үк таныш булган. Бу турыда Х.Миңнегулов болай дип белдерә: «1001 көн» бер бөтен китап рәвешендә татар теленә тулысынча тәрҗемә ителмәгән. Әмма андагы күп кенә сюжет-мотивлар, образлар, күренешләр татар укучыларына Пети де ля Круа эшчәнлегенә бәйсез рәвештә дә, Шәрык чыганаклары аркылы, Шәһризад хикәятләре кебек, күптәннән таныш»[43].

«Мең дә бер көн» французчадан рус теленә тәрҗемә ителеп, беренче тапкыр 1778–1779 елларда Петербургта басылып чыккан. Әлеге китаптагы «Шаһзадә Караф һәм Кытай патшасының кызы турында» дигән хикәят «Кыз хикәяте» поэмасының сюжетына туры килә.

Миңнегулов «1001 көн» китабындагы хикәятләрне татарлар арасында «Мәҗмугыл-хикәят» исеме астында билгеле булган җыентык белән чагыштырып, аларны «төп идеяләре, сюжетлары белән бу кыйссалар үзара якын торалар...» дип яза. Әдәбиятчы галим мондый нәтиҗәгә килгән: «Ике җыентыкны гомуми планда гына үзара чагыштыру да шундый фикергә этәрә: һәм Пети де ля Круа, һәм татар тәрҗемәчесе фарсы телендәге бер үк чыганаклар белән эш иткән булсалар кирәк. Ике арадагы уртаклыклар, охшашлыклар нәкъ менә шул файдага сөйли. Әмма һәр ике тәрҗемәче дә текстка үз халкының әдәби үсеше, рухи ихтыяҗлары ноктасыннан торып якын килгән»[44].

---

[41] Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар... – Б. 127–128.
[42] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет... – Б. 182.
[43] Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар... – Б. 137.
[44] Шунда ук. – Б. 137–138.

## «Мәликә китабы»

Әүвәлрәк кулъязма хәлендә таралган, XIX гасырдан XX гасыр башына кадәр кечкенә форматлы, 16 битле китапчык рәвешендә күп мәртәбә басылган һәм яратып укылган «Мәликә китабы»ның эчтәлеге белән танышыйк. Әсәрнең төп геройларыннан берсе – Рум шәһәрендәге Малик исемле падишаһның кызы. Ул бик акыллы һәм зирәк була, белемдә аңа тиңнәр табылмый. Аны егерме яшенә кадәр муллада укыталар. Атасы: «Шундый кызым бар, кияүгә биримме?» – дип, Мөхәммәт галәйһиссәламнән сорарга кеше җибәрә. Пәйгамбәр: «Никах – минем сөннәтем», – дип җавап бирә. Кыз: «Үзем кебек диндарга никахланырмын», – ди. Атасы вафат була, кыз аның урынына падишаһ дәрәҗәсендә тәхеткә утыра. Ул галимнәрне җыеп, үзенең йөз соравына җавап бирүчегә (падишаһ булса да, фәкыйрь булса да) кияүгә чыгачагын, дөрес җавап бирә алмаучыларга рәхимсез җәза булачагын белдерә. Төрле шәһәр һәм вилайәтләрдән кыз янына галимнәр агыла. Күпләр, җавап бирә алмыйча, дарга астырыла. Күпмедер вакыттан соң бу хәбәр Төркестанга да ирешеп, андагы Габделхәлим исемле бер фәкыйһ Рум шәһәренә килеп, мәликәгә (патша-кызга) керә. Кыз аңа: «Әй, йегет, сәнең дик күп йегетләр үлде, сән үләрсән!» – дип, фикереннән кире кайтырга өндәп карый. Егет аңа шигырьләп, болай дип җавап бирә:

Шөгъләи шәмгъ җәмалең бәхрене күргәч рәван,
Җандин пәрванә йаңлыйг кем кичдем һәман.

Ягъни, «шәм утыдай гүзәллегеңне күргәч тә, җанымнан күбәләк кебек тиз генә ваз кичтем» дип, Габделхәлим үзенең мондый гүзәл хакына һәлак булудан да курыкмавын белдерә[45].

Кыз күпсанлы сорауларын бер-бер артлы бирә бара, егет җавабын кайтарып тора. «Мәликә китабы»нда кыз чынлап та төп-төгәл бер йөз сорау бирә. Сорауларның барысы да диярлек Коръән, шәригать өйрәтмәләренә һәм Ислам дине тарихына бәйле.

---

[45] Борынгы Шәрык әдәбиятында, бигрәк тә суфыйчылык шигъриятендә шәм белән күбәләк символик образлары киң кулланылган. Яктылыкның гашыйгы утны яратуыннан үз-үзен корбан иткән. Сәгъди, Сәйф Сараилардан килгән бу шигъри символлар Габдулла Тукай һәм Дәрдмәнд иҗатларында да дәвам иткән (Сибгатуллина Ә. Суфичылык серләре (төрки-татар шигъриятендә дини-суфичыл символлар, образлар, атамалар). – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 1998. – Б. 245–246).

Китапта сорау-җаваплар «кыз сорды», «фәкыйһ әйде» рәвешендә, гади генә тасвирланган. Мәликә һәм фәкыйһнең бу бәйгесе тоташ бер көн эчендә барган кебек сурәтләнә. Һәрхәлдә, күпме вакыт дәвам иткәнлегенә ишарәләр юк. Фәкыйһнең җавабына карата кыз кайчагында дәлилләр дә сорый һәм егет Коръәннән дәлилләр китерә. Җаваплар аеруча камил булганда, мәликә канәгатьләнеп, «Саддака сәнең остазыңа!» дип, хуплау сүзләре әйтә. Бөтен сорауларга да төгәл җавап алгач, «кыз урыныннан сачрәб торыб... төркестани Габделхәлим гарифга буйун куйды – мән сәнең никахыңда булдым, тиде. Габделхәлим Төркестани кабул кыйлды. Кичә-көндез гыйш-гошрәт кыйлыб, морадыга йитде»[46].

«Кыз хикәяте» кыйссасының эчтәлеген тасвирлаганда авторның гыйлем байлыгын мал байлыгына караганда өстенрәк куюын әйткән идек. «Мәликә китабы»нда кыз егеттән турыдан-туры «гыйлем өстенрәкме яисә малмы?» дип сорый. Егет аңа гыйлем дәрәҗәсе өстенрәк булуын әйтеп-аңлатып бирә[47].

«Мәликә китабы» текстында «Кыз хикәяте» әсәрендәге сорау-җавапларга охшаш урыннар бар. Мәсәлән, «Кыз хикәяте»нең 105–107 нче бәйтләрендәге текстка аваздаш юллар: «Кыз сорды: ничә нәрсә атасы юк, кәлде китте? Фәкыйһ әйде: биш торыр. Әүвәл – Адәм ата, икенче – Хава ана, өченче – Исмәгыйль пәйгамбәрнең кучкары, түртенче – Салих пәйгамбәрнең тивәсе, бишенче – Муса пәйгамбәрнең гасасы»[48]. Болар арасыннан «Кыз хикәяте»ндә бары тик Муса пәйгамбәргә бәйле сүзләр генә юк. «Мәликә китабы»ндагы тагын бер охшаш сорау һәм җавап: «Кыз сорды: кем ирде дәрья эчендә балык карынында кырык көн гыйбадәт кыйлды? Фәкыйһ әйде: ул – Йуныс пәйгамбәр торыр»[49]. Болар «Кыз хикәяте»нең 100–101 нче бәйтләрендә дә тасвирланган. Шулай ук мәликәнең «кайу йыгач... утуз йафракы бар, һәр йафракының ике йөзе бар, бер йөзе – ак, бер йөзе кара...» дигән сорау[50] һәм аның җавабы «Кыз хикәяте»нең 129–133 нче бәйтләрендәгечә.

Төрле гөнаһлары өчен Аллаһның хөкеме белән кеше кыяфәтеннән бүтән төр җан ияләренә әверелдерелгәннәр турында «Мәликә кита-

---

[46] Мәликә китабы. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1883. – Б. 16.
[47] Шунда ук. – Б. 12.
[48] Шунда ук. – Б. 9; *гаса* – таяк.
[49] Шунда ук. – Б. 10.
[50] Шунда ук. – Б. 10.

бы»ндагы сорау һәм җаваплар да «Кыз хикәяте» текстына (183–219 бәйтләренә) аваздаш. Андыйларның саны «Мәликә китабы»ның 1883 елгы басмасында фәкыйһ тарафыннан «йегерме өч нәмәрсә» дип бирелсә дә[51], кыяфәт һәм рәвешләре үзгәртелгән 15 кенә затның исемнәре китерелгән[52].

Бу китаптагы кыяфәтләре үзгәртелгән нәрсәләр мәсьәләсенә тукталып, Г.Рәхим һәм Г.Газиз болай дип язганнар: «Андагы бәгъзе хорафат халык гаммәсенең [массасының – *Р.М.*] аңына да кереп өлгергән. Мәсәлән, төрле хайваннарның төрле гөнаһлы кешеләрдән азган булулары хакындагы, халык арасында бик таралган игътикад [инану – *Р.М.*], шушы китап тәэсирендә мәйданга килгән»[53]. Әмма монда күздә тотылган хорафатларның халык аңына сеңүенә «Мәликә китабы» гына сәбәпче булмыйча, Рабгузи кыйссасы, «Кыз хикәяте» һәм башка әсәрләр дә тәэсир иткәнлеген үз тарафыбыздан өстәп әйтергә тиешбез.

«Мәликә китабы»н Г.Рәхим һәм Г.Газиз татарлар арасында иң киң таралган гыйбрәтле хикәятләрдән дип бәяләп, болай язалар: «Ул бездә иң элек басылган хикәят китапларыннан. Кирәк өслүб, кирәк мөндәрәҗә [эчтәлек – *Р.М.*] ягыннан, 16 битле бу кечкенә рисаләнең һичбер төрле әдәби кыйммәте юк. Аның мөндәрәҗәсе бик садә...»[54]. Галимнәр китаптагы сораулар уңаеннан «Гомумән, бу сөальләр Робгузиның «Кыйссас»ында[55] төрле җирдә чәчелгән сөаль вә җавапларны хәтергә төшерәләр. Хәтта бер үк сөальләр тегендә дә, монда да очрыйлар» дигән фикер белдергәннәр.

Бу китаптагы Мәликә исеме – кыз исеме буларак язылса да, аның башлангычы Коръәндәге «Ән-Нәмел» сүрәсендә Сәба мәликәсе (патшабикәсе) дип аталудан һәм Рабгузи кыйссасында Бәлкыйснең «мәликә» дип язылуына турыдан-туры бәйлелектә каралырга тиеш.

---

[51] Мәликә китабы... – Б. 11.

[52] Бу китапның текстында әйтелгән саннарның һәр очракта да туры килеп бетмәгән урыннары тагын да бар. Мәсәлән, кызның бер соравында «йите нәмәрсә бер-берәдин туймаз...» дигән сорауга җавапта алты нәрсә генә аталган. Ягъни, «күз – бакмакдин туймаз, иркәк – зәгыйфәдин, ут – утындин, галим – гыйлемдин, бай – малдин, адәм гомере – яшәмәкдин туймазлар» (Шунда ук. – Б. 12).

[53] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере... – Б. 258.

[54] Шунда ук. – Б. 256–257.

[55] Рабгузиның пәйгамбәрләр тормышы һәм гамәлләренә, Ислам дине тарихына багышлап 1310 (1311) елда язылган «Кыйссасел-әнбийа» исемле, Казанда күп мәртәбә басылган мәшһүр әсәре күздә тотыла.

***

Г.Рәхим белән Г.Газиз шушы сюжетка язылган икенче бер әсәр турында да язганнар: «Мәликә китабы»ның асылы Урта Азиядән чыккан. Ихтимал, анда бу китапның берничә варианты бардыр. Безгә мәгълүм булганы белән Казан басмасы арасында байтак аермалар бар. 1911 нче елда Ташкәндә ташбасма белән басылган бу китап «Һәзар сөале мәликә вә данишмәнд» (Мәликә белән галимнең мең сөале) дип атала. 100 битле бу китап безнең Казан нөсхәсенә караганда күп зур; андагы сөальләрнең саны, китапның исеменнән күрелгәнчә, меңгә үк тулмаса да, йөздән байтак артык[56]. Арада бик озын сөйләнгән урыннар, хикәяләр һәм Казан басмасында булмаган сөальләр бар. Казан басмасында галимнең исеме Габделхәлим, Төркестан басмасында – Габделгали. Безнекендә мәликә сөаленә җавап бирмәгән галимнәрне дарга астыра, әмма Төркестанныкында богаулатып ун көннән үтертмәкче була. Ләкин, Рум шәһәренең «әкябире» [аксакаллар – *Р.М.*] җыелып килеп алар өчен үтенгәч, үтермиче, малларын гына мөсадәрә кылып [алып – *Р.М.*] җибәрергә күнә. Казан басмасында вакыйга Мөхәммәд пәйгамбәр заманасында була, әмма Ташкәнд басмасында «данишмәнд» – Имам Әгъзамның шәкерте була. Шул рәвешчә, әсәрнең мөндәрәҗәсендә булсын, телендә булсын, беркадәр аермалар бар. Безнең «Мәликә китабы» яки башка бер чыгытайча варианттан күчерелгән, яки татар язучысының үз тарафыннан үзгәртелгән вә кыскартылган булырга кирәк... Казан басмасында булсын, Төркестан басмасында булсын, «Мәликә китабы»ның кайчан язылуы хакында мәгълүмат юк. Безнең татар арасында ул басылганчыга кадәр кулъязмаларда йөргәнме-юкмы – белә алмадык. Һәрхәлдә, бу рисалә безнең халык каршында бик мәкъбуль китаплардан берсе булып, хосусан, катын-кыз аны яратып укучан иде»[57].

Әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллин «Мәликә китабы»н «күп укылып йөртелгән китапларның берсе» дип атый. Ул шулай ук «бу китап үзенең төзелеше белән үк без хәзер хикәя төшенчәсе астында аңлый торган жанрдан бик ерак тора. Аның эчтәлеге бик гади һәм үзе әкиятләрдә күп очрый торган формада башланып китә» дип, китапның

---

[56] Китап исемендә фарсы телендә язылган «һәзар» (мең) сүзе төп мәгънәсеннән тыш, «күп, бик күп» дигәнне дә белдергән. – *Р.М.*

[57] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере... – Б. 257–258.

эчтәлеген тасвирлый[58]. М.Гайнуллин Ташкент басмасын да телгә алып, аның Казан басмасы «Мәликә китабы» кебек үк, язылган вакыты күрсәтелмәгән булуын искәрткән[59].

Галим С.Хафизов «Мәликә китабы» турында традицион сюжетка корылган дип яза һәм «Мәликәнең шаһзадәләргә биргән сораулары дин, схоластикага бәйле сораулар. Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларында күп сурәтләнгән традицион сюжет биредә дини мотивлар белән сугарылган» дип бәяли[60].

«Мәликә китабы»ның кайчан иҗат ителгәнлеге турында галимнәрнең фикерләре каршылыклы. Бу мәсьәләдә Г.Рәхим һәм Г.Газиз «безнең татар арасында ул басылганчыга кадәр кулъязмаларда йөргәнмеюкмы – белә алмадык» диләр[61]. Татар китабы тарихы белгече, галим Әбрар Кәримуллин «Мәликә китабы»ның «борынгы чор әсәрләреннән» булганлыгын язып үтә[62]. Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов «Бу сюжетның «Мәликә китабы» дип исемләнгән бер варианты татарларга күптәннән таныш. Әүвәл ул кулъязма хәлендә йөри, 1846 елда Казанда басылып та чыга...» дип яза[63]. Кайбер галимнәр исә «Мәликә китабы» беренче тапкыр 1846 елда басылган булуга нигезләнеп, бу әсәрне ялгыш XIX гасырга нисбәт итәләр[64].

Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында (хәзер: Көнчыгыш кулъязмалары институты, Петербург) саклана торган төрки кулъязма истәлекләр каталогында «Мәликә китабы»ның барлыгы 13 кулъязмасы булуы күрсәтелгән[65]. Шулардан берсе XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында, икесе XIX гасыр башында күче-

---

[58] Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз: югары уку йортлары өчен. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – Б. 20–21.
[59] Шунда ук. – Б. 21–22.
[60] Хафизов С. XIX йөз татар прозасы. – Уфа, 1979. – Б. 22.
[61] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере... – Б. 257.
[62] Кәримуллин Ә. Китап дөньясына сәяхәт: татар басма сүзенең сәхифәләреннән. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – Б. 40.
[63] Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар... – Б. 138.
[64] Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз... – Б. 20; Хафизов С. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 22.
[65] Н.Исмәгыйлев андагы бүтән җыентыклардан да эзләп, барлыгы 17 кулъязмасын тапканлыгын язган иде (Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет // Казан утлары. – 1985. – №9. – Б. 180).

релгәннәр[66]. Менә бу факт «Мәликә китабы»ның XIX гасырдан элегрәк иҗат ителгән әсәр булуына ишарә итә. Ихтимал, ул XVIII гасырда яисә аннан да әүвәлрәк язылган булгандыр.

Г.Рәхим белән Г.Газиз «Мәликә китабы»ның тел үзенчәлекләренә карап, бу әсәрне «яки башка бер чыгытайча варианттан күчерелгән, яки татар язучысының үз тарафыннан үзгәртелгән вә кыскартылган булырга кирәк...»[67] дип билгеләүләре дә ачыклык кертүне таләп итә. Петербург Көнчыгышны өйрәнү институтында саклана торган 13 кульъязманың иң искесе, ягъни XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башына нисбәтлесе, Синцзяндә (Көнбатыш Кытайда) һәм җидесе Урта Азиядә, бишесе Идел буенда (татар җирлегендә) табылган булуына нигезләнеп фикер йөрткәндә, «Мәликә китабы»ның авторы төркестанлы (Урта Азияле) булу ихтималы зуррак кебек. Һәрхәлдә, «Мәликә китабы»ның төрле китапханәләрдә, архивларда һәм музейларда сакланган кульъязма күчермәләренең барчасын җентекләп өйрәнмичә торып, бу турыда катгый фикер белдерергә читенрәк.

Н.Исмәгыйлев үз мәкаләсендә «Мәликә китабы»ның 1846–1905 еллар арасында Казанда ун мәртәбә басылып чыгуын әйтеп, бу китапчыкның кыскача эчтәлеген бәян итә[68].

«Мәликә китабы» иске басмадан гамәлдәге татар язуына күчерелеп һәм теле бераз хәзерге татар теленә якынайтылып 2002 елда зур тираж белән басылып чыккан иде[69]. Аны Шәех Зәбиров белән Фәния Хуҗахмәт нәшер иттеләр. Бу басманың кереш мәкаләсендә Ф.Хуҗахмәт түбәндәге сүзләрне яза. «...Заманында бик тә кадерле дә, кирәкле дә китап булган ул... Ул әле күп әбиләрдә бар. Аны кат-кат кәгазьгә төреп, кадерле ядкәр итеп саклыйлар. Татар хатын-кызларының белеменә, укымышлылыгына әле хәзер дә сокланам... Нәкъ менә укымышлылык ягыннан хөрмәткә лаек алар. Кирәк чакта алар горур да, сылу-зирәк, акыллы-фикерле, тәвәккәл-кыю да. Борынгы төрки әдәбиятның бу гүзәл әсәренең төп герое Мәликә дә нәкъ шундый. Тирән белемле мөслимә гомерлек пар булырлык ирне, егет солтанын үзе эзли»[70].

---

[66] Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской академии наук. – М: Вост. лит., 2002. – С. 468–469.
[67] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере... – Б. 257.
[68] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет... – Б. 179–180.
[69] Мәликә китабы. – Казан: «Идел-Пресс», 2002. – 32 б.
[70] Шунда ук. – Б. 3–4.

***

Гали Рәхим һәм Г.Газиз тарафыннан тасвирлап үтелгән, Ташкентта 1911 елда басылган китапны без күрмәдек. Ләкин 1904 елда Ташкент шәһәренең В.М.Ильин матбагасында литография (ташбасма) ысулы белән басылган нөсхә белән танышу насыйп булды. Ул «Китабе мәликәи данишмәнд һәзар сөали мәшһүр мәга сөали мөтәфәррика» дип атала һәм 120 битне тәшкил итә. Исемен татарчага тәрҗемә иткәндә, ул «Укымышлы мәликәнең бик күп мәшһүр һәм төрле сораулары турындагы китап» дигәнне белдерә.

Бу китап Гали Рәхимнәр кыскача мәгълүмат биргән китапның бүтән, ягъни элегрәк чыккан басмасы булуы аңлашыла. Ләкин алар арасында кайбер аермалар бар. Әдәбият галимнәре 1911 елгы басманы 100 битле дип һәм укымышлы егетнең исеме Габделгали дип күрсәткән булсалар, без танышкан 1904 елгы басма 120 битне тәшкил итә һәм гыйлем иясенең (данишмәнднең) исеме Габделгалим дип язылган. Бу аермаларга карап, Ташкент басмаларының нигезләре бер үк, ләкин ике төрле кулъязма күчермәләреннән нәшер ителгәндер дип фаразларга мөмкин.

Ташкентта 1904 елда чыккан китапны тулырак күзаллау өчен, аның эчтәлеге белән танышыйк. Рум шәһәренең патшасы үлгәч, улы булмау сәбәпле, аның тәхетенә кызы утырган. Китапта ул «мәликә» (хатын-кыз патша) дип кенә язылган. Ягъни, мәликә – бу очракта кызның исеме түгел. Бер көнне ул галимнәр һәм укымышлыларны җыеп, «минем мең мәсьәлә-сөалем бар. Һәр кеше минең бу мәсьәләләремгә җаваб әйтсә – ушал кешегә үзүмне кабул кыйлыб, тәхет-падишаһлегемне бирүрмен», – ди. Мәликәнең бу сүзе шәһәрдән-шәһәргә, вилайәттән-вилайәткә – бөтен галәмгә тарала. Аның янына бик күп укымышлылар килә, ләкин сорауларның җавапларын әйтә алмыйлар. Мәликә һәммәсен бәйләп-богаулап куйдырта һәм ун көннән соң үтерергә дип хөкем кыла. Рум шәһәренең барлык олуглары киңәшеп, мәликә янына киләләр һәм боларны үтергәч, чын галим дә килергә куркыр бит дип, үтермәскә, мал-мөлкәтләрен генә алырга киңәш бирәләр.

Бу мәликә Рум шәһәрендә кырык ел падишаһлык кылган. Ләкин сорауларының дөрес җавапларын бирердәй галим табылмаган. Ул гүзәллеге, дин галимнәрен зурлавы белән бөтен дөньяда танылуга ирешкән.

Төркестан вилайәтенең мулла Габделгалим исемле бер галиме була. Ул Имам Әгъзам хәзрәтләренең шәкертләреннән икән. Шул Габ-

делгалим 40 көнлек юл узып, Төркестаннан Румга килә. Текстта аның мәликә белән беренче күрешкәндәге кайбер сүзләре шигъри юллар белән бирелгән. Мәликә галимгә болай ди:

Мең сөалемгә әгәр бирсәң җаваб,
Юк әгәр – каның түгүлүр нә саваб. *(Нә саваб – файдасызга)*

Данишмәнднең җавабы:

Ки мин пәрванәмән, сән – шәмгъдүрсән,
Йөзеңнең нурыдур чөн шәмгъ табан.

Җәмалең шәмгъдә пәрванә йаңлыйг,
Гаҗәб ирмәс ки мән пәрванәдүрмән.

Бу шигъри юлларның мәгънәсе алда тасвирлап үтелгән Казан басмасы «Мәликә китабы»ндагыча.

Ундүрт сорауга төгәл һәм тулы җаваплар алгач, мәликә галимгә: «Саддака синең остадыңа! Рәхмәт кыйлсун Ходай Тәгалә сәнгә!» дип, хуплау сүзләре әйтә (8 бит). Мәликәнең мондый мактау сүзләре китапта тагын берничә урында (46, 48, 59 һәм 120 битләрдә) кабатланган.

Мәликәнең кайбер сораулары катлы-катлы, ягъни бер мәсьәләнең җавабын алгач ул, тагын да ачыклык кертү өчен дәлилләр сорый. Галим дәлилләрне Коръәннән китерә.

Китапның бөтен тексты да «мәликә сорды» һәм «данишмәнд әйде» дигән сүзләр белән, сорау һәм җавап рәвешендә язылган. Галим егет җавапларының һәм дәлилләренең бер өлеше Рабгузи әсәренә аваздаш һәм якын. Җавапларның кайберләре озын булып, китапта берничәшәр биткә сузылган. Галим үзенең дәлилләрен тәфсилләп аңлаткан, мисал итеп кыска хикәяләр дә сөйләгән. Мәликәнең сораулары арасында Коръәндә ничә сүрә булуы һәм аларның ничек дип аталулары, шулай ук ничә аять булуы һәм аларның иңү сәбәпләре соралган. Хәтта Коръәндә ничә хәреф барлыгы да сорау итеп бирелгән. Данишмәнд барчасына тулы җавап тотып, Коръәндәге бөтен сүрә исемнәрен, ничә аять булуын һәм алар нәрсәләргә багышланганын, Коръәндә һәр хәрефнең ничә мәртәбә язылганлыгын (мәсәлән, «әлиф» хәрефе 40999 тапкыр, «би» хәрефе 5420 мәртәбә һ.б.) бәян итеп бирә.

Әсәрнең ахырында мәликә галимнең кем нәселеннән булуын сорый. Данишмәнд үзен хәзрәти Гомәр разый Аллаһының унберенче оныгы дип атый һәм үзе дә мәликәнең кем нәселеннән булуын сорый. Мәликә Искәндәр Зөлкарнәйн токымыннан булуын әйтә. Шуннан соң мәликә «мин сиңа үземне багышладым» дип, тәхеттән төшеп, да-

нишмәнднең башына патшалык таҗын кигерә һәм тәхеткә утырта. Барча укымышлылар, олуглар һәм аксакалларны җыеп, никах мәҗлесе үткәрелә, «алты айгача Рум шәһәрега аш бирде. Болар морадыга йиттеләр, гыйш-гошрәткә мәшгуль булдылар» диелә. Китап Рум патшалары шушылар нәселеннән, чын дөресен Аллаһ үзе белер дигән сүзләр белән тәмамлана[71].

Бу китапның исемендә сорауларның «һәзар» (мең) дип аталуы һәм мәликәнең «мең мәсьәлә-сөалем бар» дигәне дә төгәл мең дигәнне аңлатмый, ә гипербола-арттыру сүзе буларак кулланылган. Хакыйкатьтә, әлеге китапта мәликә тарафыннан барлыгы 200 сорау бирелгән. Шуларның утыздан артыгы дөньяви сораулар булып, калганнары барысы да ислам дине кануннары һәм тарихына бәйле мәсьәләләр. Дөньяви дип, шартлы рәвештә саналганнары да, дини өйрәтмә һәм аңлатмаларга бәйсез үк түгел.

Бу текстның башындагы дүрт һәм иң ахыргы битендәге хикәя сюжетына охшаш булган урыннарыннан тыш, калган өлеше бары тик сораулар һәм җаваплардан гына тора. Текст эчендәге берничә урында галимнең җавапларын хуплап мәликә әйткән «Саддака синең остадыңа!..» дигән сүзләреннән башка, хикәя сюжеты рәвешендәге әдәби бөтенлекне саклый торган берни дә юк. Әгәр бу текстның башындагы һәм ахырындагы өлешен, шулай ук мәликәнең хуплау сүзләре аерып алынса, китапның эчтәлегенә әлләни зарар килмәс тә иде. Ул иман һәм Ислам дине нигезләрен өйрәнү өчен сорау-җаваплардан торган белешмә китапка әверелер иде. Андый сорау-җавап методикасына – мәгълүмат үзләштерүнең чагыштырмача җиңелрәк ысулына нигезләнгән дини дәреслекләр татар мәдрәсәләрендә киң кулланылган. Сорау-җаваплардан торган, «Гыйльме халь» дип аталган, татар телендәге дәреслекләр XIX гасырда һәм XX гасыр башында бик күп басылган.

Ташкент басмасындагы кайбер сораулар һәм җаваплар «Кыз хикәяте»ндәгеләргә охшаш. Мәсәлән, «Кыз хикәяте»ндә анасыз туган дүртәү турында сүз барса (105–107 бәйтләр), Ташкент басмасында ата-анасыз туган алтау әйтелгән (Адәм галәйһиссәлам, Хауа ана, Исмәгыйль кучкары, Салих галәйһиссәлам тивәсе, Гайса галәйһиссәлам, Шис пәйгамбәр)[72]. Басма китаптагы «Мәликә сорды: Ул нә дәрәхтдүр

---

[71] Китабе мәликәи данишмәнд һәзар сөали мәшһүр мәга сөали мөтәфәррика. – Ташкент: В.М.Ильин типо-лит.-се, 1904. – 120 б.

[72] Шунда ук. – Б. 11.

ки: унике шахы бар, һәр шахыда утуз бәрге бар, һәр бәргенең бер йөзе – ак, бер йөзе – кара?» дигән сорау һәм аның җавабы[73] «Кыз хикәяте»ндәге 129–133 бәйтләргә туры килә. Бу очракта Ташкент басмасында сүзләр фарсыча бирелүе белән генә (дәрәхт – агач, шах – ботак, бәрг – яфрак) аерылып тора, ә мәгънәсе бер төрле үк. «Кыз хикәяте»ндә Кояшның зурлыгы 700 фәрсәх диелсә, басма китапта ул башкача – илле мең «фәрсәң» дип язылган[74]. Шулай ук басма әсәрдә мәликәнең «Ничә адәм сурәте мөбәддәл булган?» (үзгәртелгән – *Р.М.*) дигән соравына данишмәнднең: «Ун җан» дип җавап бирүе, мәликә исә аларның сәбәпләрен сорап, галимнең җавапларын әйтүе дә[75] «Кыз хикәяте»ндә бар. Ташкент басмасында андый затлардан «төлке, мүшүк, мәймүн, туңуз, эт, бүре, хичир, айык, фил, афтабпәрәст» саналган. Гөнаһ-сәбәпләрен әйткәндә «төлке – адәм иде...», «мүшүк – ...ялган сүзләде», «мәймүн – хатун ирде...», «туңуз – адәм ирде...» кебек, поэмадагыга аваздаш тасвирлар бар. Болардан башка, Ташкент басмасында Гайса пәйгамбәр һәм маидә, Юныс пәйгамбәрне балык йоту, Кабил белән Һабил вакыйгалары кебек, «Кыз хикәяте»ндәгегә охшаш мәсьәләләр бар.

Ташкентта басылган китап белән Казанда басылган «Мәликә китабы» бер-берсенә бик якын булуын әйтергә кирәк. Аларның кереш һәм бетем өлешләре бер-берсенә охшаш. Ике китаптагы галимнең исемнәрендә дә аерма зур түгел: Габделхәлим һәм Габделгалим. Бу китапларның төп аермасы – Казан басмасында сораулар төгәл бер йөз булып, Ташкентныкында ике йөз булуда. Казанныкында җаваплар кыска булса, Ташкентныкында алар шактый озын. Ләкин бу китап текстларының башта берсе (Казан басмасындагыча) язылган булып, икенчесе (Ташкентныкы) шуннан үстерелгән дип, яки, киресенчә, башта Ташкент басмасы варианты булып, аннан кыскартылган Казан басмасы барлыкка килгән дип кистереп әйтергә читен. Чөнки сорау һәм җавапларда уртаклык һәм охшашлыклар булган кебек, аермалар да бар. Һәрхәлдә, җентекләп тикшергәндә бу мәсьәлә-табышмакны чишеп була торгандыр. Шулай ук бу ике китапның башлангыч төп чыганагы бер үк булган дип әйтсәк – ялгышмабыз.

[73] Китабе мәликәи данишмәнд... – Б. 21.
[74] Шунда ук. – Б. 111.
[75] Шунда ук. – Б. 118–119.

## «Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгындагы Хәләф белән Чин кызы хикәяте

Татар әдәбияты тарихында шушы сюжетка язылган, эчтәлеге һәм теле буенча алда сөйләнгәннәргә бик якын торган чәчмә әсәр кергән туплам – «Мәҗмугыл-хикәят» исеме белән билгеле җыентык булуы мәгълүм.

Галимнәр «Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгының 1775 елда Себердәге Тубыл губернасы Тара өязендә Мөхәммәтрәхим бине Рәфыйк Казаный тарафыннан төзелгән һәм күчерелгән нөсхәсенә нигезләнеп, аны XVIII гасыр татар прозасы ядкәре һәм тәрҗемә әдәбият үрнәге дип яздылар. Ул җыентыкта барлыгы 33 хикәят тексты теркәлгән[76].

«Мәҗмугыл-хикәят»не башлап әдәбият галиме Хәй (Габделхәй) Хисмәтуллин (1895–1977) өйрәнгән һәм андагы ике хикәятне беренче мәртәбә фәнни әдәбиятта бастырган[77]. Аннан соң бу хикәятләр җыентыгын тәфсилләп өйрәнүче һәм текстларын матбугатта чыгаручы әдәбият галиме Нәҗип Исмәгыйлев булды. Галимнәрнең тикшеренүләрендә «Мәҗмугыл-хикәят» исемле җыентыкта тупланган текстлардан 24 хикәят беренче бүлектә һәм 9 хикәят икенче бүлектә урын алганлыгы язылган. Галимнәр ике кисәкнең дә бер үк кеше тарафыннан тәрҗемә ителмәгәнлеген искәртәләр. Беренче кисәк тәрҗемәчесе кем булганлыгы тәгаен билгеле түгел, ә икенче кисәкне Нурмөхәммәт бине Галим исемле каләм әһеле тәрҗемә итеп, «Мәҗмугыл-хикәят» дигән атаманы да ул биргән. Мөхәммәтрәхим бине Рәфыйк Казаный күчергән бу җыентык хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтындагы Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

Бу җыентык турындагы мәгълүматлар «Татар әдәбияты тарихы» китабында берникадәр буталчык һәм каршылыклы рәвештә басылды. Мәсәлән, хезмәтнең бер җирендә «Мөхәммәт бине Галим исемле татар әдибе «Мәҗмугыл-хикәят» исемле җыентыкны фарсыдан татарчага 1703 еллар тирәсендә тәрҗемә иткән» дигән юллар язылса[78], икенче урында җыентыкның 1775 елда Мөхәммәтрәхим бине Рәфыйк Казаный күчергәнлеге, икенче кисәген Нурмөхәммәт бине Галим тәрҗемә

---

[76] Мәҗмугыл-хикәят. Нәҗип Исмәгыйль күчермәсе. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – Б. 5–6.
[77] Борынгы татар әдәбияты. – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – Б. 503–521.
[78] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.1: Урта гасырлар дәвере... – Б. 393–394.

иткәнлеге әйтелгән[79]. Ә китап ахырындагы «Әдәбият-культура тормышы елъязмасы» бүлегендә: «Мәҗмугыл-хикәят» – хикәятләр җыентыгы (305 б.) XVIII йөзнең урталарында Мөхәммәд бине Галим исемле кеше тарафыннан фарсычадан татар теленә тәрҗемә ителгән...» дигән юлларны укыйбыз. Шунда ук дәвам итеп Мөхәммәтрәхим бине Рәфыйкның «Мәҗмугыл-хикәят»не күчереп язганлыгы әйтелгән[80].

Шул рәвешчә, «Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгындагы хикәятләрнең тәрҗемә ителү вакыты XVIII гасырга нисбәт ителеп, бу фикер фәнни әдәбиятта ныклап урнашты һәм кабатланып килә[81].

Н.Исмәгыйлев, алай да, сүз бара торган сюжетның «Мәҗмугыл-хикәят»тәге варианты XVII гасыр ахырларында ук тәрҗемә ителеп, XVIII гасыр дәвамында укылып йөргән һәм татарлар яши торган бөтен төбәкләргә таралган»[82] дип, әлеге хикәятнең әүвәлрәк язылганлыгы турында фикерен белдергән иде.

Әмма без, шәхсән, «Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгындагы бөтен хикәятләрнең дә XVIII гасырда югарыда исемнәре язылган укымышлы затлар тарафыннан тәрҗемә ителгән булуы турындагы фикер белән килешмибез. Шулай ук киң татар дөньясында таралып укып йөртелгән, хикәятләр антологиясе рәвешендә бергә тупланган ул җыентыкны Себер җирлеге белән генә бәйләп карау тарихи дөреслеккә туры килеп бетми дип саныйбыз. Чөнки җыентыкта урын алган кайбер хикәятләр аерым рәвештә бүтән күчермәләрдә дә очрый һәм табылып тора. Шундыйларга мисал итеп «Мәҗмугыл-хикәят»кә кергән

---

[79] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда... – Б. 419–420.
[80] Шунда ук. – Б. 549.
[81] Борынгы татар әдәбияты. – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – Б. 503–504; Исмәгыйлов Н. «Мәҗмугыл хикәйәт» (XVIII йөз) // Урта гасыр татар әдәбияты тарихыннан. – Казан: СССР Фәннәр академиясе, Казан филиалы, 1981. – Б. 85–100; Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.1: Урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 419–427, 531; Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет // Казан утлары. – 1985. – №9. – Б. 180, 183; Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар: поэтика һәм әдәби багланыш мәсьәләләре. – Казан: ун-т нәшр., 1988. – Б. 117, 137–138, 196; Миннегулов Х. Татарская литература и восточная классика: вопросы взаимосвязей и поэтики. – Казань: изд-во ун-та, 1993. – С. 317–318; Мәҗмугыл-хикәят. Нәҗип Исмәгыйль күчермәсе. – Казан: Татар. китап нәшр., 1994. – 446 б.; Исмәгыйль Нәҗип Нәккаш. Борынгы хикәятләрдә хатын-кызлар // Татарстан. – 1994. – №5–6. – Б. 135; Исмагилов Н. Сборник «Маджмуг ал-хикаят» как проявление литературных связей с Востоком // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.) – Казань: Фэн, 1999. – С. 216–223.
[82] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет... – Б. 180.

«Әбелфәварис хикәяте»н китерергә мөмкин. Бу хикәятнең XVIII гасырга караган ике һәм XIX гасыр башына нисбәтле бер күчермәсе Татарстан Милли китапханәсендә саклана[83]. Менә аларны – татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә табылган язма истәлекләрне – 1775 елда Себердә күчерелгән кулъязмадан соң гына таралганнар дип карау чынбарлыкка туры килә алмый.

Татар кулъязма истәлекләренең XVIII гасырдан борынгырак чорларда иҗат ителгәннәре иҗтимагый, тарихи һәм табигый сәбәпләр (сугышлар, күчләп чукындыру, тузу, таушалу, янып юкка чыгу, дингә каршы көрәш, башка төрле бәлаләр) аркасында аз сакланып калган. XVI–XVII гасырларда иҗат ителгән әсәрләр аеруча сирәк нөсхәдә генә очрый. Әүвәлрәк язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасының да йөзләгән күчермәләре арасында XVII гасырга караганнары санаулы гына, барысы да диярлек XVIII һәм XIX гасырлардагы кулъязмаларда сакланган. Менә бу хәлне исәпкә алып, галимнәр тарафыннан иске язма ядкәрләрнең иҗат ителү вакытларын билгеләгәндә, даталары күрсәтелгән кулъязма күчермәләре нигезендә, кайбер әсәрләрнең язылу вакыты ялгыш билгеләнүен әйтергә тиешбез. «Мәҗмугыл-хикәят»не тулаем XVIII гасыр әсәре дип белдерү – шундый хаталануларның берсе.

Кулъязма хәлендә гасырлар аша килеп ирешкән әдәби һәм тарихи истәлекләрнең аерым бер өлеше XIX гасырда татар укымышлылары тарафыннан бастырылган. Бу очракта да XVIII гасыр кулъязмалары билгеле булган һәм «Кыз хикәяте» сюжетына якын, «Мәликә китабы» исеме белән танылган әсәрнең 1846 елдагы беренче басмасына нигезләнеп, XIX гасыр әдәби истәлеге буларак ялгыш билгеләнүен дә әйтергә кирәк[84]. Югыйсә, борынгырак дәверләрдә иҗат ителгән һәм XVIII гасырдагы күчермәләре билгеле булган «Кисекбаш» һәм «Бәдәвам» китапларының да беренче басмалары 1846 елда гына дөнья күргән. Тик бу факт аларның XIX гасырда иҗат ителгәнлеген белдерми.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, әсәрләрнең иҗат ителү чорын кулъязманың күчерелгән вакытына һәм басма китапның нәшер ителгән еллары буенча билгеләп, соңгырак гасырларга нисбәт итү – әдәбият тарихыбызны өйрәнү дәвамында күзәтелеп килә торган ялгышлык.

---

[83] Китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендәге «1388 т», «1564 т», «1764 т» шифрлы кулъязмалар.
[84] Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз: югары уку йортлары өчен. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – Б. 20; Хафизов С. XIX йөз татар прозасы. – Уфа, 1979. – Б. 22.

«Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгындагы хикәятләрнең бер өлеше татар укучысына электән үк таныш булган. Соңгы вакытта дөнья күргән фәнни җыентыкларның берсендә «Мәҗмугыл-хикәят» тупламындагы хикәятләрнең «иң элеккеге фарсы чыганагы – 12 нче гасырның беренче яртысында барлыкка килгән «Мөниснамә» китабы» булганлыгы искәртелде[85].

Казан университеты китапханәсендә «Шаһзадә белән кыз» хикәясе буларак саклана торган «467 т» шифрлы кулъязмадагы хикәятнең дә борынгырак чорда тәрҗемә ителгәнлеге күренеп тора. Бу кулъязма тулы түгел һәм аның күчерелү датасы күрсәтелмәгән. Битләре буталган. Кәгазендәге су билгеләреннән дә елын ачыклап булмый. Ләкин, язу үзенчәлекләренә нигезләнеп, әлеге кулъязманы якынча 1750–1780 нче еллар арасында күчерелгән дип әйтә алабыз. Шушы кулъязма янында галим Нәҗип Исмәгыйлевнең 1985 ел декабрендә рус телендә язылган искәрмәсе дә саклана. Анда әлеге хикәятнең шаһзадә Хәләф белән Кытай принцессасы турындагы, Европада «Принцесса Турандот» исеме астында мәгълүм сюжетка нигезләнгән булуы әйтелгән. Шулай ук бу сюжетның татарларга XIV гасырдан билгеле һәм аның күп төрле вариантлары булганлыгы, ә бу кулъязмадагысы – «Мәҗмугыл-хикәят»тәге вариант икәнлеге («этот вариант – список из «Маджмуг эл-хикаята» (XVIII в.)) искәртелгән. Н.Исмәгыйлевнең бу очракта XIV гасырдан билгеле дигән сүзләрендә Ибраһим исемле автор 1382 елда иҗат иткән әсәрнең Петербургта саклана торган кулъязма күчермәсе күздә тотылганлыгы аңлашыла[86].

Тик университет китапханәсендәге бу хикәят текстының лексик составы һәм палеографик үзенчәлекләре – әлеге әсәрнең XVIII гасырдан күпкә элегрәк тәрҗемә ителгән булуын дәлилли. Мәсәлән, хикәяттәге XVIII гасыр өчен архаиклашкан гыйбарәләрнең кулланылуы һәм имлясында борынгылык элементлары аерымачык күренеп торуына караганда, әлеге текст «Кыйссаи Йосыф»ка, шулай ук Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорлары әдәби ядкәрләренә бик аваздаш. Шунлыктан, шаһзадә Хәләф турындагы хикәят төрки-татарчага фарсы теленнән якынча XIV–XV гасырларда тәрҗемә ителгән дип уйлыйбыз. Һәрхәлдә, бу XVI гасырдан соң тәрҗемә ителгән текст түгел. Университет китапханәсендәге әлеге хикәят кулъязмасында сүзләр нәкъ бо-

---

[85] XVIII йөз татар әдәбияты: Проза. – Казан: Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2012. – Б. 387.

[86] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет... – Б. 181.

рынгы чордагы язмалардагыча قرقو (қурқу), قلدى (қалды), ايچرو (ичәрү), سوچ (сөч), اوش (уш), قمو (қаму), سُز (сүз), يقدور (йуқдур), قرى (қарый), قچه (қуҗа), صتدم (сатдым), ددى (дэде), كُردم (күрдем), اوكنه (үгенә), قنوق (қонуқ), قريچق (қарыйчық), اولميسر (улмисәр), صغو (сағу), دكلن (дүгелән), كمدوكن (кем идүкен), اوترو (отру), بال‌آروسى (бал арусы), قرا (қара), سُيلب (сөйләб), كرن (керән) рәвешләрендә теркәлгән. Мондый имля XVIII гасырда иҗат ителгән яисә тәрҗемә кылынган әсәрләргә хас түгел.

Шигъри калыпта иҗат ителгән «Кыз хикәяте» белән әлеге чәчмә әсәр текстлары, шушы сюжетка корылган башка әсәрләргә караганда, бер-берсенә бик охшаш. Ике тексттагы аерым сүзләр һәм гыйбарәләрнең кайбер охшашлык-тәңгәллек мисалларын түбәндәге чагыштырма таблицада күрсәтеп үтәбез.

| ***чәчмә хикәяттә (университет китапханәсе, «467 т» шифрлы кулъязма)*** | ***«Кыз хикәяте»ндә (Татарстан Милли китапханәсе, «1764 т» шифрлы кулъязма)*** |
|---|---|
| бере қарый вә бере қуҗадыр болар... қаравыш *(1а кәгазь)* | қаравышум қарый, хуҗадур – қолум *(27 бәйт)* |
| ата бенде *(1б кәгазь)* | бенде атына *(36 бәйт)* |
| қарыйчыгың ун йәшәр уғлы вар иде *(3б кәгазь)* | ул қарыйның бер уғылы улмыш иде *(59 бәйт)* |
| күк алында *(3б кәгазь)* | күк алында *(65 бәйт)* |
| ниқабын йөзендән кәтерде *(7а кәгазь)* | ниқабын кәтерер *(89 бәйт)* |
| кичә иртәйә дәген *(7а кәгазь)* | кичәйә диген *(115 бәйт)* |
| Қыз әйтде: ул ағач нәдер кем – унике бодағы вар, һәр бодағының утуз йапрағы вар, һәр йапрағының бер йөзе – ақ, бер йөзе – қара? Шаһзадә: ел, унике айдур, һәр ай – утуз көндүр. *(11а кәгазь)* | Ул қыз әйдүр: «Қанқый ағачдур, вир хәбәр,<br>Ул ағачуң унике бодағы вар,<br>Дәкмә бер бодақда вардур утуз йабрақ,<br>Һәр беренүң иче – қара, ташы – ақ?»<br>Йегет әйдүр: «Ул әнкин сәһелдүр,<br>Ул ағачуң мәсьәләсе – бер йылдур,<br>Унике бодағы һәм унике ай,<br>Буны худ белүр қаму йуқсул-бай.<br>Һәр бодағында вардур утуз йабрақ –<br>Төнлә көндер: бере – қара, бере – ақ». *(129–133 бәйтләр)* |
| Кем – аңа вәхи кәлде, мәләк вә өнес вә җинн дәгүлкән? Шаһзадә: бал арусы, – дэде. *(11б кәгазь)* | ...Кем – вәхи әйләде аңа Чәләб?<br>Ул вәхи әйләдүге адәм дәгүл,<br>Нә җинндүр, нә инесдүр. Нәдер ул?»<br>Йегет әйдүр: «Бал орысыдур ғайан... *(141–143 бәйтләр)* |

| | |
|---|---|
| Кыз әйтде: ул йалан сөйләб җәннәтә керән вә ул гәрчәк сөйләб җәһәннәмә керән кемләрдүр? *(11б кәгазь)* | Ул нә қәвемдүр кем, йалан сөйләделәр,<br>Оҗмаға соңра алар керделәр?<br>Ул нә қәвемдүр гәрчәк сөйләделәр,<br>Тәңре әмрилә тамуйа керделәр?» *(145–146 бәйтләр)* |
| қапусын қақды *(9а кәгазь)* | қақды қапуы *(250 бәйт)* |
| ичрә керде *(9а кәгазь)* | керде ичәри *(251 бәйт)* |
| сәндән отру ул бәңа ғәййар *(9а кәгазь)* | сәндән отру җанымы өтә атам *(254 бәйт)* |

Чәчмә хикәяттә кызга тиңнәр «күк алында һәм йир йөзендә» юк дип язылган сүзләр «Кыз хикәяте»ндә «күк алында» буларак кыскача язылган. Шулай ук чәчмә текстта егетнең «кичә иртәйә дәген» (7а кәгазь) җавап тотуы шигъри әсәрдә «кичәйә диген» (115 бәйт) рәвешендә язылган. Чәчмә хикәяттә егет «әй, мадәр!» (3а кәгазь) дип эндәшсә, «Кыз хикәяте»ндә ул «И, ана!» (58 бәйт) дип мөрәҗәгать итә, текстның үзендәгечә әйтсәк, егет карчыкка «ана дәйү сөйләде» (61 бәйт). Ягъни, фарсы теленнән тәрҗемә ителгән әсәр буларак чәчмә текстта «мадәр» сүзе кулланылган булса, шигъри хикәят авторы, үз телебезгә якын итеп, «ана» дип язган. Хикәятнең чәчмә һәм шигъри вариантларындагы менә шундый охшашлыклар ике әсәрнең бер чордарак тәрҗемә ителгәнлегенә һәм чыганагы уртак булуга дәлил дип исәплибез.

Чәчмә хикәят героеның исеменә килсәк, борынгы чорда мөселманнар яшәгән илләрдә Хәләф атлы тарихи шәхесләр булган. Мәсәлән, фарсы-таҗик шагыйре, романтик поэмалар авторы Гонсыриның (Унсури, якынча 970–1040) үз чорының мәшһүр хөкемдары – газнәвиләр дәүләтенең[87] солтаны Мәхмүдне данлап язган бер әсәрендә Систан вилаятенең[88] Хәләф исемле хакиме телгә алынган[89]. Вәлиэддин Әбү Әхмәд Хәләф ибне Әхмәд унынчы гасырның икенче яртысында Систанның бәйсез хакиме булуга ирешкән. Ләкин ул солтан Мәхмүт белән каршылыкка кергәч, 1002 елда солтан Систанны яулап алган. Хәләф 1009 елда дөнья куйган[90]. Турандык турындагы мәшһүр хик-

[87] X–XII гасырларда яшәгән Газнәвиләр дәүләтенә хәзерге Әфганстан, Иран, Урта Азия һәм Һиндстанның аерым өлкәләре кергән.
[88] Систан – хәзерге Әфганстан һәм Иран дәүләтләре территориясендәге өлкә.
[89] Бертельс Е.Э. Избранные труды: история персидско-таджикской литературы. – М.: изд-во Вост. лит., 1960. – С. 319, 322.
[90] Шунда ук. – Б. 324.

әятләр сюжетының фарсы телендә иҗат ителгән башлангыч өлгесенә, бәлки, нәкъ шул – Систан хакиме Хәләф исеме алынган булгандыр. Уртак сюжетка ия хикәят текстларыннан «Мәҗмугыл-хикәят»тә, К.Гоццида, «Мең дә бер көн» китабының русча басмасында, Шиһабетдин Рәхмәтуллин әсәрендә, Васильев язып алган әкияттә егетнең исеме Хәләф (Каләф, Кулаф, Караф) буларак тасвирланган.

«Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгындагы әсәр «Шул хикәятдер кем, бер падишаһ Хәләф атлы угылы булып, Фәгъфур Чинның кызы белә берничә мәсьәлә араларында улып, күп вакыйгалар үткән хикәятләредер» дип исемләнгән. Хикәятнең эчтәлеге белән танышыйк. Борынгы заманда бик мәшһүр бер патша булган. Аллаһтан ялварып, күп изгелекләр кылганнан соң, аның күптән көтелгән бер улы дөньяга килгән. Бу шатлыктан патша халыкка тагын да мәрхәмәтлерәк булган. Яхшы тәрбия бирелгән уллары унбиш яшендә тирәнтен һәм күпкырлы гыйлеме белән аерылып торган. Егет гаскәри, идарәчелек һәм бүтән һөнәрләргә дә өйрәнгән, бик матур булган. Тик патша үз куанычын чикли алмыйча, тора-бара ялгышлыкка бирелеп, тиз заман эчендә бөтен ил-дәүләте бозыклыкка төшкән. Патшаны һәм улы Хәләфне ахыр чиктә шәһәрдән куганнар.

Болар тәмам хәерчелеккә төшеп, зарлы һәм ач хәлдә ил гизеп китәләр. Юлбасарлар талавына дучар булалар, михнәт чигәләр. Хәләф ата-анасына бу газапларның үз башларына Аллаһтан йөз чөергәннәре өчен җәза булуын аңлата. Дала-чүлләр аша күп җәфа чигеп, юлларын дәвам итәләр. Ниһаять, бер агач янында саф сулы чишмәгә юлыгалар. Шуннан соң, бара торгач, бер шәһәргә җитәләр. Мәчеткә җыелган халык аларга хәл кадәренчә ризык һәм киемнәр белән ярдәм күрсәтә. Хәләф, йөкче булып ялланып эшләп, тамак туйдырырга мөмкин булыр дип өметләнсә дә, уе тормышка ашмый. Аптырагач ул әти-әнисенә: «Йә, сез мине сатыгыз, яки мин сезне сатыйм – бу мескенлектән котылыйк», – ди. Ата-анасы үзләрен сатарга фатиха бирәләр, «Хак Тәгалә боерса, безне коткарырсың», – диләр.

Егет иртән хәсрәтләнеп базарга бара, бер урынга утырып елый. Шул заманда шәһәр патшасы берничә лачын белән ауга чыккан була. Лачыннарының берсе очып китә. Аны эзлиләр, таба алмыйлар. Бу кош Хәләф янына очып килгәч, егет аны тотып ала һәм шәһәргә юл тота.

Хәләф шаһ янына бара. Шаһ лачынын күреп сөенә, егетнең кем булуы турында сораша. Хәләф үзенең сәүдәгәр булганлыгын, әмма юлбасарлардан талануы турында сөйли. Аның матур итеп сөйләве шаһка

ошый. Хәләф шаһка «яшең озын булсын!» дип теләп, «бер карт колым белән каравышым бар» дип, сатып алуын үтенә. Атасы өчен ат, анасы хакына корал һәм бераз акча сорый. Егеткә ат, корал, йөз динар акча һәм шаһ үз өстендәге киемен бирә. Егет ата-анасы белән хушлашып, коллыктан коткарырга вәгъдә итеп атка менеп, юлга китә. Шаһ егетнең әтисен мәртәбәле йортка урнаштыра, әнисен хуҗабикә итә.

Хәләф юлда бер кешене очратып, икесе бер тарафка – Чин иленә юл тоталар. Хәләфнең юлдашы хат илтә бара икән. Ул Хәләфнең асылзатлылык сыйфатларын күреп, үзендәге язуны биреп, «син алып барсаңчы, мин хезмәтчең булып барам», – ди. Егет ризалаша. Тик юлда гарасатка очрап, ике юлдаш аерылыша. Шактый юл узганнан соң Хәләф хатның мөһерен бозып, язуын укый. Анда: «Бу язуны алып барган кешенең башын кисеп миңа җибәр. Шуның белән минем катымда бурычың тәмам була...», – дип язылган. Хәләф: «Хатның иясе аның эчтәлеген белгән, үзе урынына минем һәлак булуымны теләгән. Хак Тәгалә мәрхәмәт кылды, серне ачтым» – дип сөенә. Хатны ертып ташлый.

Ниһаять, ул Чин шәһәренә барып җитә һәм бер карчык өенә килә. Сәлам биреп, «И ана! Кунак сөясеңме?» – дип сорый. Карчык кунарга кертә һәм ун яшьлек улын егеткә ярдәмче итә. Хәләф патшага берәр хезмәткә керергә ниятләп, сораша. Карчык шаһларының гадел һәм яхшы булуын, аның дөньяда тиңсез, бик чибәр һәм акыллы бер кызы барлыгын, әмма канэчкечлеген әйтә. Ул кыз егерме яшендә булып, моңарчы биш йөз шаһзадәне нахакка һәлак итүен сөйләп бирә. Сәбәбе – никахлашырга сорап килүчегә йөзен ачып күрсәтә һәм аны тәэсирләндереп башын әйләндерә. Мәсьәләләр сорап, «дөрес җавап бирсәң – ярың булам, бирә алмасаң – җаныңны һәм малыңны алам ди». Кыз ун ел шулай мәшгуль икән.

Егет бу хәлгә бик гаҗәпләнә һәм үзе дә кыз янына барып, мәсьәләләренә йә җавап бирәм, йә башымны югалтам дип, бу явызлыкка чик куярга ниятли. Карчыктан рөхсәт сорый. Карчык исә елап, бармаска өнди, ялвара. Тик егет үзенең белеменә-көченә ышануын әйтә.

Хәләф иртән торып патша сараена китә. Сарай капкасындагы хезмәтчеләр ниятеннән кире кайтырга кыстыйлар. Егет «Аллаһның тәкъдире – үзе саклаучы» дип, фикереннән кайтмый. Кызга хәбәр итәләр. Кабул итәргә әзерләнәләр, тәхет ясала. Могтәбәр затлар, аксөякләр, галимнәр чакырыла. Фәгъфур патша егетне кызгана, рәхимсез кызы янына кермәскә үгетли. Егет үз сүзендә тора. Табын әзерләп, кунак итәләр.

Кыз килеп утыра. Йөзеннән япмасын күтәрә. Хәләф аның ай кебек йөзен күргәч тә, гашыйк була. Ләкин үзен кулга алырга тырыша. Кыз егеткә мәгълүм шартын җиткерә: йә җавап бирәсең, йә үләсең! Беренче көндә кыз бары тик ике сорау бирә һәм егет аңа җавабын кайтара.

Хәләф шатланып карчык өенә кайта. Елаган, кайгыга төшкән карчык егетне күргәч бик сөенә.

Шаһ та, бөтен халык та егетнең җиңүен теләп дога кылып торалар.

Икенче көндә кыз йөзен күрсәтеп, егетне һушсыз итә һәм сорауларын бирә. Бу көндә егет кызның 13 соравына җавап бирә. Кыз үзенең җиңеләчәген сизенә.

Өченче тапкыр очрашканда кыз егеткә сигез мәсьәлә бирә. Җаваплары алына. Кызның әтисе Фәгъфур бу бәйгенең дәвам итүен тыя, кызына: «Бу егет бөтен сорауларыңа җавап бирде. Инде син аның хәләл җефете буласың!» – ди.

Фәгъфур егеткә күп бүләкләр бирә. Иртән аны патша сараенда зурлап-хөрмәтләп каршылыйлар. Кыз атасы сүзенә күнсә дә, тагын ике сорау бирә. Егет үзе дә: «дүрт көн инде кызның мөшкел мәсьәләләренә җавап бирдем. Минем дә кызга бер мәсьәләм бар, җавап бирсен», – ди. Егет шулай итеп, үз башыннан кичкәннәрне сорау итеп бирә. Кыз җавабын иртәгә бирергә вәгъдә итә, үзе бик хафага төшә.

Төнлә ул бизәнеп-ясанып, шәрап һәм тәм-том алып, кәнизәген ияртеп егет янына китә. Ишекне кага. Егет ача һәм кызның гүзәллегеннән һушын җуя яза. Ашыйлар, эчәләр... Егеткә шәрап биреп, сәрхүш итәләр. Кыз егеткә үзенең кемлеген белдермичә, хәйләләп серен ала. Кыз качып китә.

Иртән егет аңына килә. Кыздан калган алтын-көмеш бизәнгечләрне һәм киемнәрен күреп гаҗәпләнә. Патша сараена бара. Анда ул кызга «төн уртасында тозакка бер кош эләккән иде, аны кыздырдым. Авызга кабам дигәндә очып китте, ә канат-каурыйлары миндә калды», – дип, киная белән хәлне аңлата. Шуннан соң кыз әтисенә үзен әлеге егеткә никахлатырга куша. Зур бәйрәм, тантана оештырыла.

Егет карчыкны һәм ата-анасын үз янына алдырта. Бераздан гаскәр җыеп, ата-анасы белән бергәләшеп үз дәүләтләренә кайталар һәм илләрен дошман кулыннан азат итәләр, падишаһлыкны үз кулларына алалар[91].

[91] Мәҗмугыл-хикәят. Нәҗип Исмәгыйль күчермәсе... – Б. 125–155.

«Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгындагы хикәяттә кыз Хәләфкә барлыгы 25 сорау биргән. Аның текстында «Кыз хикәяте»ндәге сорау-җавапларга аваздаш һәм охшашлары шактый. Мәсәлән, Юныс пәйгамбәрне балык йотуга бәйле сорау һәм җавап «Кыз хикәяте»ндәге 100–101 бәйтләргә охшаш. Атасыз һәм анасыз тере булган дүртәү: Адәм, Хауа һәм башкалар турындагы сорау белән җавабы «Кыз хикәяте»ндәге 105–107 бәйтләрдәгечә. Әюп пәйгамбәр турындагы сорау һәм җавап шулай ук ике текстта да бар, ләкин «Мәҗмугыл-хикәят»тә кыскача рәвештә. Бер шәһәргә кереп унике мең булып чыккан Йосыф пәйгамбәрнең кардәшләре турындагы сорау һәм җавап ике әсәрдә дә бер төрле («Кыз хикәяте»ндә 111–114 бәйтләрдә). Агач һәм аның ботаклары – ай һәм ел турындагы сорау белән җавап шулай ук ике текстта да бар («Кыз хикәяте»ндә 129–133 бәйтләрдә). Ялган сөйләп оҗмахка кергән һәм дөрес сөйләп тәмугка керүчеләр турындагы сорау һәм җавап та ике әсәрдә дә охшаш («Кыз хикәяте»ндә 144–152 бәйтләрдә).

«Мәҗмугыл-хикәят»тәге әсәрләрне өйрәнгән галим Нәҗип Исмәгыйлев охшаш эчтәлектәге әдәбият-сәнгать әсәрләре мәсьәләсенә багышлап махсус мәкалә язып бастырган иде[92]. Ул мәкалә әлеге сюжетка нигезләнеп язылган әсәрләр турында шактый киң мәгълүматны колачлый.

## Гоцци әкияте

Европалылар XVI йөздән башлап бу сюжетка нигезләнгән әдәби һәм сәхнә әсәрләре иҗат иткәннәр. (Бу хакта алдарак сүз булган иде). Шулардан иң танылганнарының берсе – итальян драматургы Карло Гоццины 1762 елда сәхнәләштерелгән «Турандот» исемле биш пәрдәлек әсәре. Авторы аны «Кытай трагикомедик әкияте» дип язган. Ул бу әсәрне «бик гүзәл сюжет» дип атаган. Гоцци тамашасы искиткеч зур уңышка ирешкән[93].

[92] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет // Казан утлары. – 1985. – №9. – Б. 179–183.

[93] Гоцци К. Сказки для театра: пер. с ит. / вступ. ст. Н.Томашевского; коммент. С.Мокульского; ил. Е.Катышева. – М.: Правда, 1989. – С. 208.

Әсәрнең авторы Гоцци «Турандот» пьесасына язган керешендә бу әсәре беренче тапкыр 1761 елның 22 гыйнварында Венециянең Сан Самуэле театрында уйналганлыгын язган. (Күрсәтелгән китап. – Б. 208). Тик галимнәр әлеге әсәр 1762 елда гына иҗат ителгән дип язалар (шунда ук. – Б. 7).

Карло Гоцци әсәренең төп катнашучылары болар (мәгълүмат төгәлрәк булсын өчен әсәрнең русчага тәрҗемәсендәгечә бирәбез): «Турандот – принцесса Китайская, дочь Альтоума; Альтоум – император Китайский; Адельма – принцесса Татарская, любимая невольница Турандот; Зелима – другая невольница Турандот; Скирина – мать Зелимы, жена Бараха; Барах – под именем Хассана, бывший воспитатель Калафа; Калаф – принц ногайских татар, сын Тимура; Тимур – царь Астраханский; Измаил – бывший воспитатель царевича Самаркандского; Панталоне – секретарь Альтоума; Тарталья – великий канцлер; Бригелла – начальник пажей; Труффальдино – начальник евнухов сераля Турандот; Палач; Восемь мудрецов китайского Дивана; Жрецы; Многочисленные невольницы прислуживающие в серале; Многочисленные евнухи; Воины»[94]. Болардан күренүенчә, Гоцци үзе фарсы телендәге әкият нигезендә итальянча яңа әсәр язганда кеше исемнәренең кайберләрен итальян исемнәренә якынайткан.

«Турандот» әкиятендәге персонажлардан дүртесенең исемнәре драматургның башка әсәрләрендә дә бар. Мәсәлән, бу авторның театр өчен язган җиде әкияте тупланган җыентыктагы пьесаларның һәммәсендә дә («Өч әфлисунга мәхәббәт», «Козгын», «Болан-король», «Турандот», «Елан хатын-кыз», «Яшел кошчык», «Дзеим – җеннәр патшасы, яки Тугры кол») Панталоне, Тарталья, Бригелла һәм Труффальдино исемнәрендәге король, министр, адмирал, шагыйрь, хезмәтче һәм башка вазыйфаларны гәүдәләндергән затлар булганын күрәбез[95]. Димәк, Гоцци төрле комедияләрендә шартлы рәвештәге бер үк кеше исемнәрен файдаланган.

Сәхнә өчен Карло Гоцци иҗат иткән әкиятләрнең русча басмасына кереш мәкалә язган Н.Томашевский «Принцесса Турандот» пьесасы бик борынгы дәверләрдәге фольклор әсәренә нигезләнгән дип яза. Ул үлем куркынычы астында өч табышмакка җавап бирү мотивлары антик чордагы Эдип һәм Сфинкс турындагы мифта да бар ди. Томашевский бу мотив XII гасырда Низами әсәрендә дә тасвирланганын әйтә. (Бу очракта Низаминың «Һәфт пәйкәр» поэмасы күздә тотылганлыгы аңлашыла). Ә Низами әсәре «Фарсы әкиятләре» исемле җыентыкка кертелеп, Гоццины шуннан файдаланып язган булуын белдерә[96].

[94] Гоцци К. Сказки для театра... – С. 209.
[95] Шунда ук. – 576 с.
[96] Шунда ук. – Б. 7. Монда «Фарсы әкиятләре» дип күрсәтелгән җыентык француз галиме Пети де ля Круа тарафыннан 1712 елда нәшер ителгән.

***

Томашевский телгә алган антик чордагы Эдип турындагы мифка килсәк, аның бер өлешендә, чынлап та, табышмакка бәйле вакыйга тасвирланган. Мәсьәлә ачыграк булсын өчен мифның ул урынын тасвирлап китәбез. Гәүдәсенең алгы өлеше кыз, ә калган өлеше арслан кыяфәтле, Сфинкс исемле, канатлы, дәһшәтле бер нәрсә Фива шәһәре янындагы бер кыяга урнашкан була. Ул шунда торып шәһәр халкына төрле табышмаклар әйткән. Табышмакны чишә алмаучыларны Сфинкс өзгәләп үтерә икән. Шәһәр хакимнәре, бу бәладән коткаручы булса, аңа Фива патшасы кызын кияүгә һәм патшалыкның яртысын бирәчәкләрен белдерергә мәҗбүр булганнар. Шул вакыт Эдип исемле каһарман кыядагы Сфинкс янына килә. Сфинкс аңа иртән дүрт аягында, көндез – ике, ә кичен өч аягында йөри торган җанварның нәрсә булуын сорый. Шулай ук аяклары күбрәк чакта хәрәкәтләре иң акрын булганлыгын да искәртә. Зиһенле егет, күп уйлап тормыйча, «кеше» дип җавап бирә. Ягъни тормышының иртәсендә ике кулы һәм ике аягында, көчле чагында ике аякта, ә картайгач таякка таянып йөрүен әйтә. Дөрес җаваптан хәвефләнгән һәм курыккан Сфинкс кыядан ташланып үзен һәлак итә. Ә Эдип вәгъдә ителгән бүләкләргә ия була[97].

***

Карло Гоцци әсәренең К.Тинчурин тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителгән текстының эчтәлеген түбәндә тасвирладык. Ике текст арасында аерма зур түгел.

Гоцци әсәреннән бик тәэсирләнгән немец шагыйре һәм драматургы Иоһанн Шиллер (1759–1805) аны алман теленә тәрҗемә иткән. Н.Исмәгыйлев язганга караганда, «Турандот» сюжетына нигезләнеп сигезгә якын опера иҗат ителгән[98]. Шулар арасында иң уңышлысы итальян композиторы Джакомо Пуччини (1858–1924) операсы булган.

Рус совет сәхнәсендә Гоцци әсәрен беренче мәртәбә 1922 елда режиссёр һәм драматург Евгений Вахтангов куйган.

2012 елның июль аенда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында, Казан шәһәрендә беренче тапкыр буларак, Джакомо Пуччининың «Турандот» операсы өлешчә башка-

---

[97] Грейвс Р. Мифы Древней Греции: пер. с англ. – М.: Прогресс, 1992. – С. 280; Немировский А.И. Мифы древней Эллады. – М: Просвещение, 1992. – С. 102.
[98] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет... – Б. 182.

рылды. Шушы ук елның 23 сентябрендә бу театр үзенең 74 нче иҗат сезонын Мәскәү режиссёры Михаил Панджавидзе куелышындагы әлеге опера премьерасы белән ачып җибәрде.

## Фатыйх Халиди хикәятләре

Мөхәммәтфатыйх Халидинең (1850–1923) Казанда 1897 елда басылып чыккан «Хикәят: Болгарның солтане гадил[99] Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе» исемле, сигез битле китапчыгы шул ук мәгълүм сюжетка нигезләнгән. Китапның тышлыгында ук автор «Бу хикәятне иске китаплардан җыеп яздым» дигән искәрмә биргән. Аның эчтәлеге түбәндәгечә.

Борынгы заманда Болгар шәһәрендәге Туктамыш исемле бер зур ханның Хәлимә исемле бик матур һәм гыйлемле кызы булган. Күп ханнар кызны үз улларына сорап яучылар җибәргән. Кыз әтисенә бер шарт куйган: килүчеләргә сорау биреп, дөрес җавап әйткәненә генә барачагын белдергән. «Мәһәр өчен шул – дөрес җавап булыр, бүтән нәрсә сорамам» дигән. Әтисе кызы белән ризалаша.

Бер көнне Сарайчык ханының бик белемле улы Нәзершаһ бу хәбәрне ишетә һәм Болгар шәһәренә килә. Туктамыш хан кызның шартын – «дөрес җавапны шаһ әйтсә дә, фәкыйрь әйтсә дә» кызын шуңа бирәчәген әйтә. Кыз кәгазьгә ике сорау язып бирә. Хан бөтен вәзирләр алдында бу язуны Нәзершаһка укый. Беренче соравы болай:

Ике бүре куйны йиды кан чыкармай,
Яхшы түрә дау бетерә җан чыкармай.
Уң кулымда уң йөзек – ал чыкармай,
Җавап биргәнеңә бән тигәрмән, мал чыгармай.

Кызның икенче соравы хикәят рәвешендәге озын табышмак итеп бирелгән. Анда Һиндстандагы бер шәһәрдә бер шаһның өч улы булып, аларны өйләндерергә хәзерлек тасвирлана. Шаһ вәзирләрен җыеп, диван корып, улларын берәмләп чакырып фикерләрен сорый. Өч улы да үз шәһәрләрендәге бер сәүдәгәр кызына өйләнергә теләүләрен әйтәләр. Шаһ һәммәсенә дә: «Яхшы, алып бирем», – ди. Бу хәлгә вәзирләр аптырап калалар. Шаһ хатыныннан сорашып белә – сәүдәгәрнең кызы бердәнбер һәм бик чибәр икән. Шаһ иртән улларын чакырып, өчесенә дә берәр мең алтын алып сәфәргә чыгарга һәм үзләре

---

[99] *солтане гадил* – гадел солтан.

күргән иң гаҗәп нәрсәне алып кайтырга куша. Сәүдәгәр кызы иң гаҗәп нәрсә алып кайтучыга булыр ди. Егетләр юл өчкә аерылган урында өчесе өч тарафка китәләр һәм өч айдан соң шунда ук күрешеп, әтиләре янына бергәләп кайтырга сүз куешалар.

Шаһның олы улы бер шәһәр базарында бик зур һәм калын көзге сатып ала. Аның хикмәте – уйлаган кешеңне көзгегә карап күрергә мөмкин икән. Уртанчы угыл бер шәһәрдә кош йонынннан тукылган хикмәтле палас сатып ала. Бу паласка күпме кеше утырса да һәм кая барырга теләсә дә, тиз арада очыртып илтә икән. Шаһның кече улы бер шәһәрдә тылсымлы, матур кызыл алма сатып ала. Ул алманың хикмәте шунда ки, аны кисеп үлгән кешенең ирененә тигерсәң, терелтә икән.

Өч бертуган очрашкач үз табышларын бер-берсенә күрсәтәләр. Олысы уртанчы һәм кече туганга көзгене күрсәткәч, болар сәүдәгәр кызы ни хәлдә икәнлеген күрергә телиләр. Көзге кызның вафат булганлыгын, җеназага хәзерләнүләрен күрсәтә. Егетләр хәсрәткә төшә. Ул арада уртанчысы паласны җәеп, тиз генә шәһәрләренә очып кайталар. Кече туганнары хикмәтле алманы кисеп кызның ирененә тигергәч кыз терелә. Егетләрнең һәрберсе әтиләренә үзләре сатып алган хикмәтле нәрсәләрен өстен итеп күрсәтергә тели. Шаһ «кайсысының әйбере хикмәтлерәк: кызны саклап калырга көзгеме, паласмы яки алмамы ярдәм иткән, кызны кайсысына бирик?» – дип, вәзирләренә мөрәҗәгать итә.

Туктамыш хан кызының шушы озын итеп язылган табышмак-хикәятен Нәзершаһка укып бирә. Нәзершаһ җавапларны хәзер генә әйтә алмаячагын, күпмедер вакыттан соң язу белән тапшырачагын әйтә. Ул Сарайчыкка кайтып галимнәр һәм укымышлы затлардан сораса да, кызның ике соравына җавап табылмый.

Өч ел үткәч Сарайчык шәһәренә Әхмәт исемле бер гарәп галиме килә. Нәзершаһ аңа Хәлимәнең сорауларын әйтә. Әхмәт, берничә көн уйлагач, сорауларның җавапларын таба. Беренче сорауның җавабы: бер кеше икенчесенә теле белән ялганлап, канын чыгармыйча тәмам эштән чыгара. «Яхшы түрә...» дигәне яхшы кеше үзе үлгәнче кешеләр белән алыш-бирешен бетереп ризалаша дигәнне аңлата икән. «Уң кулымда уң йөзек...» дигән сүзләре Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт – иманны чыгармыйча җанымны ал дигәнне аңлата. «Бән тигәрмән...» дигән сүзләре, боларга җавап бирүчегә чыгармын дигәнне белдерә. Шулай итеп Нәзершаһ Туктамыш ханга җавапны язып җибәрә. Туктамыш вә-

зирләре белән бергә бу җавапны дөрес дип табалар. Кыз да дөреслеген раслый һәм кияүгә барачагын белдерә. Туй ясап, Хәлимәне күп җиһазлар белән Сарайчыкка озаталар.

Китап авторы, укучыларга мөрәҗәгать итеп, Хәлимәнең икенче соравына дөрес җавап табуны уйлап карарга кушып, әсәрен тәмамлый[100].

Бу китап уңаеннан С.Хафизов болай дип язды: «Шунысы игътибарга лаек. Хәлимәнең сораулары схоластика өлкәсенә карамыйлар. Алар танып-белү характерындагы сораулар. Шулай ук бу әсәрдә кыз каршында уңышсызлыкка очраган шаһзадәләрне җәзалау телгә алынмый. Бу явызлыкны күрсәтү, күрәмсең, язучының этик карашларына җавап бирмәгән»[101].

Ф.Халиди иҗатын өйрәнгән галим Зөфәр Мөхәммәтшин мәгълүматынча, әлеге хикәятнең кыскартылган варианты әдип тарафыннан нәшер ителгән 1900 елгы календарьда да басылган[102].

***

Фатыйх Халидинең әле тасвирланганга аваздаш «Кемгә тиеш?» исемле тагын бер хикәяте Казанда Харитонов матбагасында 1904 елда сигез битле китапчык рәвешендә басылып чыккан. Аның тышлыгында һәм титул битендә «хикәят» дип күрсәтелеп, «холыксызларга шифа» һәм «Күрерсең теләгәнеңне көзгедән» дигән, гыйбрәтле хикәят булуына ишарә иткән искәрмәләр бирелгән. Эчтәлеге түбәндәгечә.

Болгар шәһәренең Җуҗи исемле шаһы тамак хастасы белән авырып, аны озак еллар күп табиплар дәваласа да, файдасы булмаган. Шуннан соң Чин мәмләкәтеннән Кәнфу исемле табипне китерткән. Табип шаһның авыруын дәвалап булачагын әйткән. Җиренә җиткереп дәвалау өчен бакчада, саф һавада галимнәр белән өч ай үткәрергә кирәк дигән табип. Ул шаһны дәвалап бер айда авыруын бетергән, ләкин холыксызлык хастасы калган. Шуннан соң Кәнфу, Җуҗи шаһ галимнәр һәм вәзирләре белән бергә зур каекка утырып йөзеп, «Волга иделенең» югары тарафына матур агачлы һәм чәчәкле урында төшәләр. Анда чатырлар корып, төрле уеннар белән шаһның кәефен

---

[100] Халиди Мөхәммәтфатыйх. Хикәят: Болгарның солтане гадил Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе. – Казан, 1897. – 8 б.
[101] Хафизов С. XIX йөз татар прозасы. – Уфа, 1979. – Б. 23.
[102] Мөхәммәтшин З. Фатих Халидинең иҗат мирасы. – Казан: Таң–Заря, 2001. – Б. 45.

табарга тырышалар. Бер ай буе төрле кыйссалар сөйләсәләр дә, шаһның холыксызлыгы бетми.

Бер көнне Кәнфу: «Әй, шаһе җәһан! Гомереңез озын булсын! Бер хикәят сөйлим», – дип, үзенең Һиндстанга баргач Габбас шаһ янында утырганда бер сәяхәтче килеп шаһка үтенеч белән мөрәҗәгать иткәнен сөйли башлый. «Дөньяда сездән дә зур галим юк, минем сорауга сез генә җавап бирә аласыз» дип, гозерен әйтә. Ул Фас (Марокко) шәһәренең солтаны Әюпнең вәзире икән. Солтан Әюпнең өч улы бар. Хатыны фаҗигале бер гаилә хәле уңаеннан солтан Әюпкә: «Шаһ кызы булса булсын, гида кызы булса булсын...» – дип, улларына үзләре сөйгән кызларын хәләл җефетлеккә алырга кирәклеген искәрткән. Шаһ риза булып, өч улын да аерым-аерым чакырып, кем белән кавышырга теләсәгез – ихтыярыгыз ди. Тик өч бертуган да бер үк кызны – үз шәһәрләрендәге буяучы Габдеррәшитнең кызы Сәхәреннисаны алырга теләүләрен белдерәләр.

Икенче көнне шаһ барлык вәзирләрен җыеп, улларының ихтыярын һәм үзенең алып бирергә вәгъдә итүен әйтеп, киңәш сорый. Аңа һәр улына берәр мең алтын биреп, һәрберсенә нинди дә булса гаҗәп әйбер алып кайтырга кушарга, кызны иң хикмәтле нәрсә алып кайтканына никахландырырга киңәш итәләр. Егетләр атка атланып мәмләкәттән читкә китәләр. Бер ай узгач олы агалары әйтүе буенча өчесе өч тарафка юнәлә һәм өч айдан соң бер үк җирдә – зур таш янында күрешергә сүз куешалар. Шаһның олы улы бер базарда карбыз кебек көзге күрә. Теләгән нәрсәне күрергә мөмкин булган бу көзгене ул мең алтын түләп сатып ала. Уртанчы егет бер калада кош мамыгыннан эшләнгән палас ала. Аны җәеп, өстенә күпме кеше утырса да, теләгән якка тиз арада очыртып алып бара икән. Паласны егет бер мең алтынга ала. Кече энеләре бер карттан якут кебек кызыл, серле алманы бер мең алтынга сатып ала. Аның хикмәте – вафат булган кешенең ирененә алманы кисеп тигерсәң, терелтә икән.

Өч агай-эне очрашалар. Сәхәренниса хәзер ни эшли икән дип көзгедән карыйлар. Ни кызганыч, кыз вафат булган икән, егетләр паласны җәеп, күз ачып йомганчы шәһәрләренә очып кайталар. Кече энеләре алманы кисеп кызның ирененә тигергәч – кыз терелә. Шуннан соң шаһның уллары әтиләренә: «Кыз кайсыбызга тиеш?» – дип мөрәҗәгать итәләр. Солтан Әюп бу мөшкел мәсьәләне чишә алмыйча, Һиндстан шаһыннан сорарга вәзирен җибәргән икән.

Кәнфу Җуҗи ханга шушы вакыйганы сөйләп, хан шул табышмак белән баш ватып, холыксызлыгыннан сихәтләнә.

Автор хикәяне укучыларга мөрәҗәгать итеп, «холыксыз булсагыз, Сәхәреннисаның кемгә тиеш булганлыгын уйлап хәл итсәгез, холыксызлык хәстәгезгә шифа булыр» дип тәмамлаган[103].

Әдип һәм фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт (1899–1992) Ф.Халидинең алда әйтелгән ике китабын искәртеп, болай дип яза. «Әкиятләрдә табышмакларның нинди урын тотуына мисал итеп Туктамыш хан кызы Хәлимә әкиятләрен искә төшереп үтәргә була. Бөтен сюжеты белән табышмактан торган әкиятләр дә булырга мөмкин. Мәсәлән, Ф.Халидинең 1904 нче елны «Кемгә тиеш» исеме астында бастырган халык әкиятендә өч бертуган егет бер кызны үлемнән коткарып, кызның кемгә чыгарга тиешлеген чишә алмыйлар»[104]. Ф.Халиди бастырган китапларны Н.Исәнбәт халык әкиятләре дип атаган.

## Шиһабетдин Рәхмәтуллин әсәре

Шиһабетдин Рәхмәтуллинның Казанда 1903 елда басылып чыккан китабы да шушы сюжетка корылган[105]. Ул бу әсәрен төрек телендәге «Әлфе нәһар вә нәһар» (Мең дә бер көн) исемле әсәргә нигезләнеп иҗат иткән. Рәхмәтуллинның «Каләф берлә Турандук хикәяте» дип аталган әсәренең тышлыгында һәм титул битендә «Әлфе нәһар» исемле китаптан алып язылганлыгы искәртелгән.

Шәрык-татар әдәби багланышлары турында Габдрахман Таһирҗановның фикерләре кызыклы. Мәсәлән, ул болай дип язган: «Шәрыктә формалашкан сюжетларга әсәрләр язылуны, аларның кат-кат басылып чыгуын төгәл күзалларга ярдәм итә торган янә бер мисалга мөрәҗәгать кылыйк. 1330 елда Һиндстанда Зиятдин Нахшәби дигән автор һинд фольклорында тутый кош турындагы маҗаралы хикәяләр нигезендә фарсыча «Тутый намә» әсәрен иҗат иткән. (Монысы югарыда исеме аталган «Тутый-намә»дән мөстәкыйль әсәр). Менә шундагы сюжетлардан, риваятьләрдән файдаланып, Шиһабетдин ибне Габделгазиз

[103] Фатыйх Халиди. Кемгә тиеш? – Казан: Харитонов матбагасы, 1904. – 8 б.
[104] Татар халык табышмаклары. Кереш мәкалә һәм аңлатмалар белән / җыючысы һәм төз. Н.Исәнбәт. – Казан: Татар. китап нәшр., 1970. – Б. 62.
[105] Шиһабеддин бине Габделгазиз бине Рәхмәтулла. Каләф берлә Турандук хикайәте: «Әлфе нәһар»дан алынып тәртип ителде. – Казан: Типо-литография и словолитня Т. Д. Бр. Каримовых. – 1903. – 120 б.

исемле кеше «Кылаф берлә Турандук хикәяте» дигән китапны язган. Бездә киң таралган «Мәликә китабы» да шул ук материалга нигезләнгән»[106].

Рәхмәтуллин китабының тышлыгында әсәрнең кыскача эчтәлеге дә бәян ителгән. Ул түбәндәгечә: «Нугай ханы Тимүрташның тәхетене, дәүләтене Карәзем солтаны алганның соңында күп җәфалар чиккәне. Бәгъдә Чин падишаһы кызы Турандукның сөальләренә ничә вә ничә шаһзадәләр җавап бирә алмаган соңында Тимүрташ хан угылы Каләф, күп фөнүнгә маһирлегеннән җавап биреп, Турандукны җефетләнгәне. Тимүрташның тәхете, дәүләте кайтарылып, Карәзем солтанының тәхете дәхи алынып, Каләф анда падишаһ булганы. Эчендә Мусыл падишаһы Фазлуллаһ берлән зәүҗәсе Зөмәррәд хикәясе һәм мәүҗүддер»[107].

Бу әсәр күләмле булганлыктан, аның эчтәлеген тасвирлау да озынрак булыр.

Борынгы заманда Кәшмир патшасы Туранбәкнең Фәрхәназ исемле бик сылу һәм гүзәл, гаять гыйлемле кызы булган. Аны төрле илләрнең шаһзадәләре (шаһ һәм патша уллары), кайсы үзен, башкасы рәсемен күреп яисә кыз турында ишетеп яучылар җибәргәннәр.

Бервакыт Фәрхәназ төш күргән. Ул төшендә бер ата кыр кәҗәсе тозакка эләккәч, аны ана кәҗә коткаруын һәм шунда ук үзе икенче тозакка төшүен, ләкин ата кәҗәнең ярдәм итмичә ташлап киткәнлеген күрә. Бу төш тәэсире белән Фәрхәназның дөньядагы бөтен ир женессннән күңеле кайта. Мәҗүси кыз үзенең табына торган сыны шул рәвешле кисәтте дигән нәтиҗә ясый. Әтисенә үз ризалыгыннан башка кияүгә бирмәскә үтенеп, вәгъдәсен ала. Әтисе, күңеле йомшарып, ант итә. Шулай итеп, кызны ярәшергә килгән илчеләрне кире борып җибәрәләр. Туранбәккә үпкәләп тә, янап та китәләр. Кызының дайәсе (тәрбиячесе) аша патша бу хәлгә төш сәбәпче булганлыгын белеп ала. Ул дайә белән киңәшә. Дайә «кыйссалардан хисса алынырлык күп хикәяләр беләмен» дип, шуларны сөйләп Фәрхәназның ирләргә булган нәфрәтен сүрелдерергә тырышачагын әйтә.

Фәрхәназга шактый хикәяләр сөйләгәннән соң, нәүбәттәге берсе итеп дайә «чын инсаннар җөмләсеннән нугай хан шаһзадәсе Каләф»

---

[106] Таһирҗанов Г. Тарихтан – әдәбиятка. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – Б. 68–69.

[107] *бәгъдә* – аннан соң; *сөаль* – сорау; *фөнүн* – фәннәр; *дәхи* – тагын; *зәүҗә* – хатын; *мәүҗүд* – бар.

турындагы хикәятне сөйләячәген әйтә. Шулай итеп, Ш.Рәхмәтуллин хикәят эчендә икенче бер хикәят тасвирлый башлый. Анысы «Каләф белә Чин падишаһы кызы хикәяте» дип исемләнгән[108].

Нугай ханы Тимерташның балалары арасында Каләф исемлесе күркәм әхлагы, тирән белеме белән аерылып торган, тәфсир һәм хәдис гыйлемнәрен бик яхшы белгән. Ул 18 яшенә җиткәндә олуг гыйлеме һәм гүзәл холкы белән Шәрыктә иң беренче кеше буларак танылган. Сугыш һөнәрендә һәм гаскәр белән идарә итүдә дә зур осталыкка ирешкән.

Шул заманда хәрәземлеләр (текстта «Карәзем» дип язылган) илче җибәреп, нугай татарларын үзләренә ясак түләргә кушалар. Тимерташ хан, үз кешеләре белән киңәшкәннең соңында, сугышсыз бирелмәскә дигән карарга киләләр. Ләкин аларның гаскәре хәрәземлеләрдән азрак була. Шуңа күрә ярдәм сорап күршеләре чиркәсләргә мөрәҗәгать итәләр.

Каләф һәм Хәрәзем гаскәрләре бик аяусыз сугышып, күп сугышчылар һәлак була. Каләф ягында сугышкан чиркәсләр башлыгы яшерен рәвештә Хәрәзем патшасы янына чыгып, үз кабиләсенә ясак түләтмәү турында килешә, үз сугышчыларын ияртеп, Каләфтән аерылып, кайтып китә. Канкойгыч бәрелешләр нәтиҗәсендә Каләф калган гаскәре белән чигенергә мәҗбүр була.

Хәрәзем солтаны Нугай дәүләтен бөтенләй тар-мар итәргә киләчәген белеп, Тимерташ хан хатыны Алмас һәм улы Каләф белән, бераз гаскәриләр һәм хезмәтчеләрен ияртеп, башкалалары Әстерханны (текстта: Әстеркан) калдырып, Рум иленә таба китәләр. Кавказ таулары аша чыкканда аларга юлбасарлар һөҗүм итеп, киемнәренә хәтле алалар. Тимерташ бу хурлыктан үз-үзенә кул салмакчы була. Елашалар. Каләф Аллаһы Тәгаләнең язмышына буйсынырга, сабыр итәргә һәм рәхим-шәфкатькә өметләнергә, шул хакта догада булырга өнди. Ата-анасы аның сүзләренә күнә: «Ходай Тәгаләдән бәхет, дәүләт өмид итәргә урын юк түгел. Бакалым, күрәлем...» – дип, юлга чыгалар. Ачлы-туклы, җәфалар чигеп баралар. Бик хәлсезләнгәч, уллары әле әтисен, әле әнисен алмашлап күтәреп тә бара. Ачлык-сусызлыктан җәфа чиккән ата-ана тагын өметсезлеккә төшә. Каләф янә үгетли. Ул әтиәнисен калдырып, юл эзли, таба алмагач Аллага ялвара. Шуннан соң чишмә янындагы мул җимешле агачлы урынга юлыгып, бик куана.

[108] Шиһабеддин бине Габделгазиз бине Рәхмәтулла. Каләф берлә... – Б. 5.

Әти-әнисен дә шунда алып килә. Өч көн хәл җыйгач, яңадан юлларын дәвам итәләр.

Бара торгач матур һәм зур бер кирмән-калага килеп җитәләр. Яннарына бер карт килә, сөйләшәләр. Бу – Җаек шәһәре, ә ханы Аксак хан икән. Мосафирлар картка үзләренең сәүдәгәр булуларын, юлбасарлар талавын сөйләп бирәләр. Карт боларны өенә ияртеп кайтып, һәммәсен киендерә, хөрмәтләп кунак итә. Ул кунакларның кәефен күтәрергә ничек кенә тырышса да, юлчылар бөтен маллары таланганлыкны уйлап, һаман хәсрәттә калалар. Шуннан соң картларны юатыр өчен юлбасарлар мал-мөлкәтегезне алса да, үзегезне исән калдырганнар бит дип, бер гыйбрәтле хикәят сөйләргә уйлый. Һәм үзе сабый вакытында Мусыл шәһәреннән Бәгъдадка барганда юлбасарлар малларын гына түгел, җаннарын да алырга теләгәнлекне әйтә.

Картның хикәяте бу китапта «Мусыл падишаһы Уртукның угылы Фазлулла хикәяте» дип аерым исемләнгән, ягъни хикәятне сөйләүче шул Фазлулла үзе була инде. Китапның 17–56 битләрендәге Фазлулла хикәятенең безне кызыксындырган сюжетка мөнәсәбәте юк. Ул аерым мәхәббәт тарихыннан гыйбарәт. Анда Фазлулла үзенең яшь чагындагы маҗаралы һәм фаҗигале гыйшык хәлләрен, явызлыкка, мәкергә, алдау тозакларына дучар булуын бәйнә-бәйнә сөйли.

Тимерташ хатыны һәм улы белән Фазлулла хикәятен тыңлап бетергәч, төн кунып, икенче иртәдә карт аларга тагын бер хәбәр җиткерә. Хәрәзем солтанының илчесе килеп, нугай ханы монда килсә, тотып бирергә дип кисәткән икән. «Аның хәле белән чагыштырганда, сезнең хәл кулайрак бит», – ди карт. Моны ишеткәч кунаклар тагын да хәсрәткә төшә, Алмас ханым һушын җуя. Шуннан соң карт боларның сәүдәгәр түгеллегенә төшенә. Тимерташ та аңа дөреслекне ача. Йорт хуҗасы аларга дөяләр, азык һәм акчалар биреп озата.

Болар Барлас мәмләкәтенә чыгалар. Анда тагын мохтаҗлыкка төшәләр. Каләф ата-анасын мескенханәгә тапшырып, үзе теләнчелек итәргә китә. Бераз акча табып, әти-әнисен ашата. Бу хәлдән чыгу чарасын эзләп, Каләф: «Бәне кол итеп сатыңыз», акчасы үзегезгә тамак туйдырырга озакка җитәр. Аллаһы Тәгалә бер җаен бирер, ничек тә котылырмын», – ди. Әтисе исә үзен сатарга тәкъдим итә. Каләф иртәгәсе көнне йөк ташучы булып ялланып эшләп карарга уйлый. Ләкин эш таба алмый. Хәсрәтләнеп сахрага чыгып бер агач ышыгына утыра. Анда йокыга китеп уянуына, янында алтын һәм асылташлар белән бизәлгән муенчаклы ау карчыгасын күрә. Аның зиннәтләренә

күрә, патшаныкы булуын аңлап ала. Кошны тота. Бу ханның ауга чыккач югалткан, эзләп-эзләп тә таба алмаган карчыгасы икән. Каләф кошны ханга илтеп бирә. Чиксез шатланган хан егетнең кем булуын сораша. Каләф үзенең бер Рум сәүдәгәре улы булуын, сәфәр вакытында юлбасарлардан таланып фәкыйрьләнүләрен сөйли. Хан үз кошын тапкан кешегә өч нәрсә бирергә ант иткәнлеген белдереп, ниләр теләвен сорый. Каләф ханга дога һәм мактаулар укыгач, әти-әнисенә аерым чатыр кордырып, тәрбиядә тотуны, үзенә бер яхшы ат, кием, корал һәм бер янчык алтын сорый. Хан ризалыгын белдерә. Егет шөкерләр укып, әти-әнисен куандыра. Аларга бик зиннәтле чатыр корыла, хезмәткәрләр бирелә.

Икенче көнне Каләф, хан биргән кием һәм кораллар, алтынны алып, бик яхшы атка атланып, әти-әнисенә үзенең Чин патшалыгы тарафына юнәлүен әйтеп, «бакалым, күрәлем – Хак Тәгалә нә күрсәтер» дип, сәфәргә кузгала. Аны изге теләкләр теләп озаталар.

Егет, озын юл узып, бер заман Пекин шәһәренә барып җитә. Анда бер тол карчык өенә туктала. Карчык аның кием-салымына күрә, «өендә монасыйп урын барлыгын вә баш өстенә кабул кылачагыны» әйтеп, Каләфне кертә. Егет карчыкка ризык хәзерләү өчен бер алтын акча бирә, карчык 12 яшьлек улын базарга җибәрә. Ул арада егет Пекиндагы тормышны сораша.

Боларның патшалары Алтын исемле, гаделлеге, шәфкать-мәрхәмәте белән шөһрәтле икән. Ләкин тәхеткә утыртырдай ир баласы юк икән. Бусы бер хәл, әмма тагын да зуррак кайгысы – Турандык исемле кызы икән. Карчык үз кызының шул Турандыкның кәнизәге булып, сарайда хезмәт итүен әйтә. Аннан ишетеп, күп нәрсәдән хәбәрдар икән. Шәрыкнең иң оста рәссамнары ханның 19 яшьлек бик гүзәл кызының рәсемен ясыйлар икән. Рәсемен күргән кеше гыйшык тозагына дучар булып, акылларын җуялар. Шунлыктан күбесе һәлак булган. Ул зирәк кыз бик күп гыйлемнәрне, төрле телләрне белә икән. Кыз әтисенә никахлашырга теләгән шаһзадәләрнең сарайдагы галимнәр, аксакаллар һәм вәзирләр алдында үз сорауларына җавап бирүен, дөрес җавап бирүчегә кияүгә барачагын, бирә алмаучылар үтереләчәген белдереп фәрман игълан итү шартын куя. Хан бердәнбер кызына каршы килә алмый, ризалыгын биреп ант итә. Нәтиҗәдә, шактый яшь шаһзадәләр дарга асыла.

Карчык сөйләгәннәргә Каләф бик аптырап кала. Кич тагын бер шаһзадәнең асылачагы турында хәбәр тарала. Каләф бу җәзаны кү-

рергә дип бара. Яп-яшь бер егетнең башын чабалар. Халык таралгач, Каләф мәйданда үксеп елап торган кеше янына килә. Ул исә әле генә үтерелгән Сәмәрканд патшасы улының тәрбиячесе икән. Сәмәрканд шаһзадәсе җәзага тартылачагын белгәч, үз башына җиткән кызның рәсемен тәрбиячесенә биреп, әтисенә алып кайтып күрсәтергә кушкан. Ләкин тәрбияче анда кайтмаячагын әйтеп, Турандыкны каһәрләп, рәсемен җиргә ыргытып китеп бара. Каләф рәсемне ала. Үзен никадәр генә тыярга тырышса да, ихтыярсыз калып, рәсемдәге чибәргә гашыйк була.

Егет карчыкка үзенең Чин патшасы гаскәрендә хезмәт итү нияте белән килгәнлеген әйтеп, Турандык сорауларына җавап бирергә керәчәген белдерә. Карчык елап, аны бармаска үгетли. Каләф үзенә Аллаһ ярдәм итәр дип ышануын белдерә. Һәлак булсам дип, янчыгындагы алтыннарын карчыкка бирә. Карчык ул акчаларны фәкыйрь-мескен, мохтаҗларга сәдака итеп һәм галимнәргә Каләфнең иминлеге өчен дога кылырга бирергә рөхсәт ала.

Иртән Каләф сарайга бара. Сарай капкасы янындагы сакчылар аны туктатып сорашалар, кермәскә үгетлиләр. Каләф хан янына керә. Хан да бик хафаланып, фикереннән кире чигәргә өндәп карый. Егет үзенең карары катгый булуын һәм сорауларга җавап бирсә, башкаларны золымнан коткарачагын әйтә.

Патша, вәзирләр, руханилар һәм бүтән аксөякләр җыелган диванханәдә ике алтын тәхет ясап куелган. Берсенә патша, икенчесенә алтын-ефәк бөркәнчекле Турандык килеп утыра. Алар каршындагы бер утыргычка Каләфне утырталар. Шул нәүбәттә дә егет кисәтелә, уеннан кире кайтырга тәкъдим ителә. Аңа Турандык үзе дә шундый сүзләр белән мөрәҗәгать итеп карый.

Кыз егеткә өч сорау бирә. Беренчесе: бөтен дөнья тормышына һәм аның үсүенә иң кирәкле әйбер нәрсә? Егет җавабы: Кояш! Мәҗлестәге барча халык җавапны хуплый.

Икенче сорау: Үз балаларын дөньяга тудырып, зур үскәч йота торган ана кем ул? Каләф җавабында: «Диңгез. Ул – елгаларның чыганагы һәм елгалар зураеп беткәч барысы да диңгезгә коя» – ди. Диван әһелләре тагын хуплыйлар.

Кыз бик ярсып өченче соравын бирә: «Ул нинди йыгачдыр ки, яфракларының бер тарафы ак вә бер тарафы карадыр?» Кыз соравын әйткәч тә, Каләфне саташтырып, акылын җуйдырыр өчен башындагы бөркәнчене алып йөзен ача. Аның искитәрлек гүзәллегеннән, автор

сүзләре белән әйткәндә, «болыт астыннан Кояш чыгып, һәркемнең күзе камашты». Егет тә һушы китеп, эндәшә алмыйча торганнан соң, көч-хәл белән акылын җыеп, сүзгә килә. Ул кызның нәфислегенә таң калуын әйтеп, безнең Ислам динендә хур кызларыдай гүзәллекне күрсәтү тыелган әйбер дип искәртә һәм соралган әйбернең бер бөтен ел һәм төн белән көн булуын белдерә. Диван мәҗлесендәгеләр егет җавабын хуплыйлар.

Алтын хан кызына җиңелүен һәм никах укытырга тиешлекне әйтә. Кыз һаман карулашып, иртәгә тагын сораулар бирергә телим ди. Әтисе аның хәзер үк бер сорау бирә алуын, башкачага риза түгеллеген белдерә. Тик кыз әзер булмый. Әтисе Турандыкны ачулана, үзен дә мәгънәсез анты өчен битәрли.

Каләф, тәвәккәлләп, үзе бер сорау бирергә була. Патша ул очракта беркемне дә җәзага тартмаячагын әйтә. Егет кызга, әгәр җавап бирә алмаса, миңа кәләш булыр дигән шарт куеп, михнәтләргә һәм теләнчелеккә дучар булган, ләкин шөһрәт һәм макталуга ирешкән шаһзадәнең исемен әйтүне сорый. Кыз җавапны иртәгә әйтергә була.

Хафага төшкән Турандык җарияләре белән киңәшә, җавап табу чарасын уйлашалар.

Ул арада патша Каләфне үз янына чакыртып, аны кочаклап, газапларымнан коткарасың дип, рәхмәтләр яудыра. Каләф үз соравының дөрес җавабын аңа әйтеп куя: «Ул исемен сораган шаһзадә мин үземмен. Бәнем кем икәнлегемене һәм исемемне Пекинда аслан белүче юктыр», – дип, кызның җавап бирә алмаячагын әйтә. Шуннан соң Алтын хан белән Каләф бергәләп ауга чыгалар. Аудан соң, егет хөрмәтенә мәҗлес корыла, тамашалар күрсәтелә.

Төн җитеп, Каләф йокы бүлмәсенә кергәч, анда бик чибәр һәм сылу кыз күреп гаҗәпләнә. Бу кыз аңа зур йомыш белән килүен, сакчыларга акча биреп кенә монда үтә алуын әйтә. Әлеге кыз элек Алтын хан белән сугышып җиңелгән икенче бер ханның кызы икән. Ул кичергән фаҗигаләрен, үзен Турандыкка кәнизәк итеп бирүләрен сөйли. Аннан соң кыз Турандыкның Каләфне үтертергә ниятләвен әйтеп бирә. Турандыкны нихәтле үгет-нәсихәт кылсалар да, ул залимәгә сүз үтмәвен тәфсыйлләп сөйли. Бу хәбәрдән тәэсирләнгән Каләф: «Шәфкать-мәрхәмәт әсәрләреннән мәхрүм Турандык! Ерткыч Турандык! ...Син ул бичара Тимерташ хан баласының каны белән үзеңнең пакь итәгеңне буямакчы буласың икән?! Каләфнең сиңа бер гөнаһысы булмый торып...» – дип, үзалдына сөйләнеп, сизенмәстән, янындагы кә-

низәк кызга исемен фаш итә. Кәнизәк исә аңа бергәләп качып китү өчен атлар әзерләп куйганлыгын әйтә. Каләф бу тәкъдимне кире кага. Кыз ачуланып китеп бара. Егет таңга кадәр йокламыйча, төрле уй-фикерләр эчендә чыга.

Сарайга баргач Алтын хан Турандыкка: «Җавапны барыбер белмәссең, мондый яхшы кияүгә риза бул, Чин патшасы булырга сез икәвегездән башка лаек кеше юк», – ди. Кыз: «Бу шаһзадә – Тимерташ ханның угылы Каләф исемледер!» – дип, хак җавапны әйтеп бирә. Егет моны ишетеп кайгыга төшә. Тик бераздан исен җыеп: «Бу дөрес түгел, чөнки Тимерташның улы шөһрәт һәм шатлыкта түгел», – ди. Кыз да сүзсез калмый, ул: «Бу сорауны биргәндә син җиңү тәэсире белән бик шатлыклы идең бит», – ди. Әтисенә, мәҗлестәге барча халыкка һәм үзенә аеруча ошавы сәбәпле Каләфкә хәләл җефетлеккә риза булуын белдерә. Бу сүздән соң бөтенесе шатланыша. Алтын хан кызыннан дөрес җавапны ничек белүен сорый. Турандык исә, бер җариясенең, төрле хикәятләр сөйләп, Каләфнең исемен белүгә ирешүен, моны Каләф тә гафу итәр дип, әйтеп бирә.

Шул вакыт узган төндә Каләф янына килгән җария сарайдагы бөтен халык алдына чыгып, Турандыкка карап, үзенең шаһзадә исемен белү өчен бармаганлыгын, ә әсирлектән котылуга ниятләгән булуын әйтә. Шулай ук Турандыкның дөрес җавапны әйтеп, Каләфкә никахланмыйча, үзе белән кавышачак дип өметләнгәнен һәм хәзер чарасыз калуын белдереп, киеме астыннан хәнҗәр чыгарып, үз йөрәгенә кадап идәнгә егыла. Турандык кызның үле гәүдәсе янында: «Аһ, бичара Гаделмәләгем...» – дип, сыкранып елый. Һәлак булган кызның исеме дә укучыга ачыла. Аны бик зурлап соңгы юлга озаталар.

Туйга хәзерләнеп, Барлас иленә дә илчеләр җибәреп, Пекинга туйга чакыралар.

Турандыкның күңеле йомшара. Барлас ханы Каләфнең ата-анасы белән бергә туйга киләләр. Каләф ата-анасы белән күрешкәч чиктән тыш куанышалар. Аларны бик олылап кунак итәләр. Каләф Пекинга килгәч үзе кунган өй хуҗасы – карчыкны сарайга алдырта.

Алтын хан Тимерташ ханның үчен алу өчен Хәрәземгә яу белән җибәрергә гаскәр тупларга боера. Җиде йөз мең кешелек дәһшәтле гаскәр белән Хәрәзем җиренә баралар. Гаскәр башлыклары: Тимерташ, Каләф һәм Барлас ханы Галәнкәр була. Бик көчле сугышлардан соң хәрәземлеләрне җиңәләр. Тимерташ Хәрәзем иленә солтан булып тәхеткә утыра. Аннан бераз гаскәре белән үз патшалыгы булган нугай

татарлары җиренә бара. Алар да шушы дәүләткә кушыла. Элек хыянәт иткән чиркәсләр иленә Тимерташның яуга җыенуын белеп, чиркәс халкы үзләре сугышка керешә. Алар да тар-мар ителеп, җирләре Тимерташка кушыла. Каләф Хәрәземдә патшалык итә. Алтын хан Каләф белән Турандыкның ир баласын үзенә варис итеп калдыра, икенче уллары соңыннан Хәрәзем солтанлыгына утыра. Ә Тимерташ элек үзенең патшалыгы булган «Нугай Татарстанында» солтан була, Әстерханда яши.

Дайәнең Фәрхәназга сөйләгән бу хикәятен тыңлаган һәммәсе эчтәлегенең гыйбрәт алырлык булуын тәкъдир итәләр[109].

Бу китапта автор рус һәм Европа телләреннән кергән сүзләрне дә шактый кулланган. Мәсәлән, *план, фамилия, пудаукә, граница, команда, конвой, стерлядь, икра, флаг* һәм башка шундыйлар, хәтта «по добру, по здорову» дигән гыйбарәләр дә бар[110].

Галим Мәсгуть Гайнетдинов Шиһабетдин Рәхмәтуллинның бу кыйссасын «бүген дә кызыксынып укырлык дәрәҗәдә зәвекъле» дип бәяләгән иде[111].

Бу сюжетның тарихын җентекләп өйрәнгән галим Нәҗип Исмәгыйль әлеге китап турында болай дип язды: «Ш.Рәхмәтуллин бу китабында көнчыгыш әдәбиятында һәм фольклорында бик популяр булган сюжетларны бик оста берләштереп, халык сөйләменә якын әдәби телдә, татарча яңгырашлы кызыклы әсәр тудырган». Ул бу китап эчтәлеген «Мәҗмугыл хикәят»тәге сюжетка бик якын булуын да әйтеп, «чагыштырып караганда сюжетларның икесенең дә бер фарсы чыганагына барып тоташканлыгы аңлашыла» ди[112].

## «Хикәяи Маһифәйрүзә...» китабы

Казанда 1904 елда басылып чыккан «Хикәяи Маһифәйрүзә солтан илә Разниһан» исемле, авторы билгесез әдәби китапның эчтәлеге дә шул ук сюжетка якын. Бу китапның күләме 26 битне тәшкил итә. Аның титул битендә эчтәлек аннотациясе рәвешендәге мондый сүзләр язылган: «Бик хуш вә мәргуб, кызык вә гыйбрәтле, ике гашыйкның халене бәйан кыйлган бер гүзәл хикәядер. Үземезнең татар телендә мон-

---

[109] Шиһабеддин бине Габделгазиз бине Рәхмәтулла. Каләф берлә... – 120 б.
[110] Шунда ук. – Б. 24, 30, 39, 43, 88, 98, 113 һ.б.
[111] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т.2: XIX йөз татар әдәбияты... – Б. 257.
[112] Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет... – Б. 181–182.

дан әүвәл басылдыгы улмайуб, әүвәл мәртәбә басылуыдыр»[113]. Менә мондагы «үземезнең татар телендә...» дигән сүзләр бу хикәянең татарчага тәрҗемә ителгәнлегенә ишарә итә. Әсәрнең тексты белән танышкач та, аның тәрҗемә икәнлеге шәйләнә. Әмма китапның тәрҗемәчесе кем булганлыгы күрсәтелмәгән.

Хикәянең эчтәлегенә күзәтү ясап үтик. Хорасан иленең Кандахур шәһәрендә Дәүләтшәүкәтнөма исемле гадел падишаһ була. Ул ир баласы булмаганга бик кайгыра. Аллаһтан ялвара. Аның Хәким улы Ягъкуб исемле акыллы вәзире була. Вәзирнең дә балалары юк икән. Патша аңа: «Үземнән соң тәхетемә утыртыр кешем дә юк, безгә синең белән кая да булса китәргә кирәк», – ди. Болар кыяфәтләрен үзгәртеп чыгып, мәмләкәтләр гизәләр, күп гаҗәп хәлләр күрәләр. Бер көнне бер дәрвишне очраталар. Сәламләшкәч, дәрвишнең үзенә «падишаһым» дип эндәшүенә хаким гаҗәпләнә һәм бу зиһенле, тирәнтен белемле дәрвишне үз сараена алып кайта. Аның «Ир балаң тусын дисәң, – бер мәчет һәм чишмә төзет!» дигән тәкъдимен үти. Патшаның улы дөньяга килә. Дәрвиш аңа Разниһан дигән исем куша.

Бала 5–6 яшьләренә җиткәч аңа хәлфә сабак укыта башлый. Жомга кичләренең берсендә «Фатыйха» һәм «Йасин» сүрәләрен укып йокларга яткач, төшендә ак сакаллы бер карт аңа эндәшә: «Угылым! Бу дөньяда сиңа насыйп бер кыз бар», – ди. Шаһзадә икенче көнне дә шул картны һәм аның янында искиткеч гүзәл кызны төшендә күрә. Ул кызның исеме – Маһифәйрүзә булып, һинд патшасының кызы икән. Төштәге карт аларның икесенә дә мәхәббәт касәсеннән гыйшык ширбәте эчерә. Ходайның хикмәте белән ул кызның төшендә дә шаһзадәне күрсәткәннәр икән. Егет кызга чиксез гашыйк булып саргая, елый. Мондый халәтенә пошынган әти-әнисенә дә серен ачмый, «эчем поша» дип кенә җавап бирә. Әтисе аңа «сахраларда гиз, күңелең-күзең ачылсын» дип киңәш итә.

Егет кыяфәтен үзгәртеп йөрергә чыккач бер каһвәханә янында шагыйрьләр һәм уенчыларның бәетләр әйтешүен ошатып, аларны сарайга алып кайталар. Тамаша кылганнан соң, шаһзадәнең гыйшык уты куәтләнеп, үзе дә бәетләр – мәхәббәт шигырьләре әйтә башлый. (Китапта аның исеменнән әйтелгән беренче бәеттә «Мәхәббәт шәмгынә янар пәрванә» дигән сүзләр дә бар). Шаһзадәнең шигырьләр әйтә башлавыннан сарайдагылар гаҗәпкә калалар. Аңа әнисе: «Шаһзадә өчен

[113] *мәргуб* – яхшы, сөекле; *басылдыгы улмайуб* – басылганы булмыйча.

мондый эшләр килешмәс», – дип, үгет-нәсихәт кыла. Егет кулына кыллы уен коралы[114] сорап алып, үзенең гашыйклык хәлен әнисенә җыр-бәет белән аңлатып бирә. Хәлне әтисенә дә белдерәләр. Патша улына: «Бар, үзеңне тәрбия кылган әбиең илә бераз сахраларда күңелең ач!» – дип киңәш итә. Шаһзадә бакчага чыккач, андагы кызларны күреп, сөеклесен тагын да сагынып, бер агач кисәген үз мәгъшукасы дип күзаллап кулына ала һәм бәетләр әйтә...[115]

Патша үз сараенда диван – киңәш мәҗлесе кора, аңа бер вәзире кызын никахландырсын дип һинд патшасына хәбәр җибәрергә тәкъдим кертә. Егетнең саз белән уйнап әйткән җырларын тыңлагач, хат җибәрергә булалар.

Икенче тарафта һинд патшасының кызы да гыйшык утында янып көя. Аның хәлен күреп, әтисе саз ясатып бирә. Кыз да күңеленең сагышын бәетләр белән яңгырата: «Миңа гашыйклар булса – килсеннәр, дәгъва кылсыннар», – ди. Ул арада кызны Разниһанга бирүне сорап язган хат килеп ирешә. Һинд патшасы аңа җавап итеп, үзенең кызы бирәү генә булганга, җибәрә алмавын белдерә, шул сәбәпле, «Шаһзадәнең үзен монда җибәрегез», – дигән хат юллый.

Хорасан патшасы хатны укыгач кызып: «Болай бирмәсә, сугышып алырмын», – дип гайрәтләнә. Улы аңа күп кеше һәлак булачагын әйтеп тынычландыра һәм үзе кызга хат җибәрә. Аның хатын илтүче Һиндстанга барып бер карчыкка йомышын йөкли, хатны ничек тә кызга биреп, җавабын аласы иде дип, өч-дүрт алтын акча бирә. Ул карчык: «Баш өстенә, угылым. Син минем кунагымсын», – дип ризалаша. Шаһзадә хәбәрен алган кыз бик шатлана һәм үзе дә шигъри хат язып җибәрә. Хат егеткә ирешә, аннан соң да күп хатлар алышалар.

Шаһзадә кыз янына барырга әти-әнисеннән күпме генә үтенсә дә, аны җибәрмиләр. Бер төндә патшаның төшенә ак сакаллы бер карт кереп: «Улыңны болай елатма, җибәр!» – ди. Ниһаять, әти-әнисе улларын җибәрергә ризалаша. Шаһзадәне елашып озатып калалар. Ул юлында очраган шәһәрләрдә дә бәетләр көйләп, үз хәлен бәйан итеп

---

[114] Текстта уен коралы «уен» дип кенә язылып, китап битенең читенә «уен – эскрипкә» дигән аңлатма бирелгән. Ләкин хикәянең моннан соңгы дәвамында уен коралы «саз» буларак язылган.

[115] Кызны күрергә зарыккан шаһзадәнең «бер агач кисәген кулына алып...» юаныч табарга теләве Түләк дастаны текстындагы Түләкнең үртәкә ясавын хәтерләтә (Түләк китабы: дастан / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. – Б. 29. – «Татар археографиясе» сериясе; 2 нче китап).

бара. Бәгъдад шәһәрендәге гашыйклар (суфыйлар) арасында Гашыйк Мәсгудь дигән кеше аның белән бәет әйтешеп, үзара «имтихан кылышалар», ягъни ярышалар. Егет җавапларын бирә, тик Мәсгудь шаһзадә сорауларына җавап бирә алмый. Шаһзадәнең гыйлеме-зиһененә таң калалар.

Сәфәрчеләр юлларын дәвам итә, «күп мәмләкәтләрне үтеп, бәет вә сазларыны уйнап, елгалардан су кеби, түбәләрдән җил кеби, тигезлектән туп кеби китеп, бер көн Һиндстанга» барып җитәләр. Кыз белән хат аша хәбәрләшәләр. Кыз: «Атамны мактап бәет язып җибәрсәң – кабул итәр», – дип егеткә хәбәр белдертә. Егет һинд патшасына мәдхия яза һәм аны укып тапшыра. Бик канәгать калган патша аннан: «Саз уйный беләсеңме?» – дип сорый. Егет сазның кылларын көйләгән арада «Маһифәйрүзә ханым рәшәткә артына килеп тыңлый башлады». Патша егетнең уенынан һәм бәетләреннән бик канәгать кала. Кызы әтисеннән «без дә – хатыннар да тыңласак иде» дип үтенгәч, патша ризалык бирә. Шуннан соң «Маһифәйрүзә чаршау артына кереп утырды», шаһзадә сазны алып бәетләрен көйли. Ул үзен монда мәхәббәте китергәнлеген әйтеп бирә. Маһифәйрүзә тәэсирләнеп, сабыры калмыйча шаһзадә янына килеп, һушсыз булып егыла. Аның гүзәллеген күргән егет тә һушын җуя.

Патшага хәлне хәбәр итәләр. Патша бу егетнең Хорасан шаһзадәсе икәнлеген белгәч ачуланып, башын кисәргә әмер бирә. Тик кызы ялваргач, аны исән калдыралар. Кыз әтисенә төшләрендә гыйшык ширбәте эчереп, бер-берсенә гашыйк итүләрен әйтә. Патша ачулана һәм егетне богаулатып җиде елга зинданга яптыра.

Хәсрәттән саргайган патша кызы бер төннең уртасында ирләр кыяфәтенә кереп, зинданга бара һәм зинданчыга бер уч алтын биреп, «капу»ны ачтырып эчкә үтә[116]. Шаһзадә елап, кулына сазын алып, бәет әйтә. Кыз аңа: «Моннан чыксак, инша Аллаһ, икемез бергә качып китәрмез. Чөнки мин аңладым – атам мине сиңа бирергә нияте юк», – ди. Кинәт каршыларында бер дәрвиш пәйда була. Дәрвиш боларга: «Егъламагыз! Аллаһы Тәгалә морадыңызны бирде», – дип, могҗиза белән зинданнан чыгарып, күзләрен йомдырып Хорасанга китерә. Ул

[116] Кызның зинданчыга ришвәт биреп зинданга керүе Мәүла Колый әсәрендәге шундый ук вакыйгага охшаш (Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты»; «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Мәрданов Р.Ф. – Икенче басма. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2011. – Б. 30–31, 47. – «Татар археографиясе» сериясе; 1 нче китап).

дәрвиш – Хозыр галәйһиссәлам булган икән. Егет белән кыз никахлашалар, кырык көн, кырык төн туй ясап бәйрәм итәләр. Бәхетле парлар калган гомерләрен рәхәтлектә үткәрәләр[117].

Бу хикәя текстында чәчмә һәм шигъри юлларның аралаш бирелүе, сазда уйнап кара-каршы бәет-җырлар әйтешү борынгы Шәрык әдәби әсәрләренә охшаш һәм дастан текстларын да хәтерләтә. Ләкин бәет-шигырьләрнең бик үк камил түгеллеге, күрәсең, тәрҗемәче татар әдибенең төп мәгънәне сакларга теләвеннән килеп чыккандыр дип фаразларга мөмкин.

Хикәянең сюжеты моңа охшаш башка әсәрләрнекеннән аермалы булса да, аларның бер үк чыганакка тоташканлыгы тоемлана. Һәрхәлдә, патшаның тәхеткә утыртырга варисы юклыгы, кыз белән егет – икесе дә патша балалары булганлыгы, аларның бик белемле һәм гаять чибәрлеге, кызның «гашыйклар булса – килсеннәр, дәгъва кылсыннар» дип әйтүе бу хикәятнең бүтән текстлар белән якынлыгын раслый. Шулай ук Һиндстанга барып бер карчыкка йомыш йөкләү, карчыкның «баш өстенә угылым...» дигән сүзләр әйтеп ризалашуы; шаһзадәнең ерак юллар үтеп баруы; кызның «чаршау» артына кереп утыруы; чиксез гүзәллек тәэсирендә һуш җуюлар: зинданга ябу; төн уртасында кызның егет янына баруы һәм зинданчыга ришвәт биреп эчкә үтүе; кызның бергәләшеп качарга тәкъдим итүе; хикәянең ахыры никах һәм зур туй белән тәмамлану – менә болар барысы да «Кыз хикәяте» белән бер үк сюжетка язылган әсәрләрдә төрлечә микъдарда кабатланалар. Бу хикәяттәге «шәмгъ–пәрванә» турындагы шигъри юллар «Мәликә китабы»ның Казан һәм Ташкент басмаларында очравы, эч пошудан юаныч табар өчен сахралар гизәргә тәкъдим итүнең Фатыйх Халидинең «Кемгә тиеш?» китабында язылганга аваздашлыгы кебек мисаллар да фикеребезне куәтли.

## Татар халык әкиятләре

Халкыбыз арасында шул ук сюжетка нигезләнгән әкият вариантлары таралган. Әдип һәм драматург Рабит Батулла татар фольклоры белгече, галим һәм драматург Нәкый Исәнбәтнең сүзләрен китереп, элек

[117] Хикәяи Маһифәйрүзә солтан илә Разниһан. – Казан: матбагаи Кәримия, 1904. – 26 б.

халкыбыз арасында «Патша кызы Турандык» исемле әкият булганлыгын яза[118].

Шушы сюжеттагы, татар халык иҗаты әсәре буларак тасвирланган тагын бер әсәр Михаил Васильевның 1924 елда дөнья күргән җыентыгына кертелгән[119]. «Турандук» дип исемләнгән бу текст 1916 елда Лаеш өязе (хәзерге Татарстанның Питрәч районындагы) Шәле авылында язып алынган булган. Аның эчтәлеге Ш.Рәхмәтуллинның алда тасвирланган китабына бик охшаш булып, шул китапның кыскача сөземтәсе рәвешендә дияргә мөмкин. Вакыйгалар һәм сюжет бер үк. Турандукның Кулафка (бу китапта егет исеме шулай язылган) биргән өч соравы һәм җаваплары да (диңгез, Кояш һәм ел) Рәхмәтуллин текстындагыча.

Тик, шулар белән бергә, исем-атамаларда һәм кайбер күренешләрдә аермалар бар. Мәсәлән, Кулафның әтисе Алтай исемле һәм аларның төп ватаннары – Асхабад шәһәре дип язылган. Ш.Рәхмәтуллин китабында Каләфләрнең дәүләтен тар-мар итүче Хәрәзем ханы булса, Васильев китабындагы текстта бу явызлыкны кылучы Астрабад дәүләтенең патшасы Уран-хан дип тасвирланган. Шуның өстенә, ул Алтай патша белән аның улы Кулафны әсир итеп алган. Әсирлектә әтисе үлгәч Кулаф аның өчен Уран-ханнан үч алырга ант иткән. Кулаф туган иленә кайтып, Уран-ханга каршы сугышырга ярдәмчеләр эзләп өч ай йөргәч, Шираз дигән шәһәргә барып җитә. Анда бер карчыкта яши башлый. Шираз патшасы Алтун-ханның 18 яшьлек Турандук исемле кызына бәйле төп вакыйгалар шунда бара.

Бу текстта егетнең кызны беренче күрүе дә бүтәнчәрәк. Ягъни, Турандук үзенең хезмәтче кызлары белән шәһәр читендәге бакчага чыгып барган чакта Кулаф, хәерче булып киенеп, бакча капкасы янында торганда кызны күреп, аның гүзәллегенә таң калган.

Васильев китабында басылып чыккан «Турандук» тексты татар халык иҗаты күптомлыгының «Риваятьләр һәм легендалар» җыентыгында татарчага тәрҗемә итеп басылып чыкты. Бу китапта әлеге әсәр

---

[118] Батулла Р. Ике әсәрнең кечкенә тарихы // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары / төз. һәм фәнни мөх. Р.Исламов. – Казан, 2007. – Б. 206.

[119] Васильев М.А. Памятники татарской народной словесности: Сказки и легенды. – Казань, 1924. – Б. 158–162.

«Кылаф белән Турандык» исеме астында, риваять буларак тәкъдим ителгән[120].

***

Фатыйх Халиди Туктамыш хан кызы Хәлимәгә багышланган әсәрен үзенең иске китаплардан җыеп язганлыгы турындагы сүзләрне исәпкә алганда, бу сюжет әкиятләр рәвешендә татарлар арасында элек тә таралган булуы аңлашыла. Фаразлавыбызча Ф.Халидинең бу темага язылган ике хикәяте басылып чыккач, шуларның йогынтысы белән, әкиятләр тагын да ишәйгәндер. Аларның берсе «Кем җиңүче?» исеме белән әкиятләр җыентыгына да урнаштырылган[121]. Әлеге әкиятнең уннан артык тексты һәм вариантының чыганаклары Татарстанның төрле районнарында, шулай ук Башкортстанда һәм Новосибирск өлкәсендә дә язып алынган булган[122].

Апас районының Танай-Турай авылында 1940 елда Г.Толымбай тарафыннан язып алынган бу әкият тексты, Ф.Халиди әсәре белән чагыштырганда, шактый гади һәм кыскача рәвештә. Анда бер кешенең өч улын өйләндерергә теләве турында сөйләнә. Угыллар өчесе дә бер үк кыз – Закир абзый кызына өйләнергә теләүләрен әйтәләр. Өч бертуган көзге, палас һәм алма алып кайтканда «өчесе дә бер станциягә туры килгәннәр. Вокзалда очрашканнар». Көзгедән карап Закир кызының үләргә ятуын күреп, палас белән тиз генә кайтып, алма ашатып кызны терелткәннәр. Әкият, Ф.Халиди китабындагыча, «Йә, хәзер кыз кемгә була инде?» дигән сорау белән тәмамланган. Ләкин бу табышмак кияүгә чыгасы кызның соравы буларак хикәяләнмәгән.

***

Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык табышмаклары» китабында «табышмак-әкиятләр» бүлегендә урнаштырылган ике әкият Ф.Халиди әсәрләре сюжетына якын эчтәлектә. «Сәрвиназ» исемле әкияткә карата Н.Исәнбәт мондый искәрмә биргән: «Фатих Халидинең «Кемгә тиеш» һәм «Болгарның Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе» дигән ике аерым китабы һәм элекке календарьлардан, шулай ук Малаязның Габдерахман абзый Ганиевтән ишетеп үзем язып алганнардан берләш-

---

[120] Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1987. – Б. 227–230.
[121] Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Өченче китап. – Казан: Татар. китап нәшр., 1981. – Б. 37–38.
[122] Шунда ук. – Б. 309.

тереп, яңадан төзеп язылды»[123]. Малаяз дип, Н.Исәнбәт үзенең Башкортстандагы туган авылында 1911 елда язып алганын белдерә[124].

«Сәрвиназ» әкиятендә вакыйгалар Болгар шәһәрендәге Таймас исемле ханның кызы Сәрвиназ белән бәйләп хикәяләнә. Аңа яучылар килә. Әстерхан ягындагы Әтил каласыннан Хәзәр ханының улы Каранугай-би килеп төшә. Сәрвиназ егеткә, Ф.Халиди әсәрендәгечә үк, «Ике бүре бер куйны...» дигән табышмагын биргән. Егет ике көн узгач дөрес җавапны әйтеп, туй ясап, кызны үзенә алган. Әкият ахырында шигъри табышмакның җавабы да язылган[125].

Шул ук китапта Нәкый Исәнбәт үзенең Малаяз дәфтәренә теркәлгән «Айсылу» исемле табышмак әкият текстын да бастырган. Анысы Ф.Халидинең Туктамыш хан кызы Хәлимә хикәятендәге икенче табышмак сюжетына охшаш. Тик вакыйга Казан шәһәрендәге Алтынбәк исемле ханның өч улы дип тасвирлана. Аның өч улы да Казандагы Хәсән-бәк морзаның Айсылу исемле кызын алырга теләүләрен белдерүләре, берәр мең сум алып, иң гаҗәп әйбер эзләргә китүләре хикәяләнә. Өч бертуган өч юл чатында аерылышып, өч ай узгач күрешәләр. Кече энеләре Алма-Ата базарында алма, уртанчы туганнары Ашхабадта мамык келәм, олы агалары Кызлар шәһәрендә хикмәтле көзге алган. Калган вакыйгалар Ф.Халидидәге кебек: көзгедән карап кызның үлүен күрү, тиз генә очып кайту, алманы кисеп Айсылу ирененә тигерү һәм кызның терелүе. Хан да, вәзирләр дә, угыллары да кызның кемгә булырга тиешлеген хәл итә алмыйча аптырашып беткәннәр. Әкиятнең ахыры «Йә, әйтегез: кыз кайсына тиеш, сезнеңчә? Кайсына биргәннәр?» дип тәмамлана[126].

## Гоццидан Тинчурин тәрҗемәсе

Татар драматургы Кәрим Тинчурин Гоцци пьесасын 1917 елда ирекле рәвештә тәрҗемә иткән һәм «Хан кызы Турандык» дип атаган. Бу әсәр беренче мәртәбә «Сәйяр» татар театр труппасы тарафыннан 1918 елның гыйнварында Казан шәһәренең Зур театрында сәхнәгә ку-

[123] Татар халык табышмаклары... – Б. 444.
[124] Шунда ук. – Б. 96.
[125] Шунда ук. – Б. 439–444.
[126] Шунда ук. – Б. 444–448.

елган[127]. Бу тамашада «Кәлаф» ролен уйнаган Кәрим Тинчуринның фоторәсеме китапларда басылып чыкты[128]. Татар театры тарихын өйрәнгән белгечләр Тинчурин трагикомедиясен «Сәйяр»нең 1918 елда яңа иҗади уңышлар яулавына китергән әсәрләрнең берсе булган дип бәяләделәр[129].

Кәрим Тинчурин сәхнәләштергән бу әсәр 1920 нче еллар дәвамында төрле театрларда уңышлы барган. Мәсәлән, 1924 елның 4 гыйнварында Казанда уйналган вакытта театрда халык шыгрым тулы булган[130]. Шулай ук аның 1927 елда уйналганлыгы турында да мәгълүмат бар[131]. Шул елдагы тамашада Турандык ролен башкарган артистка Фатыйма Ильскаяның фоторәсеме театр тарихына багышланган фотоальбомда басылган иде[132]. Әлеге трагикомедиянең 1929 ел башында Әстерхан дәүләт татар театрында уйналганлыгы да билгеле[133]. Театр сәнгате тарихы белгечләре «Хан кызы»н Кәрим Тинчуринның режиссёрлык хезмәтендәге зур иҗади уңышларыннан дип билгеләделәр[134].

Заманының бик усал һәм әче телле сатирик совет журналлары, искелекне пропагандалауның бер үрнәге буларак бәяләп, ара-тирә «Хан кызы»н чеметкәләгән. Мәсәлән, «Чаян» журналының 1923 елгы өченче (март) санында, 11 нче битендә зур рәсем бирелгән. Рәсем янына «Татар сәхнәсе. Казан шәкерте Колаф белән мирза кызы Турандук» дигән сүзләр язылган. Рәсемдә «Хан кызы Турандык» әсәренә пародия сурәтләнгән. Бөтенләй диярлек буш залда йокыга талган берничә та-

---

[127] Бу трагикомедиянең беренче мәртәбә сәхнәләштерелүе турында матбугатта чыккан кайбер мәгълүматлар дөрес түгел. Мәсәлән, 1923 елның 21 декабрендә дигән (Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары / төз. һәм фәнни мөх. Р.Исламов. – Казан, 2007. – Б. 205) һәм 1927 елда диелгән (Исмәгыйлев Н. Гасырларны кичкән сюжет... – Б. 182) даталар шундыйлардан.

[128] Г.Камал исемендәге Ленин орденлы татар Дәүләт академия театры: 50 ел. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – Б. 47; Мәхмүтов Һ., Илялова И. Гыйззәт Б. Октябрьгә кадәрге татар театры: очерклар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1988. – (Фотолар кушымтасы); Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. И.Һадиев, Р.Батулла. – Казан: Җыен, 2011. – (Фотолар кушымтасы).

[129] Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 208.

[130] «Кәләй». Хан кызы // Татарстан. – 1924. – 9 гыйнвар.

[131] Парсин М. «Хан кызы Турандот» // Кызыл Татарстан. – 1927. – 8 декабрь.

[132] Г.Камал исемендәге театр. Фотоальбом. Татар һәм рус телләрендә / төз. Х.Л.Кумысников. – Казан: Татар. китап нәшр., 1957. – Бит саны күрсәтелмәгән.

[133] Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль... – Б. 625.

[134] Татар совет театры: очерклар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1975. – Б. 112, 432.

машачы бар. Бары тик берсе генә – иң алда утырган ир-ат кына сәхнәне тамаша кыла. Ул кеше артист Мохтар Мутинга (1885–1941) охшатып ясалган. Романтик рольләрне оста башкаручы буларак дан казанган М.Мутин 1922–1937 елларда Татар Академия театры актёры булган.

Бу рәсемнең астында кыз белән егетнең мондый сүзләре язылган. «Турандук: Минем бөтен җир, күкләрне, гарше көрсиләрне хәйран калдырган илаһи җәмалем үзенә тиңдәш тапканы юк әле!

Колаф: Йә Турандук, йә әҗәл!..»

Егетнең бу сүзләре К.Тинчурин тәрҗемә иткән әсәрдә еш кабатланган[135].

«Чаян» журналының бу санында әлеге рәсемгә һәм К.Тинчурин сәхнәләштергән әсәргә кагылышлы мәкалә-язмалар юк. Тик, шулай да, яңача совет җәмгыяте төзибез дип хыялланган ул елларда әлеге рәсемнең татар сәхнәсендә элекке, хан заманнары турындагы мондый романтик рухтагы әсәрләрдән көлү буларак урын алганлыгы аңлашыла.

1930 нчы елларда бу спектакльнең куелганлыгы билгеле түгел. Аннан соң, 1937 елда К.Тинчурин, «халык дошманы» буларак кулга алынып, хөкем ителгән һәм 1955 елга кадәр исеме белән бергә әсәрләре дә тыелган. 1955 елның октябрендә К.Тинчурин акланганнан соң да, ул Гоццидан тәрҗемә иткән «Хан кызы Турандот»ны татар тамашачысы озак еллар күрмичә торды. Бары тик 1980 нче елда Татар дәүләт курчак театрында «Хан кызы»ның премьерасы куелган. Бу турыда Рабит Батулла да искәртә[136].

Тинчурин тәрҗемәсендәге «Хан кызы Турандык» трагикомик әкиятенең тексты элек матбугатта басылып чыкмаган. Ә автор кульязмасы әле 1988 елда да белгечләргә мәгълүм булмаган[137]. Әсәрнең Р.Батулла тарафыннан матбугатка әзерләнгән тексты соңгы елларда гына басылып чыкты[138].

Бу текст белән кыскача танышып үтик. Алты пәрдәлек «Хан кызы Турандык» трагикомик әкиятендә катнашучылар: Алтын хан – Кытай

---

[135] Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль... – Б. 115–117, 120, 134, 135.

[136] Батулла Р. Ике әсәрнең кечкенә тарихы // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате... – Б. 205; Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль... – Б. 423.

[137] Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 354.

[138] Карло Һотси. Хан кызы Турандык / Кәрим Тинчуринның авторлаштырылган тәрҗ. // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате... – Б. 207–237; Карло Гоцци. Хан кызы Турандык // Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль... – Б. 106–139.

ханы; Турандык – Алтын хан кызы; Гаделмәләк – татар шаһзадәсе; Турандыкның яраткан җариясе; Халәф – нугай татарларының шаһзадәсе, Тимернең улы; Бәрәк – Хәсән кушаматы белән качып йөрүче, Халәфнең элеккеге тәрбиячесе; Сәлимә – Турандыкның икенче җариясе; Гөлкәй – Сәлимәнең әнисе, Бәрәкнең хатыны; Исмәгыйль – Сәмәрканд шаһзадәсенең элеккеге тәрбиячесе; Акбулат – Алтын ханның секретаре; Накамура – Алтын ханның канцлеры; Бәрәкалла – пажлар башлыгы; Туруфутдин – Турандык евнухларының башлыгы; Беренче кара кол; Икенче кара кол; Җаллад.

Вакыйга Пекин шәһәрендә һәм аның бистәсендә бара. Гаделмәләк, Халәф татарча киенгән, калганнар Кытай киемнәре кигән.

Беренче пәрдәнең беренче күренеше «Пекин шәһәренең чите. Арттагы планда шәһәр капкалары. Капка һәм шәһәр коймасы өстендә озын казыкларга адәм башлары кадалган» дип бирелгән. Текст Халәф белән Бәрәкнең очрашуын тасвирлау белән башлана. Әстерхан янында Хәрәзем солтанына каршы каты сугышлардан соң Халәф илен, патшалыгын югалтып качып китәргә мәҗбүр булган. Алар төрле илләр гизеп, Пекинга килеп чыкканнар. Халәф үзенең Бәрләс ханының ауга чыккач югалткан ау карчыгасын тотып бирүе, хан белән әңгәмәсе һәм әти-әнисен хан тәрбиягә алуы, үзенә корал, ат һәм киемнәр, алтын бирүләре турында сөйли. Үзе монда Кытай ханының хезмәтенә керү нияте белән килгән икән.

Бәрәк Халәфкә мондагы ханның искиткеч гүзәл, ләкин явыз кызы Турандыкка бәйле хәлләрне сөйләп бирә. Хан сараенда, хан һәм зур түрәләр алдында кияү буласы кеше Турандыкның өч табышмагына җавап табарга тиеш, таба алмаса – үтереләчәге турында бәян итә, капкадагы баш сөякләренә күрсәтә. Һәркем ул кызның кәгазьдәге сурәтен генә күрсә дә, шундук гашыйк була ди.

Ул арада үтерелгән бер шаһзадәнең тәрбиячесе Исмәгыйль шул кызның рәсемен тотып елый-елый килә. Халәф рәсемне күргәч әсәрләнеп кала, гыйшкыннан шашып, кыз янына барачагын әйтә. Бәрәк белән хатыны аны бармаска үгетлиләр.

Әсәрнең икенче пәрдәсе хан сараенда бара. Анда мәҗлескә хәзерләнәләр. Музыка уйный. Хан керә, ул таш бәгырьле кызының кыйланышыннан зарлана. Ханның ярдәмчесе яңа килгән егетнең бик матур һәм искиткеч акыллы, патшаларча затлы булуын әйтә, һәлак булачагын бик кызгана. Хан Халәфкә «ярты дәүләтемне ал, зинһар нахакка

кан түгүдән коткар!» дип, ниятеннән ваз кичәргә үгетләп карый. Тик файдасыз.

Кызны чакыралар. Ул йөзен япма белән каплаган. Килеп тәхеткә утыра. Карт хан кызына да үгет сүзләре әйтә. Турандык та егетне күреп тәэсирләнә. Ул Халәфкә уеннан кире кайтырга куша.

Турандыкның беренче табышмагы алда тасвирланган әсәрләр сюжетындагыча, агач һәм аның яфраклары турында була. Икенче соравы: «Дөньядагы бер асылташ... бөтен җиһан хикмәтләрен кочаклый... Зурлыгы зур энҗедәй аның. Сыйдырадыр бөтен җиһанын дөньяның...» Халәф моны «күз» дип җавап бирә.

Өченче табышмакны әйткәнче кыз Халәфне «Әле соң түгел, качып котыл!» – дип, тагын кисәтә. Турандык өченче табышмагын (Дөньяда бардыр гаҗәп бер нәрсә... Җәй көннәрендә җиргә бер башын ора һәм җиһанның бәрәкәтен арттыра. Аңар хезмәт күрсәткән илләр рәхәттә яшиләр күп еллар) әйтеп, йөзен ачып җибәрә. Халәф бу кадәрле гүзәллекне күреп, сүзсез калып торганнан соң, көч-хәл белән җавабын бирә: «Сез әйткән гаҗәп нәрсә – сабан булырга кирәк. Сабан җир казып бөтен дөньяны туйдыра, шулай ук бөтен җиһанга рәхәт тудыра». Җыелган кешеләр барчасы дөрес җавапны хуплый. Кыз һушын җуеп тәхеткә егыла. Хан егетне кочаклап, аны үз кияве итеп势 тануын әйтә. Турандык һушына килгәч, риза булмавын, тагын да табышмаклар әйтергә теләвен белдерә. Атасы һәммәсен гыйбадәтханәгә никах укырга дип чакыра. Кыз каршы булуын, хәнҗәр белән үзен үтерәчәген әйтеп куркыта.

Шул чагында Халәф бу фаҗигадән котылу өчен үзе бер табышмак бирәм ди. Ул үзенең башыннан кичкәннәрне табышмак итеп кызга әйтә һәм шул хәлләргә дучар булган шаһзадәнең исемен әйтергә куша. Кыз җавап бирергә ризалаша.

Өченче һәм дүртенче пәрдәләрдә Турандык ни кылырга белмичә баш вата, җарияләре белән киңәшә. Егетнең кем булуын, чын исемен беләселәре килә. Турандык үз әтисе белән дә бу турыда әңгәмә кора.

Әсәрнең бишенче пәрдәсендәге күренешләр Халәф бүлмәсендә бара. Бәрәкнең хатыны Гөлкәй егет янына килеп явыз кызның төрле ысуллар белән Халәфнең исемен белергә теләвен, әтисенең дә бу хәлләрне ишетеп хан сараена килүен хәбәр итә. Халәфнең әтисе улының исән икәнлегенә инану өчен исемен яздырып алырга соравын әйтә. Халәф бу хәйләгә төшенә. Аннан соң Турандыкның җариясе Сәлимә дә егет янына кереп, аның чын исемен, нәсел-нәсәбен белергә

омтыла. Аннары электән Халәфкә гашыйк булган Гаделмәләк килеп сөйләндереп, хәйләләп егетнең һәм әтисенең исемнәрен белүгә ирешә.

Алтынчы пәрдәдә хан сараенда Турандык егеткә исеме белән эндәшә. Халәф үз-үзен хәнҗәр белән кадап үтермәкче була. Кыз аны туктатып кала һәм үзенең хисләрен тыя алмыйча, «Турандык – синең хатының!» – дип, Халәф кочагына ташлана. Егет чарасыз калган Гаделмәләкне азат итәргә сорый. Хан ризалыгын белдерә һәм Халәфкә туган илен тартып алган явыз Хәрәзем ханының бәреп төшерелү хәбәрен җиткерә.

Әсәрнең ахырында Турандык үзе кылган мәрхәмәтсезлекләр өчен гафу итүләрен сорый. Бу әсәр шулай тәмамлана[139].

***

Соңгы вакытта «Турандот» әсәрен, татар һәм Кытай сәхнә осталары бергәләп, яңартылган рәвештә сәхнәгә чыгарырга әзерләделәр. Бу турыда алдан ук хәбәрләр булды[140]. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры режиссёры Фәрит Бикчәнтәев Кытай режиссёры Ма Җең Һоң һәм Кытай рәссамы Биен Вентон белән берлектә 2012 елда «Турандот»ны сәхнәгә чыгардылар. Газеталар сценарийга нигез итеп Гоццидан Кәрим Тинчурин тәрҗемә иткән текст алынуы турында яздылар. Тик соңрак – премьера уңаеннан язылган мәкаләләрдә К.Тинчурин исеме әйтелмәде, ә пьесаның русчадан татарчага Рүзәл Мөхәммәтшин тәрҗемәсе булуы хәбәр ителде. 2012 елның март аенда «Matbugat ru.» интернет сайтында «Хан кызы Турандот»ның яңача сәхнәләштерелүе уңаеннан хуплау һәм кискен каршы фикерләр белдерелгән иде. Алар арасында «Кәрим Тинчурин спектакльне татар әкияте буларак сәхнәләштергән бит! Ә сез...» кебек аянычлы сүзләр дә булды.

2012 елның 6 апрель көнендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Гоцци әсәренә нигезләнгән «Хан кызы Турандык» спектакленең премьерасы куелды. Республика матбугаты бу вакыйганы зурлап бәяләде, күпсанлы фоторәсемнәр белән мәкаләләр басылды. Газеталарда «Әлегә кадәр татар сәхнәсендә мондый әсәрнең күренгәне юк иде», «Бу – без күнекмәгән, моңарчы күрмәгән яңа стильдәге спектакль.

---

[139] Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль... – Б. 106–139.
[140] Кадырова А. Татарскую «Турандот» китаянки покажут в год Дракона // Вечерняя Казань. – 2011. – 30 декабря; Кытай режиссеры татарча спектакль әзерли // Ватаным Татарстан. – 2012. – 13 гыйнвар.

Пластика, һава акробатикасы, шәрык көрәш сәнгате, кытай маскалары гына да ни тора!», «Искиткеч тамаша» дип, югары бәяләгән фикерләр басылды. Шулай ук бу елның көзендә спектакль Кытайның башкаласы Пекин шәһәрендә күрсәтеләчәге язылды[141]. Режиссёр Ма Җең Һоңның спектакльне татар тамашачысына мөмкин кадәр якынрак итеп куярга тырышканлыгы турында да искәртелде[142].

Спектакльнең программа-буклетында Татарстан-Кытай уртак театраль проектының 2 бүлектән торган драма булуы, Р.Мөхәммәтшин тәрҗемәсе икәнлеге, әсәрне сәхнәгә куючылар һәм рольләрне башкаручылар, тамашаның 2 сәгать 30 минут дәвам итүе турында мәгълүмат бирелгән иде.

Премьера уңаеннан язганда кайбер газеталар Гоцциның бу әсәрен элек Кәрим Тинчурин татарчага тәрҗемә итеп сәхнәгә куйганлыгын искәрттеләр. Ләкин шунда ук «Пьесаны урыс теленнән яшь шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин тәрҗемә иткән. Ул геройларның исемнәрен төркиләштергән. Мәсәлән, Альтоум – Алтын ханга, Адельма – Гаделмәләккә, Бригелла – Бәрәкаллага, Измаил – Исмәгыйльгә әйләнгән» дип, үзләренчә «ачыш» ясадылар[143]. Тәҗрибәле драматург, классик әдип Кәрим Тинчуринның моннан 95 ел әүвәлге тәрҗемәсе булган хәлдә, шул ук әсәрне тәрҗемә итү ихтыяҗы зур булгандырмы һәм анықы белән Р.Мөхәммәтшин вариантларының аермалары нәрсәдә һәм кайсыныкы уңышлырак икәнен тикшерергә алынмыйбыз. Тик геройларның исемнәрен төркиләштергән тәрҗемәче буларак Р.Мөхәммәтшин күрсәтелүе дөрес түгел. Чөнки бу әкияттәге кеше исемнәре безнең халыкка электән үк төрки-татарча һәм гарәпчә вариантларда таныш булган. Шулай ук Алтын хан, Тимерташ, Гаделмәләк исемнәре Ш.Рәхмәтуллин хикәятендә һәм соңгы тамашада булган Алтын хан, Тимер, Гаделмәләк, Сәлимә, Гөлкәй, Бәрәкалла, Исмәгыйль һәм башка исемнәр һәммәсе дә К.Тинчурин тәрҗемәсендә үк булганлыгын истә тотарга кирәк.

---

[141] «Турандык» – берләшү турында хыял ул, яки Камаллылар Кытай операсын ничек куйды? // Ватаным Татарстан. – 2012. – 6 апрель; «Хан кызы Турандык» // Татарстан яшьләре. – 2012. – 7 апрель; Хәбибуллина Л. Мәхәббәт һәр халык өчен уртак хис // Шәһри Казан. – 2012. – 10 апрель; Фәрхетдинова Ч. Кытайга сәфәр // Мәдәни җомга. – 2012. – 20 апрель.

[142] Митина О. Татарскую «Турандот» увидят в Пекине // Республика Татарстан. – 2012. – 13 апреля.

[143] Фәрхетдинова Ч. Кытайга сәфәр // Мәдәни җомга. – 2012. – 20 апрель.

***

Уртак сюжет тамырына корылган әсәрләрдән югарыда тасвирлап үтелгәннәренең һәрберсе «Кыз хикәяте» әсәре белән төрле күләмдә аваздаш булып тора. Төп сюжет сызыгы һәм вакыйгалар үсешенең уртаклыгы, тел-стиль охшашлыклары һәм башка төр үзенчәлекләр бу әсәрләрнең барысының да бер чыганактан башлангыч алган булуын дәлилли. Кайбер әсәрләр «Кыз хикәяте» эчтәлегенә аеруча якын икәнлеге күренә.

Бу сюжет турында югарыда бәян ителгәннәрне йомгаклап әйткәндә, ул татарларга иң әүвәл «Кыйссасел-әнбия» һәм Низами әсәрләре, тәрҗемә хикәятләр белән Шәрыктән килгән, үз җирлегебездә иҗат ителгән «Кыз хикәяте» һәм «Мәликә китабы» аша тагын да таралган. Ә аннан соң XVIII йөздә фарсычадан французчага тәрҗемә ителгән әсәр аша XIX гасырда Европадан төрекчәгә тәрҗемәсе рәвешендә һәм төрек теленнән татарчага тәрҗемәдә дә әйләнеп кайткан. XX гасыр башында Гоцци әсәрен тәрҗемә итеп сәхнәләштергән Тинчурин спектакле белән тагын Европа әсәре буларак яңарган. Мең елдан артык тарихка ия булган мавыктыргыч бу сюжет бер халыктан икенчесенә, илдән-илгә күчеп, дөнья гизгән. Соңгы заманда – XXI гасыр башында да «Турандот»ның дөнья сәхнәләрендә уйналуы, Кытай һәм татар сәхнә осталары тарафыннан яңартылган рәвештә сәхнәгә чыгарылуы бу сюжетның үлемсез булуын дәлилли.

## Сюжет Кытайныкымы?

Сүзебез ахырында бу мәсьәләгә аерым тукталуны кирәк дип таптык. «Чин» атамасы элекке дәвердә, бигрәк тә Шәрык халыкларының иҗатында, бары тик «Кытай» мәгънәсен генә белдермәгән. Ә төрки халыклар яшәгән Кытай Төркестаны мәгънәсендә дә йөргән. Бу хакта тюркологларның һәм Шәрыкне өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләрендә әйтелгән.

Моның дәлилен Низами әсәрләрендә дә күрергә мөмкин. Аның «Һәфт пәйкәр» поэмасында тасвирланган Бәһрам шаһның гүзәл җиде хатынының берсе – Төркестан патшасының кызы Ягманаз бүлекчә башында «Туркестанская царевна» дип, ә текст эчендә «светильник Ки-

тая» һәм «звезда Турана», «царевна Чина» дип аталган[144]. Анда мондый юллар бар:

И сказала дочь хакана Чина – Ягманаз:
О мой шах, тебе подвластны Рум, Туран, Тараз.

Менә мондагы «Чин» атамасы «Төркестан» мәгънәсендә кулланылган. Бәһрам шаһ чорында «Туран» дигән атама астында төрки халыклар яшәгән Урта Азия далалары күздә тотылган[145]. Галим Г.Җәфәров Низаминың «Җиде гүзәл» поэмасында Чин кызы исеменнән Бәһрамга сөйләнгән хикәятнең Кытайга бернинди бәйлелеге булмавын искәрткән[146].

Галим Е.Э.Бертельс Төркестан хаканының кызы Ягманазны «төркмән» кызы дип язган[147].

Низами поэмасында Төркназ исемле гүзәл төрки кыз турында да сүз бара[148].

«Җиде гүзәл» әсәрендәге Чин хаканының Иранга бәреп керүе турындагы бүлектә шулай ук «Чин» атамасының Туран һәм төркиләр булганлыгы ачык тасвирланган[149].

Галимнәр билгеләвенчә, Низами әсәрләрендә төрки тематикасы киң яктыртылган. Бу күренеш төркиләрнең берләшүе һәм төрки дәүләтләрнең күтәрелеш чорында иҗат ителүе белән аңлатыла[150]. Шагыйрь Низами иҗатын тирәнтен өйрәнгән галим Е.Э.Бертельс әлеге мәсьәләдә болай дип язган: «Мусульманские авторы XII–XV вв. Чин

---

[144] Низами Г. Собрание сочинений. В 5-ти т. Т.4: Семь красавиц... – С. 165–166.
[145] Бертельс Е.Э. Низами: творческий путь поэта. – М.: изд-во АН СССР, 1956. – С. 162.
[146] Джафаров Г. Русь и тюркский мир в «Искандер-наме» Низами // Советская тюркология. – 1990. – №4. – С. 50.
[147] Бертельс Е.Э. Низами: творческий путь... – С. 172. Ягманаз исеме кушма исем булып, аның «ягма» дигән өлеше төрки сүз, ә «наз» – фарсы сүзе. Мәхмүд Кашгарыйның 1072–1074 елларда язылган борынгы төрки телләр сүзлеге – «Диване лөгатет-төрк» китабында «йагъма» сүзенең ике төрле мәгънәсе теркәлгән. Ягъни, беренче мәгънәсе – төрки кабилә исеме, икенчесе – Тәраз янындагы бер авыл исеме дип аңлатылган. (Древнетюркский словарь. Ин-т. языкознания АН СССР. – Л.: Наука, 1969. – С. 225). Ә татар лексиконына фарсы теленнән кереп, ныклап урнашкан «наз» сүзе өстәмә аңлатмага мохтаҗ түгел.
[148] Низами Г. Собрание сочинений. В 5-ти т. Т.4: Семь красавиц... – С. 154–164.
[149] Шунда ук. – Б. 112–118.
[150] Джафаров Г. Русь и тюркский мир... – С. 47–54.

(Китай) или Хитай ассоциировали с Китайским Туркестаном»[151]. Бертельс икенче бер хезмәтендә «У Низами представление о Китае почти всегда соединяется с представлением о тюрках. Очевидно, говоря о Китае, он скорее имеет в виду Китайский Туркестан»[152] дигән. Бу галим шулай ук хатын-кызларның каһарманлыгы төркиләрнең эпос традицияләренә хас булганлыгын да искәрткән: «Характерно, что героические качества Низами приписывает женщине из Китайского Туркестана, что вполне соответствует традициям героического эпоса тюркских народов»[153].

Җәфәров та Низаминың «Искәндәрнамә» һәм «Шәрәфнамә» поэмаларында Чин атамасы астында шагыйрьнең Кытай Төркестанын күздә тотып язганлыгына өстәмә дәлилләр китерә. Ул, аерым алганда, «Кытай хаканы»ның Әфрасиаб патшалыгы варисы дип һәм «төркиләр шаһы» дип тә аталганлыгын ассызыклый[154]. (Әфрасиаб – төрки Туран дәүләтенең данлыклы хөкемдары. Борынгы фарсы әдәбиятында Әфрасиаб исеме дәһшәтле көч һәм явызлык мәгънәләренең синонимына әверелгән.). Гомумән, Низами әсәрләрендәге «Чин» атамасының хәзерге мәгънәсендәге Кытайны белдермичә, Кытай Төркестаны күздә тотылганлыгы Г.Җәфәров мәкаләсендә нигезле яктыртылган[155].

Бу китапта тасвирланган борынгы сюжетка язылган әсәрләрдә очрый торган Турандык (Турандот) исеме дә «Чин» исеме астында төркиләр күздә тотылганга бер дәлил. Ягъни, Турандот – башлангычта фарсы телендә «Туран дөхт», ягъни «Туран кызы» дигәнне белдергән. Фарсыча «дөхт» (дөхтәр) сүзенең һәм европа телләрендәге: алманча *tochter*, шведча *dotter*, инглизчә *daughter*, русча *дочь* һәм башкаларның төп тамыры бер үк. Шул рәвешчә, әсәрләрдәге Турандот исеме – башбирмәс зирәк кызның төркиләр дәүләте Туран патшасының кызы буларак тасвирланганын раслый.

«Чин» атамасының бары тик Кытай дигән мәгънәгә генә ия булмаганлыгына охшаш тарихи бер карашны да искә алырга ярый. Шәрыкмөселман авторлары, шул исәптән Шиһабетдин Мәрҗани һәм башка

---

[151] Низами Гянджеви. Искендер-наме / пер. Е.Э.Бертельса и А.К.Арендса. – Баку: Элм, 1983. – С. 561.
[152] Бертельс Е.Э. Избранные труды: Низами и Фузули. – М.: изд. Вост. лит., 1962. – С. 379.
[153] Бертельс Е.Э. Низами: творческий путь... – С. 217.
[154] Джафаров Г. Русь и тюркский мир... – С. 52.
[155] Шунда ук. – Б. 47–68.

кайбер татар галимнәре дә элек европалыларны «франклар» дип язганнар. Әмма бу исем астында «французлар» гына күздә тотылмаганлыгы мәгълүм. Шуның кебек, борынгы һәм урта гасырлар чорында кулланылган Чин атамасын һәр очракта да Кытай белән тәңгәлләштерү ялгыш. Ә Чинны Кытай буларак кабул иткән соңгырак дәвердәге төрле авторларның үз әсәрләрен Кытай җирлеге белән бәйләп тасвирлавы иҗади фантазияләреннән килгән.

2012 елда татарча тамаша куйганда кытайчылык белән мавыгып ялгышу да фантазияләрнең дәвамлы булуын ачык күрсәтте. Мәсәлән, Ма ханым башта «Турандот»ны сәхнәгә кую – күп режиссёрларның хыялы булуын белдереп, русча газетада «бу бит – Кытай әкияте» дигән иде[156]. Ә татарча газетада аның бу әсәрне «Кытай халык әкияте» дип атаганлыгы язылды[157]. Тик шуннан соң дүрт көнгә генә соңрак чыккан газетада режиссёр ханымның фикере үзгәргәнлеген күрәбез. Ягъни, ул журналистның «Сез бер әңгәмәдә бу әсәрне кытай әкияте дигәнсез...» дип соравына Ма ханым болай җавап биргән: «Юк, юк, һич алай түгел. Гоцци әсәре кытай әкияте була алмый. Мин аны һәр милләт үзенеке итеп күрә ала торган әсәр дип атар идем» – ди[158]. Тагын ике көн узгач аның интервьюсында «Вакыйга Кытайда бара. Аны итальян драматургы гарәпләрнең «Мең дә бер төн» дигән фантастик әсәренә нигезләнеп язган» дигән сүзләре басылып чыкты[159]. Шулай итеп, Кытай режиссёры да бу уңайдан читен хәлдә калды, фикере атна-ун көн эчендә берничәгә төрләнеп алды.

Әмма, ничек кенә булса да, татар сәхнәсендә бу әсәр бөтенләй кытайча диярлек уйналды. Спектакльнең премьерасы уңаеннан аны газеталар «Кытай операсы», «Кытай әкияте сюжеты»[160] дип, анда тавышны нечкәртеп, татар сүзләрен кытай акценты белән әйтүләре турында сокланып та, гаҗәпсенеп тә яздылар. Спектакль режиссёры Ма ханымның мондый сүзләре дә китерелде: «Бу әсәр һәр халык үзенеке дип ка-

---

[156] Кадырова А. Татарскую «Турандот» китаянки покажут в год Дракона // Вечерняя Казань. – 2011. – 30 декабря.

[157] Кытай режиссеры татарча спектакль әзерли // Ватаным Татарстан. – 2012. – 13 гыйнвар.

[158] Хисаметдинова Г. Ма тәҗрибә үткәрә // Ватаным Татарстан. – 2012. – 17 гыйнвар.

[159] Хәбибуллина Л. Кытай режиссёры Камалда спектакль куя // Шәһри Казан. – 2012. – 19 гыйнвар.

[160] Кадырова А. Про накладные головы, шутки евнуха и принцессу Турандот // Вечерняя Казань. – 2012. – 11 апреля.

бул итәрлек итеп итальян драматургы тарафыннан иҗат ителгән. Анда Шәрыкнең «Мең дә бер кичә» әкияте чагылышлары, башка халыкларның традицияләре – бар да бар...»[161] Бу спектакль куелу уңаеннан «чып-чын меңьеллык Кытай мәдәнияте» дип мөкиббән китүчеләр дә булды[162].

Йомгаклап әйтсәк, төп башлангычта Кытайга бернинди бәйләнеше булмаган, шулай ук Чин атамасының Кытай дигәнне белдермәгәнлеген исәпкә алганда, бу сюжетка язылган әсәрләрне «кытайлаштыру» – тарихи дөреслекнең асылы бозылудан килеп чыккан бер нәрсә.

Ихтимал, кытай халкында да бу сюжетка корылган әкиятләр булгандыр. Чөнки бу сюжет, бик күп халыкларның иҗатында урын алган. Һәрхәлдә, мөселман мәдәниятенә бәйле ил-дәүләтләрдә, халык һәм милләтләрдә ул аеруча киң кулланылган, бик күп авторларның иҗатында урын алганлыгын тәгаенләп әйтергә тиешбез. Мең елдан артык мәдәни-рухи үсеше Шәрык һәм мөселман дөньясы белән турыдан-туры һәм тыгыз бәйле булган төрки-татар әдәбиятында да бу үлемсез сюжет яшәп килгән. Гомумән, бу сюжет Ислам мәдәнияте аша бөтен дөнья казанышына әверелгән.

---

161 «Турандык» – берләшү турында хыял ул... // Ватаным Татарстан. – 2012. – 6 апрель.

162 Ахметов Р. Турандот // Звезда Поволжья. – 2012. – №17 (11–16 мая).

## РЕЗЮМЕ

Десятая книга серии «Татарская археография» представляет собой публикацию текста поэмы «Кыз хикаяте» (Сказание о девушке). Сказание основано на древневосточном сюжете о мудрой деве, всемирно известном под названием «Турандот».

Рукописный сборник последней четверти XVIII века, содержащий полный текст поэмы «Кыз хикаяте», был приобретен Отделом рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан в 2000 году. Помимо поэмы в сборник вошли: неполный текст поэтического сказания «Миградж» (автор – Хаджи Махмуд), «Чубаннамэ» турецкого автора Раушани, другие поэтические и прозаические произведения.

Поэма «Сказание о девушке» состоит из 348 бейтов-двустиший, написанных неизвестным автором в форме «назира»* на поэтическое произведение 1382 года** золотоордынского поэта Ибрахима. Основной идеей поэмы является восхваление учености, которая должна быть присуща каждому правителю.

Автор и дата написания поэмы «Кыз хикаяте» в самом тексте не указаны. Крайние хронологические границы создания сочинения можно датировать началом XV – серединой XVI веков. Автором, предположительно, мог быть татарский поэт Мухаммедьяр, живший в первой половине XVI века, на что указывают сходство идей, стиля поэтического изложения и языковых особенностей известных произведений поэта и текста «Кыз хикаяте». Несомненно, установление авторства данного сочинения требует отдельных изысканий.

Предлагаемый вниманию читателей сборник содержит вступительную статью, текст «Сказания» и обзор поэтических произведений, созданных на сюжет произведения «Кыз хикаяте». В обзоре анализируются схожие мотивы увлекательного сюжета, имеющего более чем тысячелетнюю историю, проводятся параллели между текстами Корана и толкований к нему, древними персидскими и арабскими сказками, армянским переводом сочинения «Повесть о юноше и деве» (X век), поэмой Низами XII века, средневековыми сказками на татарском языке, трагикомической сказкой Карло Гоцци XVIII века и её переводом на татарский язык известного драматурга Карима Тинчурина, множеством книг на татарском языке разных авторов XIX и XX веков. В статье дается этимологический анализ названий «Чин» и «Китай».

В процессе исследовательской работы были выявлены ещё два списка указанной поэмы: в Научной библиотеке им. Н.И.Лобачевского Казанского (Приволжского) федерального университета и Институте восточных рукописей Российской академии наук (г. Санкт-Петербург).


---

* Творческая форма «назира» была широко распространенной в восточной мусульманской литературе средних веков.

** Первая информация о неполном списке произведения поэта Ибрахима была опубликована татарским литературоведом Наджипом Исмагиловым в 1985 году.

## ЭЧТӘЛЕК

*Мәрданов Р.* Гакылы китәр – һәркем күрсә йөзене! .................................. 3
«Кыз хикәяте»нең эчтәлеге ................................................................... 16
Әсәрнең идеясе ......................................................................................... 22
Сорау-җавапларга аңлатмалар .............................................................. 23
Әсәрнең тасвирлау чаралары ................................................................. 30
Хикәятнең теле һәм кульязманың палеографик үзенчәлекләре ...... 33
«Кыз хикәяте» сюжетының төп өлгесе ............................................... 37
Авторы кем икән? .................................................................................... 44

ХИКӘЯТНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ЯЗУЫНА КҮЧЕРЕЛМӘСЕ ............. 48

КУЛЪЯЗМА ФАКСИМИЛЕСЕ ............................................................... 88

«Кыз хикәяте» әсәре теркәлгән кулъязма җыентык тасвирламасы...... 108

«Кыз хикәяте»нең сюжет тамырлары һәм тармаклары ....................... 114
Сөләйман пәйгамбәр һәм Бәлкыйс кыйссасы ................................... 114
Борынгы әрмән телендәге «Егет һәм кыз турындагы хикәят» ...... 119
Низами поэмасы ..................................................................................... 121
Борынгы Шәрык хикәятләре ................................................................ 125
«Мәликә китабы» ................................................................................... 129
«Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгындагы
Хәләф белән Чин кызы хикәяте ......................................................... 139
Гоцци әкияте ........................................................................................... 148
Фатыйх Халиди хикәятләре ................................................................. 151
Шиһабетдин Рәхмәтуллин әсәре ......................................................... 155
«Хикәяи Маһифәйрүзә...» китабы ...................................................... 163
Татар халык әкиятләре ......................................................................... 167
Гоццидан Тинчурин тәрҗемәсе ........................................................... 170
Сюжет Кытайныкымы? ......................................................................... 177

Резюме ..................................................................................................... 182

**СКАЗАНИЕ О ДЕВУШКЕ**
*(на татарском языке)*

*поэма*


Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Шамиль Насыров
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 09. 11. 2012. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ №292.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 09. 11. 2012. Формат 60x84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ №292.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.